Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

07
июль 2019
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ЕВГЕНИЙ ЗУЕВ «КАЗАН КРЕМЛЕ»

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Изге Болгар җыены

15 июнь көнне Бөек Болгарның Ислам динен кабул итүе уңаеннан «Изге Болгар җыены» узды. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, РФ Президентының Эчке сәясәт идарәсенең Дини оешмалар белән хезмәттәшлек итү департаменты башлыгы Евгений Ерёмин, Россия Мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгат Таҗетдин, ТР Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башкалар катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

07 (307)

июль 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

28



31 **БЕЛЕМ АЛУ ТАРИХЫБЫЗДАН...**
Илфар Габдрахманов

100 **«ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН...»**
Әхтәм Зарипов

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Зиннур Мансуров**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*
10 **Чыңгыз хан – кара татарлар нәселеннән.** *А.Галимзянов*
12 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
18 **Әҗмәк һәм Васильево авыллары тарихы.** *Ю.Карпов*
24 **Икмәкле дә, хикмәтле дә Мамадыш.** *Л.Мөхәммәтҗанова*
28 **Хозыр Ильяс булсын юлдашың!** *Г.Хаҗиева*
31 **Белем алу тарихыбыздан...** *И.Габдрахманов*
34 **Татарстан Җөмһүрияте авылларындагы җәйге эш күренешләре**
36 **Кайту.** *Ф.Уразаев*

ТАТАР ГАМЕ

44 **Минтимер Шәймиев: «Туган тел проблемаларына күз йома алмыйбыз»**
49 **Елый-елый укыган китап.** *Г.Рәхим*
51 **Керәшеннәр башкаласы.** *Р.Сәгъди*
56 **Казанда беренче матбугат ифтары**

ПЕДАГОГИК МИРАС

58 **Керәшен татарлары математигы Игнатий Алексеев.** *Л.Мортазина*
64 **Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе.** *Р.Исхаков*

ДИНИ МИРАС

72 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*
78 **Габдулла Буби һәм аның «Иҗтиһад заманы үттеме, юкмы?» китабы.** *А.Гайнетдинов*
80 **Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?** *Г.Буби*

ӘДӘБИ МИРАС

84 **«Туган тел»гә һәйкәл кирәк.** *З.Мансуров*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов
Лотфулла Шәфигуллин

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

92 **Сихерче карт.** *Р.Шәйдуллин*
96 **Өчәү (хикәя).** *Р.Низами*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

100 **«Исемең матур, кемнәр куйган...»** *Ә.Зарипов*
106 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

108 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июль*

Заказ №.О-1607. Тираж – 2400 данә. Формат 70x108 1/16.
Басарга кул куелды: 20.06.2019.
Чыгу көне: 26.06.2019
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Казан Кремле»**. 1989. ***Евгений Зуев рәсеме***



Зиннур Мансуров

Каләм

Бездә әдәбият бар!.. Милләт хәлен тетрәнгән куллар белән язып бирү бу... Нигә... гыйбрәт алмыйсыз?

Габдулла Тукай

Язмышыннан җәберсенеп зарланучы
кавемнәргә кат-кат хәйран калам мин.
Өзгәләнеп үзгәртергә азапланмыйк –
ирексезләп булмый тәкъдир каләмен.

Күкләр барсын уңлы-суллы теркәп тора,
фани затка тагын нәрсә кала соң?
Хәләл чикне кысан тояр милләт хәлен
гыйбрәт итеп яза гына аласың.

Өмет белән сиңа бага газиз өммәт,
фәрештәләр өзеп бирә кавырсын.
Тәгълим кылыйк тәкъдир хакын ихлас санлап –
кәлам-сүздә калеб тибеп, кан йөрсен.

Сыктанулар гакылыңны сыегайтыр,
кәгазь җебер, күздән акса әр яше.
Карганмагыз кырыс хөкем карарына,
язар өчен анда бар... юл арасы.

Китап сүзен фәтва диеп белмәс бәндә
мәхлук төсле җанын асрар аң-мисез.
Язылмады азмы язмыш ялгышлары –
узганнардан нигә сабак алмыйсыз?..

Галәмнәрнең келәймәле кәлимәсе
иманлыга якын да ул, ерак та.
...Кыелудан йолып калыр каләмемне
мәхшәргәчә чәнчеп куйдым йөрәккә. ■

Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзасы Зиннур Мөҗип улы Мансуров 1949 елның 15 июлендә Татарстанның Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында туган.

Редакциядән: Бу айда мөхтәрәм каләмдәшебезгә 70 яшь тула. Танылган әдипне күркәм бәйрәме белән ихлас котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез!

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән.

Тарихчы түгелмен, шуңа күрә, әледән-әле тарихчы-галимнәребез фикерен искә төшереп, аларга мөрәҗәгать итүем, сезне дә шул чишмәләрдән саф сулар уртларга өндәвем аңлашыладыр. Мәсәлән, чагыштырмача күптән түгел арабыздан киткән Равил ага Фәхретдинов мирасы... Ул, әлбәттә, коеп куйган галим генә түгел, ә кемнәргәдер ошап та бетмәгән бик хисле, чын мәгънәсендә шагыйранә һәм ватандар замандашыбыз да иде (рухы шат булсын). Миңа култамгасы белән бүләк иткән китабының исеме дә («Кичке азан») – шуңа бер дәлил. Без укый торган әсәр («Казан ханбикәләре» трилогиясе) шактый матавыклы чорны тасвирлый, шуңа күрә бу очракта мөхтәрәм галимебезнең сүз сөрешен искә төшерү бик урынлы булыр кебек: «Татар ханлыкларында очлары-очка бәйләнеп беткән нәселләр, уртак нәселдән килүче ханнар, аларның берсенең – бер ханлыкта, туганының яки туганнан туганының икенче ханлыкта утырулары, алай гына да түгел, тәхеттән тәхеткә күченеп йөрүләре, бернинди тылмачка мохтаҗ булмаулары, сәяси генә түгел, гомуми этник берлек хакында сөйли... Кыскасы, татар җирендә татар белән сөйләшү өчен тылмач кирәкмәгән...», – дигәннән соң: «Дәүләтнең иң атаклы ханнары: ...Сафагәрәй (1524-1549); зирәк ханбикәләре: Нурсолтан һәм Сөембикә; бөек кенәз-карачылар: Булат һәм Нурали Шириннар...», – дип, үз фикерен белдергән иде ул. Кыскасы, Равил агабыз әйтеп калдырганча: «Борынгы Болгар һәм Сарай тирәләрендәге татар авыллары, Казан арты, Тау ягы, мишәр җирләре, Башкортстан, Көнбатыш Себер, Касыйм, Кырым, Әстерхан, шул җирләрдә борын-борыннан яшәп ятучы кешеләр... Үзенчәлекләр булса да, бер үк тел, бер үк матди вә рухи мәдәният, бер үк гореф-гадәт, ...әүвәл-әүвәлдән безнең татарга хас булган моң, сагыш, нечкә күңеллелек, ...пакьлек, эшкә әвәслек, ... ниһаять, бөтен татарны бүген берләштереп торучы аның борынгы, кодрәтле вә матур исеме – «татар» ...» – алтын сүзләр!

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

Фетнәгә әзерләнүче морза, бәк вә угланнар ул көнне халыкны базар мәйданнарында җыйдылар. Ялкынлы нотыклар сөйләнде:

– Казанлылар, тыңлагыз! Аннары, ишетмәдек, дип әйтмәгез! Сафагәрәй хан хакимлеген Аллаһ һәм адәмнәр каршында өстенрәк күрде! Тәкәбберлегенә чик куя алмыйча, бөтен казанлылардан биеккәрәк күтәрелде, килмешәк кырымлыларны үз тирәсенә җыйды!

– Җиребез горурлыгы булган нинди мөхтәрәм затларны хурлыклы үлемгә дучар итте! Ә күпме биләмәләрне кырымлыларга таратты!

– Алар кайчанга кадәр халыкны талап, байлык туплап, барысын да Кырымга озатып ятар?!

Әрнүле-ачулы сүзләр уңдырышлы туфракка төште. Халык төркеме зурая-куера, кузгалыш көчәя бара, инде хан сараена барырга өндәп кычкырулар да ара-тирә ишетелә башлады. Урамда елның бу вакытына хас чатнама суык тора, әмма кешеләр моны тоймый. Ирләр чыгып сөйләүчеләрне тыңлый, саллы йодрыкларын йомарлый, күзләрендә ярсу ут яна. Җәмигъ мәчеттәге өйлә намазыннан соң, башында Боерган сәед торган төркем чыкты. Сәедне шәехләрдән, муллалар һәм имамнардан торган тәкъвалар озата килә иде. Ә иң алдан саташулы биюләре белән дәрвишләр әйләнә. Алар, юл чапаннарының чабуын канат кебек җәеп, озын сәфәрләрдә аерылгысыз юлдашлары булган озын, саллы таякларын болгыйлар. Йөзләре кырыс, тавышлары тамакларын ярып чыга:

– Тыңлагыз, барыгыз да тыңлагыз!

– Базар мәйданына җыелыгыз!

– Сәед үзе килә!

– Ходай безгә үз фикер-сөземтәсен сәед аша җиткерә!

Дәрвишләрнең сүзен тыңлап, кешеләр өйләреннән чыга башладылар һәм базар мәйданына ашыктылар. Биниһая зур халык төркеме, Аллаһ хезмәтчеләренә юл бирү өчен, ике якка аерылды. Боерган сәед, биегрәк урынга менеп, кабарынкы буынлы бармаклардан гына торган карый кулларын өскә күтәрде:

– И, дин кардәшләрем! Безнең изге җиребезгә авыр көннәр килде. Кяферләр кырларыбызны таптый, өйләребезне яндыра, мөэмин-мөселманнарны үтерә. Әмма Казан илендә кяферләрдән дә куркынычрак дошман пәйда булды: Кырымнан килгән адәм актыгы мәкерле еландай хан сараена шуышып керде дә безнең өстән хакимлек итә башлады! И, дин кардәшләрем! Күзләрегез күрсен, колакларыгыз ишетсен! Ул безнең белән бер диндә булса да, бозык күңелле кяфердән дә әшәкерәк. Кырым кешесе халкыбыз муенына салган элмәген көн саен ныграк кыса бара, аның газаплануын күреп көлә. И, дин кардәшләрем! Мыскыл ителүләрегезне, кыерсытылуларыгызны кичермәгез, илкөндә танылган ирләрнең шул җәллад килмешәк койган кан елгаларын гафу итмәгез! Газаплап үтерелгән карачыларның җәмәгатьләре һәм ятим балаларының күз яшьләре җирдә ятарга тиеш түгел!

Халык төркеме гүләде, һавада гайрәтле йодрыклар селтәнде, кайберәүләр үксеп елый иде. Шулчакта кешеләрнең баш өстендә шартлаган камчы кебек ачы тавыш яңгырады:

– Алып бар безне, мөхтәрәм сәед! Явыз кырымлыларны җиребездән куыйк! Сафа хан да алар белән бергә олаксын!

Аңа бертавыштан каһәрләү сүзләре кушылды:

– Ләгыйн!

Дөнья күз ачып йомган арада кайный башлады. Ханга баш бирмәгән бәкләрнең нөкәрләре бөтен яктан кочак-кочак кылыч һәм ятаганнар ташый, ирләрнең иң түземсезләре киртә, казык сыман нәрсәләрне каерып алдылар. Тар, кәкре урамнардан сызгырып җайдаклар узды. Бөтен ярсу көче кирмәнгә таба юнәлде.

Башкаладагы чуалыш-тәртипсезлекләр турында хәбәрдар хаким дә кул кушырып утырмады. Яхшы коралланган Кырым гаскәре Хан сараена илтүче юлларны ябып өлгерде. Кирмән капкаларын бикләүдән генә бер мәгънә дә юк иде: бу сәгатьләрдә ханга каршы әмирләрнең Кирмән калкулыгындагы йортлары һәм сарайлары казаклар, баш күтәрүчеләр белән мыж килә.

Көбә киемгә төренгән һәм мыегына хәтле коралланган Сафагәрәй үзенә иярләп китерелгән чаптарга сикереп менде. Айгыр чарыслана, борын тишекләреннән ургылып пар чыга, ул пар аның купшы ялына көмешсыман сыкы булып ята. Кырым гаскәрен җитәкләүче курку белмәс Кечүк углан боерыгы буенча, капкаларны киереп ачтылар. Кар өстенә каткан юка боз өстеннән күн белән капланган, ханның хатыннары, бала-чагалары һәм кәнизәкләре утырган унлап кәшәү шуып китте. Сөембикә ханбикәнең нугайларыннан торган сак канаты астындагы олаулар баш күтәргән каладан тизрәк чыгып китәргә ашыкты. Шулчак артлы чаналарның берсеннән күн япма ачылды, аннан Сөембикәнең агарынган йөзе күренде, ул данлыклы нәсел дәвамчысы булган иренә шелтәле күзләре белән карады. Шул караш Сафагәрәйнең йөрәген чеметеп-тырнап алды: «Ә бит ул кисәткән иде, Сөем барысын да алдан күрде...» Әмма акылга муафыйк уй-фикерләрне тыелгысыз ачу, гайрәт чигү басып китте: «Ничек батырчылык итәләр алар?! Кара халык һәм алар артына яшеренгән куркак башкисәрләр мине – бөек нәселдән чыккан ханны инде икенче кат Казанны ташлап чыгарга мәҗбүр итмәкчеләрме? Һичкайчан булмас хәл! Беркайчан бу каланы калдырмаячакмын! Барысын да кырып бетерәм, буйсынмаганнарны канга батырам! Монда чын ханның ныклы кулын мәңге оныта алмаслар!»

Атын тыя-тыя, Кечүк килеп җитте, башын иеп хәбәр салды:

– Хаким, алар килә!..

***

Кышкы юл очсыз-кырыйсыз тоелды, җәйрәп яткан ак басулар офыкка барып тоташа иде. Вакыт-вакыт уңда яисә сулда, агач тарак шикелле, карлы урманнар торып басты. Суык инде качакларның тәненә һәм күңелләренә үтеп керә башлаган иде һәм бозлы тынлыкта чана табаннары шыгырдавы, атлар пошкыруы, аларны иярләгән угланнарның сирәк кенә кычкырып куалап алганы ныграк ишетелгән кебек тоелды. Сөрелгән хан, караңгы чыраен яшерә алмыйча, хәрәмханәсе белән шыплап тулган кәрванның башында дәшми-тынмый бара. Бу олауларда Сафагәрәйнең исәпсез-хисапсыз байлыгыннан алып өлгергән бөтен нәрсә дә бар. Хәер, байлык нәрсә ул, кешеләре калмады диярлек. Казан урамнарында төнгә кадәр барган куркыныч һәм аяусыз бәрелештә аның горурлыгы булган Кырым гаскәрен кырып салдылар. Хакимнең үзен могҗиза белән генә Кечүк коткарып калды. Сәргаскәр төн карасында аны җир асты юлына алып чыкты. Аларның эзеннән көч-хәл белән тагын ике дистәләп нөкәр мүкәләде. Нөкәрләрнең кайберләре – яраланып беткән һәм хәлсезләнгәннәре – ханлыкның чик буендагы Ия авылында сыену тапты. Боз каплаган Кинелчәк инеше артта калды, моннан инде нугай олыслары, аларның иксез-чиксез далалары башлана.

Атының тезгененнән кагып, Сөембикә иренә таба килде. Сафагәрәй, кайгыртучан кыяфәткә кереп, күзләрен мех башлыкка төренгән хатын-кыз йөзенә текәде:

– Туңдыңмы?

Ханым башын чайкады:

– Онытмагыз, әфәндем, мин бу җирләрдә үстем һәм моннан да суыграк шартларга ияләшкәнмен.

– Әйе, хәтерлим, – дип таркау гына җавап бирде Сафагәрәй. Аның тавышы ничектер хыялый һәм тонык чыкты, ул үзе дә биредә юк кебек иде. – Ә Кырымда... хәзерге вакытта бөтенләй башкача. Яңгыр ява, диңгездән салкын җил исә, ләкин мондагы кебек түгел. Әй, Кырым, изге туфрагым!

Сөембикәнең ачуы чыкты, башлыгын ачып ташлады, күз алдында нәфрәт белән ялтыраган күзләре һәм нык итеп кысылган иреннәре генә калды:

– Әгәр Сез, ирем, шул Кырым һәм күңелегезгә хуш кырымлылар турында азрак уйлаган һәм хыялланган булсагыз, безгә мондый бәхетсезлек килмәс иде! Менә без, хәерче сукбайлар кебек, минем атама кайтып сыенырга, дип, хәзер шушы юлларда тулганып йөрмәс идек!

Сафагәрәй башын өскә чөйде, аның матур коңгырт күзләрендә корыч кырыслыгы ялтырады:

– Беренче мәртәбә генә ялгышып китүең түгел, Сөембикә! Ә бит син үзеңнең бары тик хатын-кыз, ә мин хуҗаң икәнлегемне онытмаска тиешсең!

– Бәлки Сез хуҗадыр да, – дип тыныч һәм салкын тавыш белән җавап кайтарды ханым, бары тезген тоткан кулларының дерелдәп алуы гына тыштан болай тыныч булып күренүнең нинди авырлык белән бирелүен күрсәтеп тора иде. – Тик йортсыз хан белән атсыз егет – икесе дә бер үк түгелмени!

Сафагәрәй кыргый тавыш белән үкереп куйды, баш очында кылыч белән селтәнгән кебек камчысын уйнатты, шул вакытта икесенең дә килешмәүчән кырыс карашлары кисеште. Ир чаптарының кабыргаларына камчы белән сыдырып алды, моны көтмәгән яшь айгыр үрә басты, яңгыратып һәм үпкәләп кешнәде. Хан аны тиз генә артка чигендерде, тезгенен ярсып тартты да олауның койрыгына, иярләрендә салмак кына тирбәлеп барган кырымлы көрәштәшләре янына чаптырып китте, аннары барган шәпкә кире борылды, гайрәтле тавыш белән:

– Минем арттан! Хаҗитарханга киттек! – дип кычкырды.

Кырымлылар җәһәт кенә күтәрелделәр, камчылар эшкә җигелде, нөкәрләр, җәнлек аулагандагы тавышлар белән кычкырып, үз ханнары боерыгына берсүзсез буйсынып, аның артыннан ташландылар. Котырып чапкан атларның тоякларыннан күтәрелгән кар өермәсе кәшәүләргә һәм юлдагы кешеләргә ак кырпак сибеп калдырды.

Хәрәм агаларының башлыгы Җәгъфәр, бу көтелмәгән хәлдән аптырап, Сафагәрәйнең артыннан курку катыш кычкырырга өлгерде:

– Хаким, ә безгә нишләргә?!

Өермә эченнән тәкәббер ханның:

– Сарайчыкка барыгыз! – дигән боерыгы гына ишетелде.

Арыган-талган кәрван кар баскан даладан инде унынчы көн бара. Чакырылмаган кунаклар очраклы гына Габбас морза торлагына юлыктылар, ичмасам, монда бераз хәл җыярга, алдагы юлга каклаган ит һәм сыр алырга мөмкин булды. Морза кунакчыл тирмәсендә нугай бәкләр бәгенең кызын сыйлады, үзе бертуктаусыз сөйләнде:

– Быелгы кыш бик кырку булырга охшаган. Безнең олыс, Аллаһка шөкер, Аралга һәм Сырдәрьяның түбәнге өлешләрендәге көтүлекләргә күчеп өлгерде. Биредә дистәләп кенә ат калды, алар янында мин дә әлегә монда, кар басып китмәсә ярый инде, югыйсә, алардан да колак кагуыбыз бар. А-һа-һа, авыр заманнар кичерергә туры килә!

Иңенә тиң киң чырайлы һәм авыр сөякле Габбас учакта дөрләп янучы утка күзләрен

кысып караган булды, өзми-куймый зарлануын дәвам итте, ә үзе аның сүзенә каршы төшмичә, шым торган ханбикәне астыртын гына күзәтте. «Бәкләр бәге Йосыфның кызы шәп, әһ, шәп бит! Сафагәрәй хан ничек аны, Сарайчыкка кадәр озатып, атасының кайгыртучан кулларына илтеп тапшырганчы, ялгызын гына калдырып китә алган?! Ханбикә, әлбәттә, мангытлар каныннан, дала кызы, тик аның туган-үскән олысыннан чыгып киткәненә, рәхәт тормышта, муллыкта назланып яшәвенә дә ни гомер. Әнә хәзер дә, учакта янган кизәкнең ачы төтен исен тоеп, борынын җыера бит. Әйтәсе дә юк, ханбикә күчмә тормышның авырлыкларыннан бизгән!»

– Әтиегез, кодрәтле бәкләр бәге Йосыф, Ходай аңа озын гомер бирсен, быел кыш чыгарга калган Сарайчыкка кадәр өч көнлек юл. Кәрваныгыз белән барганда, бәлки, дүрт тә булыр. Алга таба бүтән торлаклар очрамас, кыш бик авыр килде, бөтенесе дә күптән инде җылы көтүлекләргә китеп бетте. Бәлки Сарайчыкка кадәр озатып куючыларны күтәрсез? Ни әйтерсез икән, ханбикә?

Сөембикә, уйларыннан арынып, башын какты.

– Сезгә бик рәхмәтлемен, морза, әмма Сарайчыкка никадәр тизрәк барып җитсәк, безнең барыбызга да шулкадәр әйбәтрәк булыр. Озакламый тирмәгез ишегенә үк кар бураннары килеп җитәчәк, ул чакта инде далада сәяхәт итәрмен димә. Сезгә дә, безнең тоткарлануыбыз аркасында, һәр кашык авырлык китерәдер!

Габбас морза кулларын як-якка җәяргә мәҗбүр иде. Ни диярсең?! Казан ханбикәсе күчмә тормышны бөтенләй онытып бетермәгән әле. Бураннарын да, далада кыш чыгуларның авырлыгын, кизәктән һәм тарыдан ясалган һәр көлчәнең санаулы гына икәнлеген дә яхшы хәтерли әнә.

Хәл җыйган, ял иткән казанлылар иртән, юмарт, кунакчыл морза белән саубуллашып, юлга кузгалдылар. Кәрванны озатырга ике көтүче үзләре теләп риза булды. Сафагәрәй хатыннарын ташлаганнан бирле, ханбикә төп йөкне үз өстенә алган иде. Атыннан ул, арбалар һәм кәшәүләр тыгыз боҗрага алынып, эчке якка чатырларны таратып, учакларга ут эленгәч, йоклар алдыннан гына төшә башлады.

Морзабәк торлагыннан алып хәстәрләнгән ягулыкны, ризыкны сак кына тотарга туры килә. Сөембикә хатыннарның һәм бигрәк тә балаларның суыктан иза чиккәнен күрә. Бөтен төшкә үтеп керүче салкыннан туннар һәм тиредән сырган юрганнарның күплеге генә коткара алмый шул.

Ул кичне ханбикә үзе дә үләрдәй булып талчыкканын һәм җелегенә кадәр төшеп җанын суырган суыкны тойды. Сөембикә, тиешле күрсәтмәләрен биргәч тә, киез чаршау-ишекне тыгыз гына ябып, чатырга керде. Учак янында кулларын җылытып утырган хатыннар аңа битараф кыяфәт белән генә борылып карадылар. Йөзләре йончыган, яңаклары сулган, ә күзләрендә ачлык шәүләсе генә калган. Әйе, бөтен дөньясына төкереп, алар ачы төтен таратучы ут янында утыралар һәм кол хатыннарның аларга ризык китереп биргәнен көтәләр. Берсе дә читкәрәк тайпылып, ханбикәгә учак янында урын бирергә кирәк, дип, уена да китереп карамады. Сөембикә, хәле бетеп, бер почмактагы киез өстенә тезләнде, аннары әкрен генә тирбәлеп торучы чатыр чатына авып төште. Күз алдында бөтен тирә-юнь әйләнә, тамагында торган ачы үт тәме күңелен болгата. Сөембикә янына Фәйрүзә бикә генә килде, өстенә сыр куелган үзенә тиешле көлчәсен сузды:

– Тамак ялгап алыгызчы, ханбикә.

Сөембикә үзәге өзелердәй ачыккан иде, әмма тәкъдим ителгән нигъмәттән баш тартырлык көч тапты:

– Башта улыңны тукландыр.

– Ул инде ашады. – Фәйрүзә, ханбикәнең янәшәсенә утырып, үзе дә сизмәстән,

көлчәнең бер кисәген авызына капты. – Бу каһәрле сәфәр кайчан бетәр икән соң, ханым-солтаным?

– Тиздән. – Сөембикә тынычландырырлык сүзләрен әйтеп өлгерә алмады, шул арада бөтен хатыннар кабат аңа борылып карадылар. Ябыгып калган йөзендә инде төпсез чокыр булып күренә башлаган матур зур күзле кәнизәк – юнанлы[1] кызы ямьсез итеп кычкыра башлады:

– Безгә теге юлы да, Сарайчык капкаларына кул сузарлык ара гына калды, диделәр! Кайда соң ул шәһәр?! Бөтен тирә-юньдә дала һәм бу каһәр суккан кар, без барыбыз да монда үләчәкбез!

Икенче почмакта бүтән кәнизәк үкереп елый башлады, кемнеңдер баласы кычкырды һәм Сөембикәнең өстеннән давыл узгандай булды, – бер мизгелдән чатыр эчен шашынып кычкыру, үкерү авазлары һәм яшь агызулар басып алды.

– Тыныгыз чыкмасын! – Ханбикә бөтен буена торып басты, юнан кызының ир-атны җәлеп итәрлек матур чыраена кизәнеп торып сыдырды. Тегесе, куркып, юрганына төренде дә тынып калды. Ул арада чатырга инде хәрәм агалары да йөгереп керергә өлгерде, ә Сөембикә, тынып калган хатыннарны инә күзеннән үткәреп, кырыс кына әйтте:

– Сарайчыкка барып җитә алмабыз, дип сөйләнгән һәркайсыгызны мин суыкка чыгарып ташларга кушачакмын! Барыбыз да – Ходай хөкемендә, аңа догаларыгызны багышлагыз һәм инде иртәгә без атам сараенда булачакбыз.

Хатыннар башларын иеп тындылар, кайберләре, сыр белән көлчәләрен ашап, куркып кына мышкылдады. Хадимә ачуы чыккан ханбикәгә дә ашарга китерде. Аның тамагыннан тәгам үтмәде, шулай да, үз-үзен ирексезләп, каткан салкын көлчәне чәйнәргә булды. Тәмам хәлсезләнсә, ул Сарайчыкка барып җитә алмас, ә аның көче бу кавемдәге һәркемгә кирәк, ханбикә аларны үзләренә куркыныч янамаган сыеныр урынга илтеп җиткерергә бурычлы дип саный. Күзеннән яшьләр ирексездән акса-аксын, ә Сөембикә учак янында утырмаганына, бу хатыннарның шул мәлдә аның көчсезлеккә бирелүен күрмәгәненә сөенә иде. Ышанычлы ир җилкәсенә таяну мөмкин булмавы аны гаҗизләндерә, бу мәлдә саклаучың, яклаучың бар икәнлеген тою шулкадәр кирәк икән.

– Сафагәрәй... – дип, ишетелер-ишетелмәс итеп кенә пышылдады ул. – Кайда соң син, Сафагәрәй?

Ә шуннан соңгы көндә берәү дә көтмәгән бәхетсезлек булды. Иртә таңнан дала өстенә кургашсыман авыр болытлар асылынды, бөтен тирә-як тынып калды, хәтта көртләр астыннан тырпаеп торган камыл сабаклары да үрә катты. Кар өермәсе көтмәгәндә килеп ябырылды. Зәһәр җил, давыллап-ургылып, чаналарга һәм ат ялларына сыенган кешеләргә ташланды. Өскә күтәрелгән чәнечкеле боз тузаны якаларга очып керде, учлап-учлап биткә сибелде, авызларны томалады һәм сүз әйтерлек әмәл калдырмады. Ханбикә буранны уздырып кычкырырга, алга таба бару юлын күрсәтергә тырышып карады. Булмады. Кәшәүләрне туктатып, бер-берсенә якынайта башладылар. Алда, күренер-күренмәс өермә эчендә, җайдаклар бәргәләнә, алар олауның котырган атларын игә китерергә маташалар булса кирәк. Сөембикә чаптарын шул тарафка юнәлтә генә башлаган иде, кинәт атның тояклары астыннан ниндидер сыгылмалы соры нәрсәкәй атылып чыкты. Бүре! Айгыр куркып кешнәде, аягүрә басты да дулап китте. Кулдан шуып барган юеш тезгенне тотып калу мөмкин түгел иде, чын мәгънәсендә йөгәнсез ат кар-буран эченә кереп югалды, аны һаваның тагын бозыла төшүе дә, хуҗасының иңрәп кычкырулары да туктата алмады...

Урысчадан ***Мөдәррис Вәлиев*** тәрҗемәсе ■

[1] Юнан – грек *(тәрҗ. иск.)*.

ЧЫҢГЫЗ ХАН – КАРА ТАТАРЛАР НӘСЕЛЕННӘН

Айрат Галимзянов*

Чыңгыз хан хатыны Бүртә ханым белән

Тарихчылар соңгы елларда Чыңгыз ханның этник нәселе белән кызыксына башлады. Мәгълүм ки, совет чоры, хәтта 1990 нчы еллардагы тарих дәреслекләрендә дә татарлар турында, Чыңгыз хан һәм аның оныктурыннары исеме, аларның канкойгыч һөҗүмнәре белән бәйләп, сүгеп-яманлап язалар иде. Моның өчен үзбәк, казакъ, каракалпак, бурят укучыларына да түгел, ә нәкъ менә татар балаларына гарьләнергә, башка милләттәге сыйныфташлары алдында кызарырга туры килде.

Хәзерге көндә һәр халык, аеруча казакълар, хәтта кытайлар да мәгърур Чыңгыз ханны борынгы ата-бабаларына кардәш итеп, үз тарихларына ныграк бәйләргә омтыла. Бу ни өчен шулай соң? Чөнки һәр милләтнең дөнья аренасында шанлы булып күренәсе, данлыклы тарихы белән мактанасы, үзен Евразия киңлекләренең тарихи хуҗасы итеп танытасы һәм моңа дәгъва белдерәсе килә...

Чыңгыз хан, ягъни үз исеме белән әйткәндә, Тимучин 1155 елда Бөек Тартариянең кечкенә генә бер почмагында – хәзерге Монголия далаларында утлап йөргән кыят кабиләсендә дөньяга аваз сала.

Тарихтан мәгълүм ки, ыруг һәм кабилә атамалары еш кына территориаль топонимнарда да сакланып кала. Миңа узган гасырның 80 нче елларында Татарстанның Буа районында урнашкан Кыят авылында эшләргә туры килде. Шуны да искәртик:

* Айрат Галимзянов – Чуашстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, тюрколог.

Чыңгызыйларның японнарга һөҗүме

бу авылда яшәүчеләрнең бер өлеше – татар һәм чуаш милләтеннән. Төрки кавемнең мәшһүр бер вәкиле буларак, чуаш кардәшләребез дә Чыңгыз хан мирасына дәгъва кыла ала.

Тарихчы Әхмәдзәки Вәлиди үзенең «Хатирәләр»ендә*: «Профессор Бартольд фикеренчә, Чыңгыз хан кара татарлардан килеп чыккан... Чыңгыз ханның бабалары үзләрен Эргенеконнан килгән күк төрекләр вәкиле дип санаганнар. Алар Чыңгыз хан дөньяга килгән вакытта Кансуда яшәп, төрки телдә сөйләшкән. Чыңгызыйлар дәверендә көнбатышка күченгән, Дунай буйларында һәм Анатолида яшәгән кара татарлар һәрвакыт төрки телдә генә аралашканнар»*, – дип яза.

Дөрес, бу гасырларда каракалпак һәм казакъ халыклары аерым милләт буларак формалашмаган әле. Шул сәбәпле дә булса кирәк, фольклорчылар «Идегәй», «Козы Көрпәч белән Баянсылу», «Чура батыр» кебек мәшһүр дастаннарны казан татарлары, телеут, нугай, казакъ һәм башкаларның уртак мирасы буларак өйрәнә.

Казакъ һәм каракалпакларның этногенезына турыдан-туры катнашкан нугайларның составында да кыят һәм аргын кабиләләре була. *(Половецкая луна. – 1991. – №1.)* Кырымда кырым татарларының эпиграфик мирасын өйрәнгән вакытта кыят һәм аргын кабиләләренә нисбәтле тамгалар булган кабер ташлары табылган. *(Мәмәт Айдар. Кырым татарлары // Казан утлары. – 1992. – №5. – Б.151.)* Бөек тюрколог Вельгельм Радлов атаклы «Идегәй» дастанының бер вариантын Кырымдагы Коген-ни-Кият авылы нугайларыннан язып алган. *(А. Н. Самойлович «Варианты сказания о Едигее...» // Тюркологический сборник. – 1972. – С.198.)*

Һәм, ниһаять, Тимучин бөек каһан итеп игълан ителгән һәм Чыңгыз хан исеме алган корылтайда кыят, аргын, меркит һәм җәлаир кабиләләре дә катнаша. Шулай итеп, казакъ һәм татарлар кебек үк, һәр төрки милләт Чыңгыз хан исеменә, аның мирасы һәм шанлы дәүләтенә дәгъва белдерә, киләчәк буынны аның рухында тәрбияли ала! ■

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

Саркофаг капкачына ясалган ирле-хатынлы этрусклар сыны (б.э.к. VII гасыр). Йөзләрендә монголоидлык чалымнары сизелә

Галимнәр инде берничә гасыр дәвамында бүгенге Италия биләмәсендә беренче югары үсешкә ирешкән цивилизация төзегән этруск халкының серен ачарга тырышалар. Ни өчен бу халык галимнәрнең даими игътибар үзәгендә соң? Сәбәбе шунда – матди һәм рухи яктан зур казанышларга ирешкән этрусклар Римның остазлары булганнар. Анда этруск патшалары хакимлек иткән дәвердә, фәкать алар тырышлыгы белән, Рим төзелгән, матур калага әверелгән. Этрусклар, үз казанышларына таянып, римлыларга кала да, шактый камил структуралы дәүләт тә корып биргәннәр.

Этруск халкы нинди телдә сөйләшкән соң? Аурупа галимнәре берничә гасыр буе этруск теленең серенә төшенергә тырышалар. Әмма һинд-аурупа телләре ярдәмендә этруск телен аңларга тырышу тиешле нәтиҗә бирми. Бу ачкыч яраклы түгел. Ачкычны исә татар галимнәре тапты. Аның серен бары тик төрки телгә таянып кына ачып була икән. Иң әүвәл этруск телендә шактый калын төрки сүзләр катламы булуы турында Төркиядә яшәгән Адилә Айда (Садри Максуди кызы) үз хезмәтләрендә язып чыкты. Язучы Нурихан Фәттах та бу мөһим эшкә үз өлешен кертте. Бүгенге көндә татар галимнәре һәм энтузиастлары Ф.Р.Латыйпов, Н.Н.Хөсәенов, Н.И.Сәхапов һәм башкалар этруск теленең борынгылыгын, гадәти төрки телдән бераз тайпылган булса да, кире кагып булмаслык дәлилләр белән исбатлауны дәвам итә.

*Фәнни-популяр тарихи бәян

ЭТРУСКЛАР

«Үз үткәннәренең тирәнлеген аңларга өлгермәгән халыкларның киләчәге дә юк».

Олжас Сөләйманов

Галимнәр, этруск халкының серен ачарга теләп, гасырлар дәвамында төрле тикшеренүләр алып баралар. Шуңа да карамастан, этрускларның нинди халык икәнлеге, килеп чыгышы, теленең нинди тел булуы турында шушы көнгә хәтле төп-төгәл фикергә килә алганнары юк иде әле. Галимнәр ни өчен үҗәтләнеп этрусклар белән шөгыльләнә соң? Югыйсә, җир шарында килеп чыгышы, тарихы, теле, мәдәнияте сер булып калган халыклар алар гына түгел бит. Ә игътибар үзәгендә һаман этрусклар. Моның сәбәбе нәрсәдә соң, ни өчен Яңарыш чорыннан башланып киткән бу кызыксыну һаман сүрелмичә дәвам итә?

Эш шунда ки, этрусклар зур матди һәм мәдәни казанышларга ирешеп, көчле шәһәр-дәүләтләр конфедерациясе төзеп, соңрак чорда ярты дөньяны яулап алган Рим империясенең тәүге остазлары булганнар. Римның бишегендә этрусклар торган. Римлылар бик күп казанышларын Италиянең уртасында унике мөстәкыйль шәһәр-дәүләт төзегән ут күршеләре этрусклар цивилизациясеннән үзләштергәннәр. Алар этрускларны үзләренең остазлары дип таныганнар. Моннан ике мең еллар элек этруск кызына өйләнгән Рим императоры Клавдий хәтта этрусклар тарихына багышланган 20 томлы хезмәт тә язган булган. Ни аяныч, бу кыйммәтле хезмәт безнең көннәргә хәтле килеп җитмәгән. Әгәр сакланып калса, этрусклар бүгенге көндә теле, тарихы, мәдәнияте нинди икәнлеге ачыкланып җитмәгән серле халык сыйфатында галимнәрне даими ымсындырып тормас иде. Кызганыч ки, император Клавдий язган хезмәт борынгы заманда иң бай китапханәләрдән саналган Александрия шәһәре китапханәсе янганда утта юкка чыккан. Галимнәр шул янгын вакытында антик дөнья авторларының этрусклар турындагы башка хезмәтләре дә юкка чыккан, дип язалар. (Бәлки аларның кайберләре Ватиканның серле китапханәсендә сакланадыр?!)

Тарихка «мәңгелек шәһәр» дигән исеме белән кереп калган Рим Тибр елгасының сул як ярында урнашкан. Элек бу елганың атамасы Рума булган дигән мәгълүматлар да бар. Кайбер галимнәр «Рума» атамасын этруск сүзе дип саныйлар. Рим шәһәренә нигезне дә этрусклар йоласы буенча салганнар һәм аны этрусклар төзи башлаган. Рим дәүләтенең беренче патшалары да этрускларның Таркна ыруыннан булган. (Татарстанның Биектау районында Таршна авылы бар!) Соңрак бу ыруның исеме римлашкан һәм Тарквинига әйләнгән. Бу ыру вәкилләре төзегән шәһәр дә Тарквини шәһәре дип аталган. Рим тарихчысы Тит Ливий (б.э.к. 59-б.э.ның 17 елларында яши) Рим тарихы турында зур хезмәт язып калдырган. Ул анда Римның беренче патшалары этрусклардан булуын турыдан-туры искәртә: «Патшалар Римга нигез салынганнан алып аның азат ителүенә хәтле 244 ел буе идарә итәләр», – ди. Рим халкы ахыр чиктә этрусклар ыруыннан булган патшаларның шәһәрдә хуҗа булып утыруына каршы чыга, баш күтәрә һәм тарквиниларны Этруриягә куып җибәрүгә ирешә. Икенче урында Тит Ливий: «Барысы да бер фикергә килде – Тарквинилар ыруыннан арыну гына патшалардан котылуга китерәчәк», – дип яза. Кыскасы, вакыт үтү белән көч туплый барган Рим халкы этруск патшаларын тәхеттән төшерә, тик этрускларның бер өлеше шәһәрдә шуннан соң да яшәп кала. Соңгы патша Горур Тарквини Этруриягә куылганнан соң, шәһәрдә республика хакимияте урнаша. Бу хәл б.э.к. 509 елда була. Шул рәвешле патшалар хакимияте бетерелә һәм идарә итү ике преторга (беренче то-

ручы) – Брут белән Коллатинга тапшырыла. Соңрак преторлар урынына консуллар идарә итә башлый. Алар бер елга гына сайлап куела. Идарә итүнең консуллар кулына тапшырылуы хакимиятнең күпмедер дәрәҗәдә көчсезләнүенә китерә. Ике тәкә башы бер казанга сыймас, дигәндәй, бераздан консулларның берсе – өлкән, икенчесе кече санала башлый.

Мәдәни һәм матди яктан шактый түбән дәрәҗәдә торган римлылар этрусклардан нинди казанышлар, һөнәрләр, йолалар кабул иткән соң? Беренче чиратта этрусكларның калалар төзү осталыгына игътибар итик. Археологлар җимерелеп, әрәм-шәрәм булып бетмәгән этруск шәһәрләрен казып тикшерү бәхетенә ирешәләр. Бу халык калаларын күп очракта калкулык өсләренә төзегән икән. Гыйбадәтханәләр дә калкулык өсләренә салынган, аннан астарак, баскыч-баскыч булып, торак йортлар урнашкан. Калаларда су торбалары үткәрелгән. Бу гадәт тора-бара этрусклардан римлыларга да күчкән. Юкка гына Рим «җиде калкулык өстенә салынган», дип сөйләнми торгандыр. Анда да тора-бара калкулыклар өстендә гыйбадәтханәләр, храмнар барлыкка килгән.

Этрусклар әүвәл түгәрәк өйләр сала торган булганнар, түбәсен салам белән япканнар. Соңрак йортларны турыпочмаклы итеп тә төзи башлаганнар. Иң зур бүлмәнең уртасында һәрвакыт учак янган. Төтен түшәмдәге тишектән чыккан. Бу төрки халыкларның тирмәсен хәтерләтә. Шунысы игътибарга лаек, соңрак римлыларда барлыкка килгән аксөякләр, югары катлам кешеләре, дәрәҗәле хәрбиләр, зур һәм затлы йортларда яшәсәләр дә, йортның иң зур бүлмәсе өстен ачык калдыра торган булганнар. Бу бүлмә «атрий» дип аталган һәм аның уртасында һәрвакыт учак янган. Бу гадәтне дә римлылар этрусклардан алганнар. «Атрий» этруск сүзе булырга тиеш. Аны этрусклар тарихы, теле, мәдәнияте белән күп еллар шөгыльләнгән Адилә Айда түбәндәгечә аңлата: «атриум» (атр-иум), биредә иум – латин теле кушымчасы, атр = ата-йер, ягъни «аталар җире» дигән мәгънәгә ия. (Зәкиев, 115). Өстәп шуны да әйтик: күрәсең, учак янган җылы бүлмәдә хөрмәтле аталар утыра торган булгандыр.

Этрусклар бик дини халык булганнар. Алар колонналар белән бизәлгән зур гыйбадәтханәләр төзегәннәр, аның фронтонын төрле сыннар, скульптуралар белән бизәгәннәр. Римлылар храмнар төзергә дә этрусклардан өйрәнгәннәр. Аларның храмнарын нигездә этруск осталары салган.

Рим шәһәре урнашкан җиде калкулыкның берсе Капитолий калкулыгы дип атала. Бу калкулык Римның үзәген тәшкил иткән, анда Римның мәңгелеген, кодрәтен чагылдыручы мәшһүр Капитолий храмы төзелгән. Ул Римның соңгы патшасы этруск Горур Тарквини заманында барлыкка килгән. Капитолий храмы үзенең архитектурасы белән этрусклар гыйбадәтханәләрен хәтерләтә икән. Римлыларның горурлыгы булган Капитолий храмы фронтонындагы ике тәгәрмәчле арбага җигелгән канатлы дүрт ат сыны – квадрига да этруск сынчысы Вулка тарафыннан эшләнгән (Нем., 230). Храм римлыларның өч төп алласы – Юпитер, Юнона һәм Минервага багышлап корылган, анда аллаларның сыннары урнаштырылган. Моннан тыш, биредә Римның символын тәшкил итүче бронзадан коелган Капитолий бүресе сыны да куелган. Имчәкләре сөт белән тулып кабарынган ана бүрене ике сабый – Рем белән Ромул имеп утыра. Борынгы риваять ана бүре имезеп үстергән Рем белән Ромул Рим шәһәренә нигез салган дип бәян итә. Әмма бу риваять тарихи дөреслеккә туры килми. Ул соңыннан гына уйлап чыгарылган. Бронза бүре сыны әүвәл Этрурияд коела (Нем., 230). Бүре этрусклар һәм аларның төрки күршеләре саба халкының тотемы – ыру башы саналган. Ул вакытта ана бүре корсак астында сөт имеп утыручы сабыйлар әле ясалмаган була. Соңрак Рим көч туплый, ә этрускларның шәһәр-дәүләтләре

Этрускларның гаилә төрбәсе – тумули. Бу төркиләрнең курганын хәтерләтә

конфедерациясе көчсезләнә төшкәч, римлылар ана бүре сынын Римның Капитолий храмына алып кайтып урнаштыралар. Бу этрусклар һәм сабаларның Рим белән берләшүен чагылдыручы сәяси акция була. Көчәеп киткән Рим моны идеологик максатларны күздә тотып башкара. Соңрак кына, риваятькә тәңгәл килсен, дип, этрусклар бүресе корсак астына ике сабыйны – бронзадан коелган Рем белән Ромулны утыртып куялар. Римның башлангыч тарихы шулай матур риваятькә төреләә, гәрчә римлыларда бүрене ыру башы дип санау булмаса да.

Рим шәһәре барлыкка килгән җиде калкулыкта элек авыллар торган. Борынгы Рим ул заманда әле шәһәр булмаган. Андагы авылларны берләштереп, шәһәр төзү өчен иң элек пычрак сазлык, баткаклыктан арыну максаты куелган. Үзәннең ямен алып, шәһәр төзергә комачаулаган бу сазлык римлыларның тәмам үзәгенә үткән. Ул бер үк вакытта бизгәк авыруы чыганагы да булган. Рим халкы аны үз телендә «клоака максима» – «биниһая пычраклык» дип атаган. Ниһаять, этрусклардан чыккан Рим патшасы Тарквини Приск заманында бу мәсьәләне хәл итәргә тотынганнар. Җыелган пычрак суларны агызып җибәрү өчен, каналлар системасы төзелгән. Җир астында калдырылган каналларның кайберләре шундый киң булган ки, «аннан печән төялгән арба да үтә алган булыр иде», дип яза Рим язучысы Өлкән Плиний (б.э.ның 23-79 елларында яшәгән). Каналлар корылганнан соң, этрусклар Палатин белән Капитолий калкулыклары арасындагы сазлыкны киптерүгә ирешкәннәр. Анда балчык ташып түшәп, Форум мәйданы ясаганнар, биредә халык җыеннары үткәрелгән, хөкем карарлары чыгарылган, базарлар оештырылган. Шулай этруск осталары җитәкчелегендә калкулык өсләрендә урнашкан авылларга үзара берләшү мөмкинлеге туган, нәтиҗәдә, Рим шәһәре барлыкка килгән.

Икенче бер урында Өлкән Плиний, рухланып һәм гаҗәпләнеп, тагын «бинигая пычраклык»ны, этрускларның каналлар төзү осталыгын телгә ала: «Кайвакытта Тибр (елгасы) суларын кире таба куа һәм андый чакта ике агым каналлар эчендә капма-кар-

шы очраша. Әмма шуңа да карамастан, нык итеп төзелгән корылма су басымына бирешми. Аның өстеннән авыр йөк төялгән арбалар да уза, ләкин түшәме түгәрәкләнеп эшләнгән корылма зыян күрми; аның өстенә кайвакыт искереп җимерелгән йортлар да авып төшкәли, тик Тарквини Приск заманыннан бирле җиде йөз ел үтүгә карамастан, ул һаман бирешми, гүя мәңгелек итеп корылган». Борынгы Римда төзелгән әлеге каналлар бүгенге көндә дә Италия башкаласындагы канализация системасының бер өлеше булып кала бирә икән. Бу хәл этрускларда гидротехниканың, сазлыкларны киптерү технологиясенең бик югары дәрәҗәдә торуы турында сөйли.

Этрускларның Римга ясаган йогынтысы архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә үзен аеруча нык сиздерә. Римда этруск патшалары династиясе Тарквинилар хакимлек иткәндә бу шәһәр нык диварлар белән уратып алына. Шулай Рим Италия шәһәрләре арасында абруйлы урын ала. Этрусклар тарафыннан Римда башкарылган күп эшләр соңрак римлылар тарафыннан «бөек» дип билгеләнә. Тарквинилар заманында Авентин һәм Палатин калкулыклары арасындагы үзәндә этрусклар тарафыннан төзелгән цирк та «бөек корылма» исеменә лаек була. Ул алтмыш мең кешене сыйдырган (Нем., 229).

XVIII гасырда яшәгән итальян архитекторы Джованни Баттиста Пиранези этрускларның урта гасырлар архитектурасында киң урын алган «роман стиле» барлыкка килүгә сәбәпче булуларын билгеләп үткән. Чыннан да, «роман стиле» чиркәүләр, монастырьлар һәм башка биналар төзү өлкәсендә бик зур роль уйнаган. Этрусклар тарихы, мәдәнияте белән таныш булмаган кешеләр бу стиль Рим империясе йогынтысы аша киң таралыш алган, дип уйларга мөмкин, әмма аның башлангычы этрусклар төзегән архитектура үрнәкләренә килеп тоташа икән.

Шәһәрләр төзү сәнгатен генә түгел, идарә итү системасын да римлылар этрусклардан алганнар. Әйтик, төрле тантаналар вакытында кулланылган бизәү алымнары, шулай ук Этрурия шәһәрләре патшалары, лукумоннар, консуллар, башка рәсми затларның кием-салымнарындагы бизәкләр, кулларындагы төрле хакимият билгеләре – барысы да Римга Этруриянең иң абруйлы шәһәре Тарквинидан (Таркна) китерелгән, чөнки Рим патшалары шушы шәһәрдән чыккан. Шулай ук римлыларның тантаналар вакытында кырыйлары пурпур (ачык кызыл төс) тукыма белән каймаланган атаклы тогасы, фил сөягеннән ясалган кәнәфиләр, дини йолалар, сугыш вакытында, бәйрәмнәрдә кычкырта торган махсус боргылар (быргылар) һәм тагын бик күп нәрсәләр этрусклар шәһәр-дәүләтләрендә, тормыш-көнкүрешендә кулланылган әйберләр булган. Һәм без римлыларныкы дип уйлаган күп нәрсәләр, ачыклый башласаң, этрускларга барып тоташа икән.

Этрускларның рәсем сәнгате Италиядә барлыкка килгән иң әүвәлге рәсем сәнгате булып тора. Ул мәгълүм бер мәгънәдә антик чор рәсем сәнгатен аңларга ярдәм итүче уникаль чыганак. Этрускларның мәһабәт һәм зиннәтле тумул-төрбәләрен бизәгән фрескалар, терракотага ясалган сурәтләр Италиядә биш-алты гасыр буе үскән рәсем сәнгатен өйрәнергә ярдәм итә. Этрускларның мәетләр өчен төзелгән иң бай тумул-төрбәләре чын мәгънәсендә картиналар галереясын хәтерләтә.

Римлыларның б.э.к. II-I гасырларга караган рәсем сәнгате этрускларның бай иҗади тардицияләренә нигезләнеп үскән. Этрускларның бу өлкәдәге йогынтысын бәяләп җиткермәвебез аларның өй һәм гыйбадәтханәләрне ничек бизәвен белмәвебез белән аңлатыла. Без бит бары тик этрускларның тумул-төрбәләрендәге фрескаларны күреп кенә фикер йөртәбез (Нем., 231).

Бронзадан сыннар, бюстлар коюга да римлылар этрусклардан өйрәнгәннәр. Капи-

толий храмы бүресенең этруск осталары тарафыннан коелганын алдарак әйтеп үткән идек.

Этрускларның һәм соңрак римлыларның да «атрий» дип аталган учак яна торган бүлмәләрендә вафат булган туганнарының балавыз битлекләре саклана торган шкафлары булган. Мәет күмү мәрасимендә бу битлекләрдән файдаланганнар. Моның өчен килеш-килбәте һәм буе мәрхүмгә охшаган берничә кеше шушы битлекләрне кигән <...> Балавыз битлекләрнең бронза сыннар һәм бюстлар койганда файдаланылуы шик уятмый. Бу йоланы беренче тикшерүчеләр этруск сынчыларына этруск һәм римлылар тарихына караган персонажлар исемнәрен куша торган булганнар. (Нем., 230-231). Соңрак римлылар да, этрусклардан күреп, скульптур портретлар ясаганда балавыз битлекләрдән файдалана башлаганнар.

Этрусклар римлыларга шәһәр төзүдә, архитектурада, сынлы сәнгать һәм сәнгатьнең башка төрләре буенча йогынты ясау белән генә чикләнмиләр, римлылар шулай ук фән өлкәсендә дә бу халыктан үрнәк алалар. Бай римлылар балаларын Этрурия шәһәрләренә «этруск дисциплиналарын» үзләштерергә озата торган булганнар. Дөресен генә әйткәндә, ул заманда фән дигән нәрсә әле төрле ышануларга, дини карашларга, йолаларга бәйле булган. Әйтик, этрускларда киң таралган гаруспикция, ягъни хайваннарның эчке әгъзаларына карап, кешенең язмышы турында күрәзәлек кылу берәр ситуациядә нинди карар кабул итү һәм башка шундый гамәлләргә кайтып калган. Күрәзәче-гаруспиклар нигездә хайванның бавырын, үпкәләрен тикшерү белән шөгыльләнгәннәр, шуңа карап нәтиҗә чыгарганнар. Адилә Айда «гаруспик» сүзен «һаруспекс» (һару-спекс) дип аңлата һәм сүзнең беренче өлеше төркичә «карын» (эч) сүзенә барып тоташа, дип фаразлый (Зәкиев, 115).

Этрускларның гаруспиклары Борынгы Рим тормышында гаять зур роль уйнаган. Әүвәл бу эш белән этрусклар гына шөгыльләнгән, соңрак, алардан күреп, римлылар да күрәзәлек итә башлаганнар. Гаруспиклар оешмасының (коллегиясе) үзәге Тарквини (Таркна) шәһәрендә урнашкан булган. Төрле мәсьәләләр буенча фикер ишетү өчен гаруспикларга аерым кешеләр генә килмәгән, дәүләт мәсьәләләре буенча да аларга мөрәҗәгать иткәннәр. Гаруспиклар сүзенә ышану гаять көчле булган. Христиан дине барлыкка килгәч, гаруспикларны кысу башланган, аларга храмнар алтарьларында корбан чалу тыелган. Әмма гаруспиклар һәм аларның шәкертләре моңа карап кына бу эштән баш тартмаганнар. Безнең эраның IV гасырында Рим императоры Константин христиан динен дәүләт дине дип игълан итә. Шуннан соң күрәзәлек белән шөгыльләнүчеләрне үлем җәзасына тарту турында фәрман чыгарыла.

Этрусклар хәрби өлкәдә дә төшеп калган халык булмаган. Бу хакта этрусколог А.М.Кондратов: «Римлылар үзләре сугыш алып бару өлкәсендә бик күп нәрсәгә этрусклардан өйрәнүләрен таныганнар. Кораблар төзү һәм аларны йөртү ысулларына да «коры җирдә яшәүче» римлылар этрусклардан өйрәнгән. Этрусклар ул заманда Урта диңгездәге иң оста диңгезчеләрдән саналган, греклар белән карфагенлыларның көндәше булганнар», – дип яза.

Нинди халык булган соң этрусклар? Алар кайдан килеп чыккан, ничек Италиянең уртасында унике шәһәр-дәүләт конфедерациясе төзеп, һәр өлкәдә зур уңышларга ирешкәннәр, югары үсеш алган үз цивилизацияләрен төзегәннәр. Заманында ярты дөньяны яулап алган Рим империясенең тәүге остазлары булганнар. Бу хакта сүз ике мең елдан артык дәвам итә. Шулай булса да этрусклар һаман тарихы да, теле дә, мәдәнияте дә ачыкланып бетмәгән серле халык булып кала бирә.

Дәвамы бар ■

Әҗмәк һәм Васильево авыллары тарихы

(Совет чорына кадәрге тарихи чыганаклардан)

Юрий Карпов

Район үзәге Мамадыштан 30 чакрым ераклыкта урнашкан Васильево (Әҗмәк) авылын безгә – драматург Рәдиф Сәгъди һәм «Безнең мирас» хезмәткәре Ленар Гобәйдуллинга да «Әби патша юлы»ннан барып күрергә насыйп булды. Тарихның төрле чорларында мәҗүсилек, мөселман, христиан, керәшен һәм рус мәдәнияте белән сугарылып, хәзер биредә нибары 181 кеше (руслар – 50 процент, керәшен татарлары – 47 процент) яши (чагыштыру өчен: 1908 елда – 942, 1926 елда 1035 кеше торган), бер урамлы бу авылның үз белгече, тарихчысы бар булып чыкты. Ул – тирә-як авылларда, районда исеме күпләргә таныш төбәкне өйрәнүче, тарих укытучысы, үзенең кечкенә генә «мәгарә»сендә архив тузанына чумып, үткәннең һәр вакыйгасын энҗе бөртегедәй барлаучы ***Юрий Петрович Карпов****. Сүзне, озакка сузмыйча, авторның үзенә бирик.*

Редакция

МӨСЕЛМАН АВЫЛЫ – ӘҖМӘК

Авыл турындагы иң тәүге мәгълүмат 1654 елга нисбәтле. Казан өязенең 1647-1656 еллардагы теркәү кенәгәсендә административ берәмлек – Җөри даругасындагы Әҗмәк турында менә ниләр язылган: «*По Зюрейской ж дороге писано и мерено во 162-м [1654] году. За служилым татарином Барзигитком Чирючеевым в деревне Ожмяк вместе с ясачными по мере пашни всее и с ясачною и с пустою ясачною ж землею пять длинников, одиннатцать поперечников без трети, итого – пятьдесять три десятины с третью в поле, а в дву – по тому ж*».



Әжмәк елгалары һәм Васильево авылының иске урыны. Мамадыш өязе картасыннан фрагмент

Җөри даругасының 1680 елгы теркәү кенәгәсендә дә Әжмәк авылы татар, ягъни мөселман авылы буларак теркәлә. 1710-1711, 1716, 1719 һәм 1745 еллардагы халык санын алу кенәгәләрендә Әжмәктә ясаклы дәүләт крестьяннары яшәгәнлеге күрсәтелә. Шуны да искәртик: нәкъ менә әлеге елларда авылда яшәүчеләр салым күплегеннән, яшь егетләрнең рекрутка алынуыннан һәм дини мәсхәрәләүләрдән йорт-җирләрен калдырып качып китәргә мәҗбүр була.

Тарихтан мәгълүм булганча, патшабикә Анна Иоановнаның рус булмаган халыкларны массакүләм чукындыру турындагы 1740 елгы карары нигезендә, 1742 елда Казан губернасындагы 536 мәчетнең 418е җимертелә. Шулар арасында Җөри даругасында, Тау Иле авылыннан 5 чакрым ераклыкта урнашкан 25 хуҗалыклы Әжмәк мәчете дә юк ителә. Бу вакыйгадан соң авылда яшәүчеләр саны бик нык кимеп, XVIII гасыр уртасына биредә мөселман татарлар бөтенләй калмый диярлек. Халык телендә авылның бары исеме генә саклана.

1904 елгы «Историко-статистическое описание церквей и приходов Мамадышского уезда» исемле китапта, төбәктә яшәүчеләр сөйләгәннәргә нигезләнеп, бирегә Ишки авылыннан беренче өч гаилә күчеп килгәнен һәм авылны Әжмәк дип атаганын беләбез. XIX гасырда яшәгән тарихчы И.А.Износковның «Список населенных мест Мамадышского уезда» исемле хезмәтендә Әжмәкнең чишмә исеме икәне әйтелгән. «Генеральный Геометрический план города Мамадыш и его уезда, состоящему в Казанской губернии сочинен в Казанской межевой конторе в 1798 году» исемле картадан Әжмәк һәм Иске Әжмәк елгалары ачык күренә.

Күп кенә елга һәм чишмә атамаларының кеше исеме белән бәйле икәне мәгълүм. Һичшиксез, Әжмәк атамасы да Хаҗимөхәммәт исеменнән килеп чыккан. Моңа охшашлы башка мисалларны да китерергә мөмкин. Мәсәлән, Әҗәле авылы атамасы – Хаҗигали, Әстерхан (Әҗтерхан, Әчтерхан) – Хаҗитархан исеменнән барлыкка килгән. Акман атамасы – Акмөхәммәт, Дусмәт – Дусмөхәммәт, Туймәт – Туймөхәммәт, Ярмәк – Ярмөхәммәт, Килмәк Килмөхәммәт исемнәренә барып тоташа.

Түбән Новгород, Сембер, Казан губерналарындагы почта юллары картасыннан фрагмент. Картада Мамадыш трактын һәм Васильево авылының яңа урынын күрә аласыз

Әҗмәк авылы тагын бер тарихи чыганакта – «Ведомость о наместничестве Казанском»да да искә алына. Бу документта 1781-1782 еллардагы Казан губернасының шәһәр һәм авыллары турында бай статистик мәгълүмат бар. Исемлектә 169 нчы сан белән Кошлеи (ягъни Кош Иле) авылында 17 ясаклы татар, шунда ук Әҗмәк авылында нибары бер генә кеше, ә 170 нче сан белән күршедәге Васильевода 47 керәшен татары яшәгәне әйтелә. Моның өстенә, һәр өч авылның да өяз шәһәре Мамадыштан (21 чакрым) һәм Казаннан (109 чакрым) бер үк ераклыкта урнашкан икәнлеге теркәлгән.

Шуннан соңгы тарихи чыганакларда Әҗмәк татар-мөселман авылы буларак бүтән телгә алынмый. Ул бары тик керәшен татарлары һәм руслар яши торган Васильевоның икенче атамасы буларак кына, гадәттә сызыкча аша яки җәя эченә языла.

Алда искә алынган 1742 һәм 1781-1782 елгы чыганакларга нигезләнеп, татар-мөселман авылы булган Әҗмәкнең хәзерге Васильево авылы янында урнашканын төгәл әйтә алабыз. Моңа Әҗмәкнең волость үзәге Тау Иленнән – 5 чакрым, Васильевоның – 6 чакрым, өяз шәһәре Мамадыш һәм губерна башкаласы Казаннан бер үк ераклыкта урнашуы да дәлил.

КЕРӘШЕН-РУС АВЫЛЫ – ВАСИЛЬЕВО

Васильево авылы исемен һәм анда керәшеннәр яшәгәнлеген телгә алган иң әүвәлге документ 1716 елга нисбәтле. Бу елгы халык санын исәпкә алу кенәгәсендә авылда яңа чукынган (халык телендә – чумылган) 7 гаилә, аларда 26 кеше яшәгәне (9 ир-ат һәм 17 хатын-кыз) теркәлә. Чыганактан күренгәнчә, Васильевоның яңа чукынган ир-атлары 1719 елга кадәр йомышлылар сословиесенә кереп, беренче чирата хәрби-полиция хезмәтен башкарган.

Әмма 1716 елда теркәлгән яңа чукынганнар арасында Василий исемле яки Василь-

ев фамилияле бер генә кеше дә юк. Бу исә авылга нигез салучының халык санын исәпкә алган вакытта инде гүр иясе булганлыгы турында сөйли. Шуңа нигезләнеп, Васильево авылы XVIII гасырдан иртәрәк, ә бәлки XVII гасыр ахырында ук барлыкка килгән, дип уйларга нигез бар.

Авыл атамасы турында да төрле фикер таралган. «Историко-статистическое описание...»нең авторы раславынча, авыл Әҗмәктән беренче чукынган Василий атлы керәшен исеме белән аталып, Әҗмәкнең исеме Васильевога гына алышынган. Әмма 1716 һәм 1719 елгы халык санын алу документларыннан һәм «Ведомости о Казанском наместничестве»дан күрүебезчә, алар икесе аерым авыл булып күрсәтелгән. Әҗмәклеләрнең чукынуы турында халык риваятьләре дә, тарихи чыганаклар да сакланып калмаган.

Башка фикер, аеруча халык риваятьләре буенча, бирегә руслар күчеп килгәндә беренче хуҗалык корылмалары Василий улы Василий исемле кеше тарафыннан салынган һәм авыл да аның хөрмәтенә «Васильево» дип аталган, имеш. Төбәкне өйрәнүче И.А.Износков фикеренчә дә, авылга исемне, беренче килеп төпләнүчене олылап, руслар биргән. Әмма бу мәгълүматлар бик шикле, чөнки 1834 елгы халык санын алу һәм 1904 елгы «Историко-статистическое описание» материалларына караганда, авылга руслар фәкать XIX гасыр башында гына күчеп килгән, 1716 елгы халык санын теркәү кенәгәсендә үк, ягъни XVIII гасыр башында инде авыл Васильево дип аталган һәм анда «йомышлы яңа керәшеннәр» генә яшәгән. Безнең фикеребезчә, Васильево бу елгы тарихи чыганакта «йомышлы яңа керәшеннәр» авылы буларак телгә алынган икән, авыл да XVII гасырның азагында безнең җирлеккә күчеп килгән һәм аңа нигез салган керәшен, ягъни ул вакыттагы документларда язылганча, «яңа керәшен» Василий исеме белән аталган булырга тиеш.

Авыл исеменең ике төрле әйтелешен болай аңлатырга мөмкин. XVIII гасырның 40 нчы елларында мәчет җимертелгәннән соң Әҗмәктә яшәүчеләрнең саны нык кимеп, 1781-1782 елларга бер генә гаиләгә кала. Безнең фикеребезчә, шуннан соңгы халык санын алу документларында Васильевога бик тә якын булган Әҗмәктә яшәүчеләрне аерым теркәмичә, ә ике исемле итеп, бер авылга гына язганнар булса кирәк. XX гасырның беренче чирегенә кадәр булган барлык рәсми документларда да авыл Васильево (Әҗмәк) дип теркәлгән. Хәзерге вакытка кадәр халык телендә, авылның икенче атамасы буларак, Әҗмәк исеме сакланып килә.

1904 елгы «Историко-статистическое описание церквей и приходов Мамадышского уезда» исемле китапта: *«XIX гасырга кадәр Васильево хәзерге урыныннан чакрым ярым ераклыкта, көньяктарак, ерганакта урнашкан була һәм анда яңа керәшен татарлары яшәгән»*, – дип язылган. Укытучы Валентина Васильевна Иванова халык риваятьләренә нигезләнеп сөйләгәннәргә караганда, авыл халкы элек ерганакның уң ягында, элекке колхоз умарталыгы җирендә яшәгән. Андагы кырда ватык чүлмәк калдыклары, кирпеч кисәкләре һәм хезмәт кораллары да табыла торган була. *«Халык гореф-гадәт һәм йолаларны авыл башындагы Кирәмәт дип аталган чишмә һәм ындыр артындагы елга буенда башкарган. Чишмә каршында аларның зиратлары да булып, әле безнең заманда да картлар анда яңгыр келәү йоласы үткәрә иде»,* – дип искә ала ул.

1789 елгы «Генеральный Геометрический план...»да Васильевоның беренче урнашкан урыны ачык күренә. Картада Әҗмәк авылы юк, әмма аның булганын Әҗмәк һәм Иске Әҗмәк елгалары искәртә. Хәзерге Васильеводан ике чакрым көнбатыштарак, Иске Әҗмәк елгасыннан ерак булмаган басуда кыр эшләре вакытында ислам йоласы буенча җирләнгән кеше сөякләре дә килеп чыгуы кайчандыр бирედә мөселман татарларының борынгы авылы һәм зираты булганы турында сөйли.

1719 елгы документта Васильеводa яшәүчеләр йомышлылар сословиесендә күрсәтелсә, 1720-1730 елларда ясаклылар составына күчкән булса кирәк. Һәрхәлдә, 1745 елгы теркәү кенәгәләре шул турыда әйтә. Бу елда Васильевода «әҗнәбиләрдән чукынган» 41 ир-ат яши.

Ә инде 1762 елда Васильеводa яшәүчеләр «дәүләткә ясак түләүче иске керәшеннәр» дип язылган. Бу елда авылда 47 ир-ат һәм 47 хатын-кыз яшәгәнлеге теркәлеп, алар 1745-1762 еллар аралыгында Әбде авылыннан да күчеп киләләр. Шул ук елларда Казан шәһәреннән өч чукынган мөселманның – «яңа керәшен татары»ның да килеп төпләнүе турында мәгълүмат бар.

Соңрак Васильево авылына руслар да күчеп килә башлый. 1834 елгы теркәү кенәгәсендә биредәге русларның алдагы халык санын алу вакытында, ягъни 1816 елда ук яшәгәне искәртелә. «Историко-статистическое описание»дә русларның кайсы авыллардан килеп төпләнүен һәм авыл халкының башка урынга күченү сәбәбен дә беләбез: *«В начале XIX века (с 1801-1808 г.) сюда (в Васильево) переселились из разных мест (из Красной Горки, Каменного Починка, Дальнего (Беляева) Починка Мамадышского уезда, из Усада и Кушака Вятской губернии 15 семейств экономических (государственных) крестьян. Когда таким образом Васильево стало увеличиваться, а болотистая и лесистая местность для застроек оказалось неудобною, жители принуждены были пересилиться на более сухое, удобное место. Они поселились поближе к Тавелям, по обеим сторонам большой, называемой в ту пору «Зюрейской» дороги, и занимают это место по настоящее время»*.

Шулай итеп, хуҗалык алып барырга уңайсыз булу сәбәпле, крестьяннар чакрым ярым төньяккарак, коры, иркен урынга күченә һәм ике яклы бер урамга каралты-кура корып, йорт салып яши башлый. Нәтиҗәдә, волость үзәге булган Тау Иле авылына да ара якыная.

Безнең фикеребезчә, авыл халкының яңа урынга күчеп төпләнүендә башка сәбәп тә мөһим роль уйный. Васильевоның иске урыныннан ерак түгел Казаннан Мамадыш шәһәренә бара торган почта тракты, ягъни гади халык әйткәнчә, «Әби патша юлы» узган. Дәүләт юлы статусындагы әлеге юл – Себер трактының бер өлеше. Бу чорда дәүләт дәрәҗәсендәге юлларны салу, даими төзекләндереп тору һәм юлчыларга хезмәт күрсәтү вазыйфасы якындагы авылның крестьяннарына йөкләнгән. Васильево авылы почта станциясе һәм кунак йорты төзү өчен өяз үзәгеннән кулай ераклыкта була. Мөгаен, хакимият авылны юл буена күчерергә һәм почта трактының ике ягына да мосафирханәләр төзеп, почта станциясе, күперләр салу, почта юлын ремонтлап тору өчен якын-тирә авыллар халкын да җәлеп итәргә дигән карарга килгәндер. 1808 елгы «Карманный почтовый атлас всей России с показанием главных почтовых дорог» исемле чыганакта Васильево яңа урында – почта трактында урнашкан һәм почта станциясе булган авыл дип күрсәтелә.

Яңа урынга күченгән авыл халкы почта станциясе өчен ат бирергә, кунакханәдә хезмәт итәргә, ям чабарга – күчер булып юлчыларны һәм почтаны йөртергә, мосафирларга ял итү өчен уңайлы шартлар тудырырга, кирәк булган очракта аларның карета һәм тарантасларын төзәтергә, юлның төзеклеген кайгыртырга тиеш була.

Почта станциясе төбәктә иң зурларыннан санала. XIX гасырның икенче яртысында Васильево халкы почта станциясенә көн саен 6 пар ат куеп һәр пары өчен 50шәр тиен акча биргән. Шуны да искәртик: әлеге акчага Мамадыш базарыннан ике пот арыш оны сатып алырга мөмкин булган.

Дәүләт юлына бәйле хезмәт башка төр һөнәрләр үсешенә дә ихтыяҗ тудыра.

Авылда тимерче, балта осталары, күн эшкәртүче, төзелеш өчен таш чыгаручы һәм ватучылар, көмешкә куучыларның (рәсми рәвештә аракы ясаучыларның) саны арта.

1834 елда Васильево авылында 41 гаиләдә 338 кеше (167се – ир-ат, 171е – хатын-кыз) яши. Шулардан 18е – ясаклы иске керәшен, 18е – рус крестьяннары гаиләсе дип теркәлгән. 1859 елда 72 гаиләдә 204 ир-ат һәм 231 хатын-кыз яши. И.А.Износков мәгълүматлары буенча, XIX гасыр азагында Васильево авылында 272 рус һәм 253 керәшен татары булган. 1897 елгы халык санын алу кенәгәсенә 846 кеше теркәлә. Бу саннар бер гасыр эчендә Васильево халкы 2,5 мәртәбә артканын күрсәтә. Моңа Тау Илендә яшәүче табиб хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге, халыкның тормыш шартлары яхшыруга исә өяз үзәгендәге телеграф һәм телефон станцияләре, авылда почта бүлеге барлыкка килү, мал табибы, янгын сүндерү машинасы һәм мәктәп эшләү дә сәбәпче булган.

1861 елгы реформадан соң, Васильево авылындагы һәр ир-атка 7,2 дисәтинә җир туры килә. Бу Кабык-Күпер волостендагы башка авыллар белән чагыштырганда иң зур күрсәткеч.

20 йөз башында Васильево икътисади һәм мәдәни яктан шактый үсешкә ирешкән иң зур авылларның берсе булып санала. 1909 елгы «Описание Казанской губернии»да язылганча, *«Кабык-Күпер волостендагы Васильево авылындагы 137 хуҗалыкта 936 кеше яши; 1876 елның 9 гыйнварында ачылган земство мәктәбендә священник Ф.Романов һәм укытучы Иван Прокопьевич Холкин 29 ир һәм 6 кыз баланы укыта; авылда полиция каравылчысы фатиры, вак-төяк сата торган 5 лавка, бер аракы кибете, су тегермәне, тимерче алачыгы һәм почта станциясе була»*. Авыл халкы игенчелек, терлекчелек, бигрәк тә аның ат үрчетү тармагы һәм вак һөнәрчелек белән дә шөгыльләнә.

Зират һәм чиркәү элек-электән Тау Илендә була. Шунда ук шимбә көнне базар да эшли. Гадәттә Васильево халкы волость үзәгенә Кече Үсинкә елгасы аша, 5 чакрым чамасы басу юлыннан йөргән. Чиркәү бәйрәмнәрендә – җәйге Никола, Покрау, кышкы Никола көннәре уңаеннан оештырыла торган ярминкәләргә дә бик теләп барганнар.

Туган илебезнең иң гүзәл почмакларының берсендә урнашкан, үзенә мөселман, керәшен, рус, хәтта борынгы мәҗүсилек мәдәниятен сеңдергән Васильево (Әжмәк) авылының совет чорына кадәрге кыскача тарихын шуның белән тәмамлыйм. Киләчәктә архив материалларын тагын да тирәнрәк өйрәнү нәтиҗәсендә яңа фактлар ачылыр һәм авылыбыз тарихы китап булып басылып чыгар, дип өметләнәм.

Чыганаклар һәм әдәбият

Дымолазов А.И., Чернышова В.А. Земля Мамадышская. – Нижнекамск, 2011.

Дымолазов А.И., Чернышова В.А. Кабык-Куперская волость Мамадышского уезда. (Краеведческий очерк).– Мамадыш: Филиал ОАО «ТАТМЕДИА» «Информпечать» «Нократ» («Вятка»). – 2009.

Износков И.А. Два реферата, читанные на IV-м археологическом съезде в Казани в 1877 г. – Казань,1882.

Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. Вып.VI. Г.Мамадыш и Мамадышский уезд. – Казань: Типография Императорского Университета, 1904.

Казанская губерния. Список населенных мест по спискам 1859. – С.П-б,1866.

РГАДА, ф.1209, оп.1, ед. хр.1128, л.306об.; РГАДА, ф.350, оп.2, ед. хр. 1102, л.664об; РГАДА, ф.350, оп. 1, ед. хр. 152, листы 7об.–8об; РГАДА, ф.350, оп.2, ед. хр. 1105, листы 241–241об.; РГАДА, ф.350, оп. 2, ед. хр. 1143, листы 261об.–262об.; РГАДА, ф.350, оп. 2, ед. хр. 1206, листы 521–515об. РГАДА, ф. 248, оп. 16, д. 803, л. 52-154 об. («Экстракт в Правительствующий сенат Казанской губернской канцелярии о татарских мечетях»).

Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в. /Под ред. проф. Корсакова Д.А. – Казань: Типо-литография Казанского университета, 1908.

Список селений Казанской губернии / Сост.чл. Каз. губ. зем. управы К.П.Берстель. – Казань: Типо-литография И.В.Ермолаевой,1908. ■

Безнең мирас №7 июль 2019

ИКМӘКЛЕ ДӘ, ХИКМӘТЛЕ ДӘ МАМАДЫШ

(Татарстанның Мамадыш районы авылларында җыелган халык ядкарьләре)

Лилия Мөхәммәтҗанова

Республикабызның үзәгенә урнашкан Мамадыш районында хезмәт сөючән, ачык йөзле, нык рухлы кешеләр гомер кичерә. Татар милләтенә күп кенә күренекле улкызларны – атаклы Яруллиннар, Шәйхи Маннур, Әхмәт Гадел, Зиннур Мансуров, Шаһинур Мостафин, Ринат Мөхәммәдиев, Локман Закир, Камил Вәлиев, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Нәҗип Нәккаш, Рафаэль Газизов, Миңгол Галиев, Марат Закир кебек иҗат кешеләрен һәм галимнәрне бирүе белән данлыклы як булуы да мәгълүм аның.

Шагыйрь, фольклорчы Шәйхи Маннурга Мамадышта куелган һәйкәл

Татарлар яши торган җир буларак, Мамадыш төбәге гомер-гомергә татар галимнәрендә зур кызыксыну уятып килә. 1940 нчы еллардан башлап, Ул тел, әдәбият һәм сәнгать белгечләренең игътибарын тоеп яши. Халык иҗаты белән кызыксыну, фәнни эзләнүләр алып бару максаты үз чорында бирегә Казан фәнни үзәкләреннән Хәмит Ярми, Халидә Гатина, Хуҗи Мәхмүтов, Шәйхи Маннур, Марсель Әхмәтҗанов кебек тикшеренүчеләрне китергән. Биредә табылган борынгы әдәбият җәүһәрләре, шушы төбәктә яшәгән һәм яшәүче шәхесләр иҗаты, фольклор материаллары матбугатта, фәнни җыентыкларда урын ала, гыйльми үзәк фондларында, архивларда тасвирланып, фәнни әйләнешкә кертелеп килә.

Биредә яшәүче халык үзе дә элгәрләре тормышына, үткәненә, мәдәни ядкарьләренә беркайчан да битараф булмаган: галимнәр белән бәйләнешкә кереп, фәнни архивларга үзләренең җирле рухи табылдыкларын – иске кульязмаларны, бәет һәм мөнәҗәтләрне, авыл тарихына мөнәсәбәтле кыйммәтле мәгълүматларны, шушы

төбәк өчен үзенчәлекле мәдәни кыйммәтләрне җыйнап тапшырган. Мондый эш белән кызыксынган кешеләрнең исемнәре онытылмый. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Мамадыш районының Түбән Ушмы авылыннан Габдулла Хәмитовның 1972 елда тапшырылган, Түбән Ушмы һәм кайбер башка авыллар тарихына мөнәсәбәтле гарәп язулы кулъязмасы саклана һ.б.

Мамадыш районы авылларына хас, әле бүген дә актив кулланылышта булган фольклор үрнәкләренә килсәк, алар аеруча кызыклы. Фән-техника, компьютер заманында дастан көйләүчеләр, әкият сөйләүчеләр күп булмаса да, туган ягы тарихына, туган җире сулышына битараф булмаган, үз авылы турында риваятьләр ишетеп үскән, үз ягының аждаһалы чокырларын күрсәтә белгән, шушы якта гына җырлана торган җырларга гашыйк, шушы якка мөнәсәбәтле бәетләр язучы, такмак-такмазаларга оста әби-бабайлар, апа-абыйлар, рухи мираска битараф булмаган яшь буын гомер кичерә бирәдә. Уйлап карасаң, нәкъ менә шушындый кешеләр милләт сагында тора да, нәкъ менә шулар татарны татар итеп саклый бит.

Мамадыш районы авылларында халыкның рухи энҗеләре шактый мул саклаған. Түбән Ушмы, Күчтем, Үсәли, Бөрсет-Сөкәче, Күкчишмә, Кече Кирмән, Урта Кирмән, Түбән Тәкәнеш, Шәмәк, Көмеш Күл, Дусай авылларында информантлар белән әңгәмә кору нәтиҗәсендә күпләгән топонимик, тарихи һәм мифологик риваять, мифологик хикәят, мәзәкләр һәм мәзәк хәлләр, ияләр турында ышанулар, сынамыш, такмак һәм җырлар, бәетләр, туй йоласы, умай утырту йоласы һәм уен фольклорын язып алу мөмкин булды. Төрле жанрларга карый торган, кайберләре төрле информанттан берничә вариантта яңгыраган әлеге әһәмиятле материалларда – һич ялгансыз халык хәтере, тарихи хакыйкать, мифологик фикерләүгә үк барып тоташа торган борынгылык, заманча фольклор һәм халыкчан юмор.

Мамадыш районы авылларында яшәп ятучы татар халкы вәкилләреннән тупланган фольклор материалларының кайберләрен сезгә дә тәкъдим итәбез.

МЕЖА АЖДАҺАСЫ НИНДИ УЛ?

(мифологик хикәят)

Тумгак башлы, олы авызлы, озын койрыклы, елан шикеллерәк нәрсә булган ул аждаһа. Еланнан азган. Межа чокыры башында яшәгән. Яман авазлар чыгара торган булган. Бервакыт җилләп-давыллап бәк каты яңгыр яуган. Шуннан ак болыт бөтерелгән ул чокыр өстендә. Аннары яңгыр койган. Чокыр өстендәге теге болыт Аждаһаны алырга дип килгән болыт икән. Межа башы аждаһасын бөтереп-бөтереп үзенә суырып алган.

Авызыннан утлар өргән аждаһа, киткән вакытта, җирне көйдереп киткән. Авыл кешеләренә зыян китергәне-китермәгәне турында сөйләмиләр аның. Ак болыт суырмаган булса, зыян да итәсе булгандыр, ул бөтен нәрсәне дә йота торган булган бит.

Межага барырга курка торган иек. Аждаһа кабып йотар дип. Кап-караңгы тирән чокыр булган ул Межа чокыры. Еланнары белән мыжлап торган. Шул еланнар башта юхага, аннан соң аждаһага әйләнә, дип сөйлиләр ие.

Зарипова Сөембикә Гыйлемхан кызыннан (1938 елгы, Күчтем авылы) язып алынды.

«ДЕРЕВЯНКА, ЖЕЛЕЗЯНКА, РЕМЕШОК»

(мәзәк)

Безнең авылдан армиягә киткән берәүдән имтихан алалар икән. Ату коралының нинди өлешләрдән торганын әйтеп бирергә кушалар моңа. Солдат әйткән:

– Өч частьтан тора, – дигән.

– Нинди частьлар инде ул?

Чынлыкта коралның ствол, затвор, предохранитель һ.б.лардан торганлыгы турында бернәрсә дә белми икән бу. Коралны күргәне, кулына тотып караганы булса да, техник яктан белеме булмаган моның, корал өлешләренең исемнәрен шуңа атый алмаган. Аптырап калмаган үзе, оста җавап биргән:

– Деревянка, железянка, ремешок!

Түбән Ушмы авылында Ибраһимов Мөбәрәкша Ибраһим улыннан (1931-2013) язып алынды.

ТҮБӘН УШМЫ НИК ЧУКЫНДЫРЫЛМАГАН?

(тарихи риваять)

Чукындыручылар Югары Ушмыга чаклы килгәннәр. Югары Ушмыдан соң – Күчтем. Чукындыру чорында Күчтем әле булмаган. Аннары – Түбән Ушмы. Югары Ушмыга хәтле килгәннәр тегеләр. Авылы-авылы белән чукындыра килгәннәр. Әнә Чия башы – тоташ керәшеннәр, Әҗмәкнең яртысы чукынган. Ишки – олы авыл, аңа кагылмаганнар. Сәртек – бәләкәй авыл булса да, урман кырыендагы авыл, шунда кереп качканнар, чукынмаганнар. Бүгенге көндә Югары Ушмы – татар авылы. Әмма анда да чукындырулар булган. Шәмси абый сөйләде: 50 нче елларда болынга печән чабарга барганда бер керәшен карты утырып барган боларга. Керәшен Пакшыныннан икәнен әйткән. Малмыжкага баруы икән. Шул сөйләгән борынгы бабаларының Югары Ушмыныкылар булуын. «Шунда безнең әби-бабаларыбызны чукындырганнар. Икенче исемнәр биргәннәр. Кайсы кешеләр урманга качкан чукындырудан. Чукындыручылар киткәч, чукынган халык бу татар авылында калмаган, Пакшинга күчкәннәр. Әби-бабаларыбыз тумышлары белән Югары Ушмыныкы булып чыга», – дип сөйләгән. Керәшен Пакшины диләр инде ул авылны.

Югары Ушмыга хәтле килгән чукындыруның Түбән Ушмыга зыяны тимәгән. Түбән Ушмы ул чагында олы юл өстендәге көчле, зур авыл булган. Халкы бик гаярь. Кара баганалы авыл булган ул. Авыл Краснай ягыннан Тимер атавыннан (оста тимерчеләр династиясе яшәгән атау) башланып, Күчтемгә таба Беренче күпергә хәтле сузылган элек. Озынлыгы өч чакрым булган. Мең душлы Ушмы, дигәннәр. Әле меңнән артып киткән чаклары да булган.

Алай да чукындырып йөрүчеләр бер кагылган безнең авылга. Шулай дип сөйлиләр. Авылга килеп кергән чукындыручыларны Түбән Ушмылылар кыйнап үтергән. Чокыр казып, күмеп тә куйганнар тегеләрне. Авылдан читтә күмгәннәр. Артларыннан эзләп килүчеләр сораган:

– Шундый-шундый кешеләр йөрдеме монда, күрдегезме? – дигәннәр инде.

Түбән Ушмылар:

– Күрдек, фәлән-фәлән төстәге фәлән чаклы кешеләр керде монда, – дигәннәр.

– Кая алар?

– Әнә, тегеләй таба киттеләр алар, – дип, Түбән Ушмы юнәлешеннән кыйбла якка таба төртеп күрсәткәннәр (информант Керәшен Пакшины, Омар, Сәкәнәс ягына – керәшен, урыс авыллары ягына таба кулын болгап күрсәтә. – Л.М.). – Шуннан эзләгез кирәк кешеләрегезне, – дигәннәр.

Бүтән чукындырырга дип килеп борчымаганнар Түбән Ушмыны.

Түбән Ушмы авылында Мөхәммәтханова Флёра Зиннур кызыннан (1939 елгы, тумышы белән Мамадыш районы Ишки авылыннан) язып алынды.

УМАЙ УТЫРТУ ЙОЛАСЫ

Умай утырта торганнар ые элек. Бәби тапкан хатынның, умае утырсын өчен, эчен сыпыралар. Шул умай утырту була. «Умае утырсын!» – дигәннәр. Умай – бала ята торган аналык инде ул. Умай утырта торган кендек әбиләре бар ые. «Умаең утырсын, балакаем!» – дип, эчне сыпыра, юындыра торган ые.

Кече Кирмән авылында Шакирова Зәйнәп Әбделмәүли кызыннан (1912 елгы) язып алынды.

ИЯЛӘР ТУРЫНДА

Һәрвакыт ияләрне искә алу, аларны әйтеп дога кылу кирәк. Йорт иясе бар ул. Үзем күргәләдем. Кеше сыман шәүлә инде ул. Ия, риза булмаса, куркыта башлый, тынгысызлый. Болай тими ул кешегә бервакытта да. Бисмилла әйтеп укысаң, тыныч алар.

Абзар иясе малыңны яратмаса, маллар шыбыр тиргә баткан була. Кайбер сарайга сарык батмый, йә күҗә батмый, сыер батмаска да мөмкин. Бу – ияләр яратмаганга.

(Чәй артыннан кычкырып озаклап кылган догасында информант «Йорт ияләренең тынычлыгы өчен» – дигән сүзләр дә әйтте. – Л.М.)

Көмеш Күл авылында Сәмигуллина Нурфия Габдулла кызыннан (1958 елгы) язып алынды.

ТУЙ ЙОЛАСЫ

Хәзер никах төрлечә була: егет ягында да уздыралар, кыз ягында да. Кем ничек. Элек болай иде: егет кызны алып кайта, икенче көнне мулла чакырып, егет ягында никах укыталар. Кызны җомгага каршы көндә алып кайталар. Алып кайткан көнне кыз егетнең анасы белән куна. Икенче көнне – никах, никах укылгач, никах мунчасына җибәрәләр өйләнешүче яшьләрне. Гел шулай булган.

Кызны алып кайткач, берәү, өйгә алдан кереп, әйтә:

– Парлап кайттык! – ди. Шуннан соң өйдә көтеп торучылар булачак киленне каршы алырга чыга, кайтучыларны өйгә чакыралар. Кыз кергәндә тупсаның эчке ягына мендәр куялар. Егет өенә атлап кергән кыз ике аягы белән дә мендәргә баса. Моңа булачак каенана әйтә:

– Төкле аягың белән! Исән-имин яшәргә язсын! Йомшак басып йөрер өчен дип салдым мендәрне.

Бал белән май каптыра кызга:

– Балдай тәмле телле бул! Майдай эре! – ди.

Кече Кирмән авылында Шакиров Ринат Закир улыннан (1947 елгы) язып алынды.

АВЫЛ КӨЕНӘ ҖЫРЛАР

Түбән Ушмы, Югары Ушмы,
Уртасында – Ник күчтем.
Йөрәгемнең януына
Әрем кайнатып эчтем.

Кала Ушмы, Кала Ушмы
Зират таулары белән.
Армиягә барсаң иде
Сөйгән ярларың белән.

Тезелеп кайта сабанчы,
Тезелеп кайта сабанчы,
Сайрый сабан тургайлары,
Шул чакларда ямансу.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ясәви,
Теләмәгән агачына
Кошлар да оя ясамый.

Түбән Ушмы авылында Мөхәммәтҗанов Җиһанша Мөхәммәтҗан углыннан (1929 елгы) язып алынды. ■

Хозыр Ильяс булсын юлдашың!

Гүзәлия Хаҗиева

Хозыр Ильяс образы татар фольклорында, әдәбиятында, халык традицияләрендә үзәк урынны алып тора. Әлеге образның, җирле халык традицияләрендә билгеләнгән үзенчәлекләреннән тыш, төрки дөньяда да аерым урыны бар. Төрки контекстта бу образ бер нигезгә барып тоташса да, һәрбер төрки культура аны үзенчә яктырта һәм үзенең колоритына якынлаштырып реконструкцияли.

Мөселман мифологиясендә Ильяс Библиядә чагылыш тапкан Ильяга туры килсә, Хызыр (Хозур) исә – мөселман мифологиясендә чагылыш тапкан персонаж. Ильяс һәм Хозырга хас булган үлемсезлек үзенчәлеге әлеге образларны берләштерә, шуңа күрә Хозыр Ильяс халык арасында бер исем белән аталып йөри. Хозыр Ильяс – аерым сыйфатлары һәм вазыйфалары белән кешегә хас үзенчәлекләрне туплаган антроморф мифологик образ. Җирле халык текстларында Хозыр Ильяс гайре табигый көчкә ия дип билгеләнә, ул төрле авырлыкларга очраган кешеләргә ярдәм итә.

Традицион татар мәдәниятендә Хозыр Ильяс образы татар халкының ырым, имтом жанрында очрый. Төрле көч-ияләрне үз ихтыярыңа буйсындырырга тырышу,

мәҗүси яки дини образларга мөрәҗәгать итү – ырым, им-томнарда кулланыла торган алым. Шуңа күрә халык, ырымның кодрәтен, тәэсир көчен арттыру өчен, Гайшә-Фатыйма, Искәндәр, Сөләйман пәйгамбәр (г.с.), Хозыр-Ильяс образларына һәм төрле әүлияларга мөрәҗәгать иткән. Татар халкының төрле җирле традицияләрендә Хозыр Ильяс исеме берничә вариантта билгеле: *Хөсер Илйас, Хөзер Ильяс, Кодырата, Кыдыр ата, Кодырата бабай, Хызыр Ильяс, Көзер Илйас, Гөзер Ильяс*. Әлеге исемнәрне шартлы төшенчәләр буларак карарга кирәк, чөнки һәрбер җирле культурадагы төшенчә үзенчәлекле сыйфатка ия була. Әлеге сыйфатлардагы, исемнәрдәге вариативлылык образның бөтенлеген бозмый, ә киресенчә, әлеге сыйфатлар билгеле бер бәйләнеш-мөнәсәбәттә торып, образның халык традициясендә реконструкцияләгән күзаллавын булдыра. Төрки халыкларда да әлеге исемдә вариантлылык күзәтелә: *Хызыр Нәби, Хызыр Ильяс, Хызыр Зәнди, Хызыр Әлләрәз*. Җирле сөйләшләрдә Хозыр Ильясның исеменә ата яки бабай дигән олылау сүзләре кушылып языла.

Нигездә бөтен төрки культураларда да Хозыр Ильяс авырлыкка төшүчеләргә ярдәм итүче серле юлчы, бүләкләүче яки җәза бирүче буларак күзаллана. Шуңа күрә халыкбыз телендә «*хозыр ильяслык*» гыйбарәсе яхшы эшләр мәгънәсендә йөри. Татар культурасында Хозыр Ильясны юл иясе дип тә атап йөртәләр. Өйдән чыкканда, хәерле юл теләгендә әйтелә торган теләк-багышлау сүзендә Хозыр Ильяс образы искә алына: әстер. «*Балаларыбыз-кардәшләребез кайда йөреп торсалар да Хөзер Ильяс йулдашы булсын, бәла-казаларсыз йөрмәгә нәсиб ит, йарабби*»; «*Чыккан юлың йул булсын, малың-мөлкең күп булсын, Хызыр Илйас йулдаш булсын!*»; *Кайда йөрсәң, кайда торсаң да Хөсер Илйас йулташың булсын*». Башкорт телендә дә Хозыр Ильяс юл күрсәтүче, юлдаш образы буларак күзаллана: «*Рәхмәт, юлыңа Хызыр Ильяс юлдаш булһын!*». Кайбер ышануларда юлга чыкканда хәвеф-хәтәрдән саклану өчен Хозыр Ильяс исемен телгә алу кирәклеге әйтелә.

Хозыр Ильяс халыкның җирле текстларында афәттән, чирдән коткаручы буларак та сурәтләнә: «*Кан чире таралган еллар. Шулвакыт каяндыр таныш түгел бер бабай килеп чыкты. Ап-актан киенгән, таягы да бар иде. Ул безгә: «Чирдән курыкмагыз. Чалмалы авылы изге җиргә урнашкан, чир бу якларга килмәс», – дип әйтте һәм кинәт юк булды. Без озак аптырап тордык. Бу бабайны Хызыр галиәссәләм, дип уйладык*».

Шулай ук Корьән ашларында, бәрәкәт сорап, Хозыр Ильяска дога кылалар: «*Ашларыгыс ашсын, табакларыгыз ташсын, нәнтәй күзәл ашларыгыс, йөскә йетсен йәшләрегес. Пәрәкәт бирсен ашыгыска, тәүләт килсен каршыгызга. Кысыр Ильяс, Кысыр Нәби оцоп килсен каршыгыска*».

Мифологик персонажның кыяфәте халык текстларында тулысынча ачылып бетми, портрет характеристикасы тулысы белән чагылыш тапмый. Хозыр Ильясның портретына кагылышлы бары тик бер билгегә яки хәрәкәтендәге билгеле бер үзенчәлеккә генә игътибар ителә. Халык текстларында Хозыр Ильяс олы яшьтәге бабай буларак күзаллана: «*Таныш түгел бер бабай килеп чыкты*». Кыяфәтенә килгәндә, Хозыр Ильяс ак киемнән («*Кодырата киләде, ак кийем кийәде*»), яшел чапаннан («*Кодыртата йәшел чапан кийә*»), таягы («*Кодыратаның таягы да йәшел була*») булган карт рәвешендә сурәтләнә. Нигездә җирле текстларда Хозыр Ильяс ак киемнән тасвирлана: «*Хозыр Ильяс ак киемле, ак чапанлы була*». «*Ап-актан киенгән, таягы да бар иде*». Кайбер җирле вариантларда Хозыр Ильясның ак алъяпкычы турында да әйтелә: «*Хөзер Ильяс ак запун алъяпкыч бәйләгән була, диләр*»). Хозыр Ильясның атрибуты – аның таягы, камчысы. Ул камчысын селкесә, димәк, барысы да яхшы була: «*Көн кояшлы, матур булса, әйтәләр: «Бүген Хөзер Ильяс камцысын селеккән», – дип*». Хозыр Ильяс камчысы яман көчләрдән саклау атрибуты буларак та карала. Камчы

яман көчләрдән саклау ритуаль вазыйфасын башкарса, *камчы селку* ритуаль хәрәкәте исә яман көчләрне куркыту мәгънәсенә барып тоташа.

Тышкы кыяфәтендә аның күзгә күренми торган үзенчәлеге күрсәтелә: «*Кодырата бабай булган, ул кешегә күренми торган булган*». Халыкның җирле телендә Хозыр Ильясның кулларына да игътибар бирелә: «*Аның куллары сәвәксез булган, мамык кебек йомшак булган*». Азәрбайҗан этнографик текстларында Хозыр Ильясның бармаклары сөяксез булуы һәм йомшаклыгы ассызыклана. Хыдрреллез бәйрәмендә барлык кешеләрнең дә кулларын тотып исәнләшү Хозыр Ильясны очрату нияте белән башкарылган.

Мифологик персонажны өйрәнүдә аның яшәү урыны, билгеле бер җирдә пәйда булуы яки кеше белән сөйләшү урыны да әһәмияткә ия. Мәсәлән, Хозыр Ильяс еш кына кырда йөри: «*Кырда Хызыр бабай йөри инде. Дога кылырга кушалар баргач та*». Шуңа күрә кырга чыккан кешегә Хозыр Ильяс ярдәм итә, дигән ышану яшәп килә: «*Кырда – Кыдыр бабай булсын ярдәмчең!*». Шулай ук халык текстларында Хозыр Ильясның йөри торган юлы, сукмагы барлыгы да күрсәтелә: «*Буразнаны, ызанны сукаламагыз, әйбер чәчмәгез, ызан – ул Хозыр Ильяс бабай җөри торган җул, – диләр*»; «*Ызан ул – Хозыр Ильйас бабай җөри торган җул*».

Мифологик персонажның пәйда булу вакыты да әһәмияткә ия. Халык традицияләрендә Хозыр Ильясның җомга көнне сәяхәт итүе турында әйтелә. Шуңа күрә халыкта җомга көнне Хозыр Ильяска дога кылу киң таралган: «*Җомга көн йори торган Гозер Илйас галиәссәләмне күрдем*»; «*Аныңга дога кылырга тейешбез, йомга көннәрне айәт укырга тейешбез*».

Төркиядә Хозыр Ильяс белән бәйле Хыдрреллез бәйрәмен үткәрәләр. Әлеге бәйрәм язга кергәндә, дөнья яшеллеккә төренгән чорда үткәрелә. Бу бәйрәм Хозыр Ильяс культы һәм аның белән бәйле ышануларның үсеш-үзгәрешенә барып тоташкан. Төрки халыкларда әлеге бәйрәм төнендә теләк теләп, авыруларның сәламәтләнәчәгенә, язмыш офыкларының ачылачагына, муллык-бәрәкәтнең артачагына ышану белән бәйле йолалар үткәрелә. Төрек телендә *Hızır gibi yetişmek* (Хозыр кебек вакытында килеп җитү) әйтеме кирәкле вакытта ярдәмгә килү дигән мәгънәне аңлата. Азәрбайҗан культурасында Хозыр Ильяс яки Хозыр Нәби бәйрәме дип үткәрелә торган бәйрәмдә ишек тупсасына он яки сөт кебек ризыклардан «*Хозыр өлеше*» куела. Хозыр Ильяс турындагы ышану-йолалар төрки халыкларда мәшһүр бер феномен булып тора. Ул халык әдәбиятында һәм суфичылык тарикатендә үлемсезлек символы белән тиңләштерелгән, төрле кыяфәтләрдә пәйда булып, кешеләргә ярдәм итә торган, муллык һәм бәрәкәт бирүче мифологик образ буларак күзаллана.

Шулай итеп, Хозыр Ильяс – халык традицияләрендә Корьән сюжетлары нигезендә үстерелеп, халык фантазиясе аша этномәдәни тирәлегенә, яшәү рәвешенә үтеп кереп, халыкның ышану-йолаларында, җирле телендә чагылыш тапкан, халыкның мәдәниятенә, рухына җавап бирерлек, аның чынбарлык һәм хыял дөньясындагы карашын чагылдырган образ. Бүгенгәчә халыкның җирле традицияләрендә сакланып калган Хозыр Ильяс образы, аның атрибутлары, сыйфатлары, мотивлары халыкның җанлы һәм җансыз объектларын үзара тиңләштерү, берләштерү максатын үтәп, халык текстлары поэтикасында аеруча калку булып күтәрелеп, теләккә ирешүдә ярдәм итәргә тиешле исем ролен үтиләр. Хәзерге вакытта да халыкның җирле сөйләшләрендә «юл иясе» дип аталып йөртелүе Хозыр Ильяс культының беренчел мифологик һәм архаик үзенчәлекләрен югалтмаганлыгын ассызыклый. ■

БЕЛЕМ АЛУ ТАРИХЫБЫЗДАН...

Илфар Габдрахманов

Татар милләтенең аң-белемгә тартылуын, Россия империясе чорында иң укымышлы булганлыгын раслап, күп язмалар, хезмәтләр дөнья күрде. Халкымның элек-электән мәгариф өлкәсендә уңышлы эш алып барганлыгы – ул инде хәзер аксиома. Моны раслаучы документлар көн дә диярлек табылып тора.

Шәкертләр мәдрәсәдә. Түбән Новгород өлкәсендәге Кызыл Тау (Красная Горка) авылы. 1907 ел



Татар әлифбасы: Ә.Максуди җыентыгы (кульязма). XX гасыр башы

Татарстан Милли архивының 160 нчы фондындагы 1 нче эш кенәгәсе – шуңа ачык мисал. Татар милләте вәкилләре меңләгән авыр эшләрдә ничек изелеп торса да, аның укырга-язарга омтылганлыгын да ачык күрә алабыз. Мисал өчен, Лаеш өязендә 1912 елның 1 гыйнварында 78427 татар яшәгән, мәчетләр саны – 100. Аларда 73 имам-хатыйп, 39 имам, 2 мулла, 59 мәзин хезмәт иткән. Өяздә 69 иске ысуллы мәктәп, 14 иске ысуллы мәдрәсә эшләп килгән. Укытуда яңа алым кулланган 10 уку йорты исәпләнә. Бу чорда 7547 укучы булган, ягъни 81 балага 1 мәктәп туры килә. 1911 елгы мәгълүмат буенча, Лаеш өязендә 4 мәдрәсә, 52 мәктәп эшләгән. Алардагы 4659 малай һәм 2817 кызга 95 ир-ат укытучы һәм 26 хатын-кыз белем биргән. 140173 урысы булган Лаеш өязендә 15316 балага 130 уку йорты исәпләнә, ягъни 1078 кешегә, 117 балага 1 белем бирү учагы туры килә. Хәзерге Балык Бистәсе районы биләмәсенең мөселман-татар авылларының барсында да уку йортлары булган. Таулар авылында мәктәп 1860 елда ук ачылса, Югары Тегермәнлек авылында беренче мәдрәсә 1890 елда эшли башлап, 1895 елда аларның саны 3кә җиткән, ә Күгәрчен авылында 3 мәдрәсә һәм бер рус-татар мәктәбе эшләп килгән. Күрше Мамадыш районына кергән Түбән Сөн авылында мәктәп 1780 елда ук булганлыгы билгеле.

1914 елгы мәгълүмат буенча, Казан губернасында 786595 мөселман татар яшәгән. Шуларның 70272се – укучы балалар. Губернабызда 1009 мәктәп, 37 мәдрәсә, 66 рус-татар мәктәбе исәпләнгән, барлыгы – 1112 уку йорты. 63 балага 1 мәктәп туры килә! 1914 елда тагы 30 уку йорты ачылырга тиеш булса да, бу сан бермә-бер кими. Тагы шунсын да искә алырга кирәк, укучы балаларыбыз дигәнгә 8-9-10 яшьлекләр генә керә. Тулаем алганда, барлык уку яшендәгеләр белем алганнар булып чыга да инде. Казан губернасының Мамадыш өязендә иң күп татар яшәгән (148923), 13391 балага 131 мәктәп, 2 мәдрәсә, 13 рус-татар мәктәбе хезмәт күрсәткән. Казан өязендә 143358 мөселман гомер итеп, шуларның 12920се – укучы балалар. Алар 207 мәктәп, 5 мәдрәсә һәм 7 рус-татар мәктәбендә белем алган, ягъни 59 балага 1 мәктәп туры килә. Тәтеш өязендә 120000 татар, 10800 укучы, 257 уку йорты (42 балага 1 мәктәп!). Калган өязләрдә мондый саннарны китерәсе килә: Лаеш өязе – 74526 татар, 6705 укучы, 99 мәктәп; Зөя өязендә – 50000 татар, 4500 укучы, 54 мәктәп; Спасста – 55559 татар, 5000 укучы, 89 мәктәп; Чистай өязендә – 102841 татар, 9256 укучы, 136 уку йорты; Козьмодемьянда – 42 татар, 4 бала, мәктәп юк; Царевококшайскийда – 28000 татар, 2520 укучы, 46 белем алу учагы; Цивильск өязендә – 18346 татар, 1650 укучы, 25 уку йорты; Чабаксарда – 5000 татар, 450 бала, 4 мәктәп; Ядринда исә татарлар яшәгәнлеге турында мәгълүмат юк.

Әйтеп киткәнемчә, һәр мөселман-татар авылында XX гасыр башында мәктәпләр булган. Аларның тулы исемлеген, кайчан ачылганлыгын һәм анда кемнәр укытканын Татарстан Милли архивының 1 нче фондының 4 нче тасвирламасының 3932 нче эш кенәгәсеннән белергә мөмкин. «О существующих в Казанской губернии татарских конфессиональных школах» дигән документ 1909 елның 30 июлендә тутырылган һәм ул 127 биттән тора. Кызыксынган кешеләргә, бигрәк тә мәктәп директорлары һәм тарих укытучыларына, мәктәп ачылу тарихын тәгаен ачыклар өчен, әлеге чыганакка мөрәҗәгать итәргә киңәш итәр идем. Шул ук архивның 160 нчы фондындагы 1 нче тасвирламаның 1441 нче эш кенәгәсендә дә авылларыбыздагы мәктәпләр буенча мәгълүмат китерелә.

Мәктәп-мәдрәсәләрнең күбесе, чынлыкта, патша идарәсе рөхсәтеннән башка эшләргә мәҗбүр булган. 1870, 1874, 1875 елгы күрсәтмәләр буенча, татарлар бары тик рус классы булган очракта гына мәктәп ачу рөхсәте ала алганнар. Шуның белән бәйле рәвештә, халык училищелары ачыла башлый. 1911 елның 14 февралендә аларның

саны: Казанда – 13, Казан өязендә – 15, Козмодемьян өязендә – 79, Лаеш өязендә – 10, Мамадыш өязендә – 32, Зөя өязендә – 1, Спасста – 11, Тәтештә – 25, Царевококшайскийда – 39, Цивильскида – 41, Чабаксарда – 49, Чистайда – 40 һәм Ядринда – 49га җитә. Рус-татар мәктәпләрендә 70тән артык дәреслек белән укытканнары билгеле. Шулар арасында Р.Фәхреддин, Х.Фәйзуллин, Р.Хәнәфи язган уку әсбаплары да бар. Китапларның күбесе, әлбәттә инде, дин укыту белән бәйле булса да, араларында география, Русия тарихы, әхлак, чит телләр белән бәйлеләре дә булуы игътибарга лаек.

Татар халкының белемле булуы рус түрәләренә ошамаган, күрәсең. Архив документлары арасында 1910 елның 10 августына караган язма бар: «В ответ на многочисленные ходатайства татар-мусульман о разрешении им открывать при мечетях мектебе для обучения детей мусульманскому вероучению, я каждый раз разъясняю просителям, что мектебе и медресе могут разрешаться к открытию только при условии учреждения при них русских классов», – дип яза халык училищелары директоры Пинегин. Шунсын истә тотарга кирәк, 1905-1906 елгы революция чорында бу карар юкка чыгарыла. Шуңа күрәдер дә инде, татар авылларында мәктәп ачарга теләүчеләрнең саны арткан­нан-арта бара, һәрбер мәхәллә каршында уку йорты ачыла. Пинегин икенче бер документта болай дип яза: «По моему мнению, вопрос об открытии мусульманских учебных заведений имеет в настоящее время два решения, основанная на существующих законоположениях: 1) Так как по смыслу законов 20 ноября и 5 февраля 1882 года под медресами и мектебами подразумевается конфессиональные магометанские учебные заведения, то я со своей стороны полагал бы, что мусульманские училища (мектебе и медресе), учреждаемые при мечетях с целью изучения мусульманской религии, без общеобразовательных наук, можно разрешать открытию без обязательства для учредителей иметь русские классы; 2) Но ввиду того, что в последнее время под теми же названиями медресе и мектебов мусульмане стали открывать уже не исключительно конфессиональные учебные заведения, а скорее всего общеобразовательные школы, с обучением в них, кроме религий, еще арифметику, геометрию. историю, географию, естествознание и прочие, то необходимо предъявлять требования об образовательном обучении в них русского языка».

Моннан күренгәнчә, татарлар өчен ачылган мәктәпләрдә XX гасыр башында дөньяви фәннәргә дә зур игътибар бирелә башлый. XIX гасырда төп фән дин булса, хәзер инде хәл үзгәрә: мәктәп-мәдрәсәләрдә – арифметика, геометрия, география, тарих кебек фәннәр дә укытыла башлый. Шулай булгач, татар әби-бабаларыбыз башка халыкларга караганда белемлерәк була һәм бу урыс җитәкчеләренең эчен пошыра. Рус телен укытуны кертү мәктәпләрнең ачылуына чикләү булыр иде, чөнки аны барлык укытучылар да укыта алмый. Моның өчен аерым рөхсәт алырга, имтихан тапшырырга кирәк була. Архив документларының берсендә шулай язылган да инде: «...обучением в мектебе и медресе могут заниматься только русские подданные, получившие на то разрешение участкового инспектора народных училищ...» (160 нчы фонд, 1 нче тасвирлама, 907 нче эш кенәгәсе).

Нинди генә чикләүләр кертергә теләсәләр дә, моннан 100 ел элек мәктәпләр һәм мәдрәсәләр күпләп ачылган, барлык балаларга белем алу мөмкинлеге тудырылган, уку йортлары өчен аерым биналар төзелгән. Кызганыч ки, 1914 елда Беренче Бөтендөнья сугышы башланып, 1917 елда хакимияткә большевикларның килүе, Гражданнар сугышы һәм 1920 еллардагы ачлык милләтебез үсешенә зыян китергән. Бу вакыйгалар булмаса, хәзерге хәлгә төшмәс, миллионлаган татар үз ана телендә белем алудан мәхрүм ителеп, татарча язу түгел, хәтта сөйләшә алмас дәрәҗәдәге гарьлеккә төшмәс идек... ■

ТАТАРСТАН ҖӨМҺҮРИЯТЕ АВЫЛЛАРЫНДАГЫ ҖӘЙГЕ ЭШ КҮРЕНЕШЛӘРЕ

«Бу рәсемнәр Татарстан матбугат-нәшрият комбинаты тарафыннан рәсемнәр алу өчен махсус Арча кантонына җибәрелгән фотограф Габделхәмид иптәш Апанаев тарафыннан татар авылларында алынган».

«Безнең юл». – 1925. – №7-8. – Б.303.

Кайту

Фоат Уразай

Рашат Сафин интервью бирә

Киткәннәр генә кайта ала. Әмма бу һәр киткәннең дә кире әйләнеп кайтуын аңлатмый әле: ярты юлда адашып калучылар, үтеп булмаслык киртәләргә юлыгучылар яисә кире кайтырга теләмәүчеләр дә булырга мөмкин бит. Бу очракта сүзебез – кайтыр өчен киткәннәр хакында. Ә илаһи күчешнең мондый төре аерым шәхесләргә генә түгел, милләтләргә дә хас. Әлбәттә, сүз биредә бәрәкәт белән кайту турында бара. Шунысы да бик мөһим: китүләрне язмыш билгеләгән кебек, андыйларның кайтуы да тәкъдирдән...

***

Яшәешнең фанилыгы һәм китү-кайту әйләнеше белән бәйле мондый уйланууларга нәрсә этәрде соң әле болай? Ә сәбәбе, чыннан да, уйландырырлык һәм ул милләт яшәешендә шәхеснең тоткан роле белән бәйле. Сүзебез татарның фидакарь улы, узган гасырның 90 нчы елларында милли хәрәкәтне җанландырып җибәрүдә зур роль уйнаган зыялыларыбызның берсе, татар алгарышы теоретигы һәм философ, зур хезмәтләр калдырып, 2016 елның 27 ноябрендә бакыйлыкка күчкән күренекле шәхес Рашат Сафин турында. Аның арабыздан китүен күпләр белми дә калды һәм, гомумән, татар халкы

кемне югалтканын әлегә бик аңлап та бетермәде кебек. Чөнки Рашат абый, гәрчә үзе татар язмышын төрле яктан анализлауга багышланган фундаменталь хезмәтләр язып, милләт алгарышының эзотерик (эчке, тирән мәгънәле) фәлсәфәсенә нигез салган зат булса да, шәхси тормышта тыйнак булып кала белде һәм бернинди дәрәҗә яки даншөһрәт артыннан кумады. Шуңадыр, соңгы юлына да ул бик тыйнак кына китеп барды.

Татар милләтендә талант ияләре һәм тирән фикерле шәхесләр шактый. Әмма милли, дини, фәлсәфи, геосәяси һәм метасәяси (илаһи яшәешкә күчү сәясәте) өлкәләрне колачлаган эшчәнлеге һәм дә үзенең фикерләү колачы ягыннан Рашат Сафин дәрәҗәсендәгеләр күп түгелдер. Шагыйрь сүзләре белән әйтсәк, андыйларның зурлыгын вә фикри колачын күрү өчен ераккарак китеп карарга кирәк. Алай да, кем соң ул Рашат Сафин? Аның тормыш юлы нинди? Алдынгы карашлы, киң эрудицияле, тирән анализга сәләтле һәм милләтпәрвәр шәхес булып формалашуының сере нәрсәдә? Моны аңлау өчен, кыскача гына булса да, ошбу фидакарь затның биографиясе белән дә танышып үтик.

Рашат Габделбәр улы Сафин 1934 елның 14 июнендә Татарстанның Кукмара районында туган. Чыгышы белән – ахуннар нәселеннән. Әтисе фронтта һәлак булгач, абыйсы һәм сеңлесе белән, әнисе Бибиләбибә Газизҗан кызы тәрбиясендә үсә. Кукмарада урта мәктәпне тәмамлагач, укуын Чиләбедәге хәрби училищеда дәвам итә. Аны 1955 елда тәмамлап, офицер дәрәҗәсе ала. Соңрак ул Мәскәү политехник институтын да тәмамлый. Армия хезмәтен Саранск, Потсдам (ГДР), Ашхабад, Ташкент, Сәмәрканд калаларында һәм Кара Ком чүлендә үтеп, 1985 елда Сызрань каласындагы соңгы хезмәт урыныннан полковник дәрәҗәсендә запаска чыга. 1988 елдан татар милли хәрәкәтендә ныклап катнаша, Татар иҗтимагый үзәген оештыручыларның һәм аның тәүге җитәкчеләренең берсе. Татарстанның хәрби доктринасы авторы буларак, 1993 елда НАТО штаб-квартирасында (Брюссель) узган сөйләшүләрдә ТР делегациясе составында катнаша. 1998 елда бер төркем зыялылар оештырган «Татар юлы» җәмгыятенең рәисе итеп сайлана.

Биографиясенә бәйле рәвештә, Рашат Сафинның холкына, милли җанлы һәм нык ихтыярлы шәхес буларак формалашуына кагылышлы кайбер детальләргә дә тукталып алыйк. Язган хезмәтләренең берсендә ул үзенең милләт язмышын кайгырткан эзләнүләре әүвәл балаларча беркатлылык дәрәҗәсендә, мәктәп интернатында торган 9-10 сыйныф укучыларыннан җыелган милли оешмада башлануы, ә еллар үтеп, сәяси мөмкинлек тугач, җитди һәм фәнни нигездә формалашкан Татар иҗтимагый үзәгендә дәвам итүе турында искә ала. Армиядә чакта аның кул астында булган хезмәттәшләренең сөйләгәннәре дә кызыклы: алар Рашат абыйны нык ихтыярлы, гадел, әмма каты куллы командир буларак хәтерли һәм үзара аны «Жуков» дип йөртүләрен дә искә төшерә. Урта Азиядә хезмәт иткәндә, ул чакта әле майор Сафин яшерен хәрби объект төзелешенә дә җитәкчелек итә. Төзелеш эшендәге тырышлыгы өчен аңа «Үзбәкстанның атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Күбрәк әни тәрбиясендә үскәнгәме, Рашат абый әнисен еш һәм зур җылылык белән искә төшерә иде. Армиядә чакта да ул аның төшләренә еш кергән. Кайчакта төшендә әнисе белән урысча сөйләшкәнен аңлагач, йокыдан торуга ук татарча граммофон тәлинкәләре тыңлап, еллар дәвамында татарча китаплар укуга күчә торган була. Шөкер, әнисе аның озын гомерле булды, йөзгә якынлашып, Ак әби булып, бакыйлыкка күчте. Һәр икесенең дә урыннары оҗмахта булсын.

Рашат абыйның хәрби хезмәттән китү тарихы исә аерым игътибарга лаек. Алдарак әйтелгәнчә, аның хәрби хезмәттәге соңгы еллары Сызрань каласында уза. Ул чакта инде полковник Сафинны хәрби база җитәкчесе итеп билгелиләр. Бу вазыйфа хәрби

чин буенча полковник яки генерал дәрәҗәләренә туры килә (армиядә андый вазыйфаларны «вилочная должность» дип йөртәләр). Гадәттәгечә, полковник Сафин озакламый әлеге хәрби базада да чын хәрби тәртип урнаштыра. Тиздән аның генерал-майор дәрәҗәсе бирелүгә лаек булуы турында Мәскәүгә представление юллана. Әмма анда ул кире кагыла. Рәсми булмаган каналлар аша, соңыннан моның сәбәпләре дә ачыклана. Аларның берсе – полковникның милләте. Рашат абый үзе моны тәкъдир кушуы буларак кабул итә һәм хәрби хезмәттән китәргә карар кыла. Аны тагын берничә елга калырга кыстап карасалар да, үз сүзендә нык тора. Шулай итеп, катлаулы тормыш юлы үткән һәм ныклы аң-белем дә туплаган полковник, яшьлегендә тәүге адымнар ясаган милли хәрәкәткә инде җитлеккән көрәшче буларак әйләнеп кайта.

* * *

Шәхсән үземнең Рашат абый белән танышып китү тарихына килгәндә, беренче тапкыр без аның белән 1990 елның көзендә Казанның 1 Май мәйданында очраштык. Ул, Татар иҗтимагый үзәге рәистәше буларак, Казанга РСФСР Югары Советы Рәисе Б.Ельцин килүе уңаеннан, анда пикет оештырып йөри иде. Минем исә, хәрби хезмәттән запаска китәр алдыннан, Казанга соңгы ялымны үткәрергә кайткан көннәрем. Берберебезне тиз аңладык, ул хәтта Б.Ельцин җәмәгатьчелек вәкилләре белән үткәргән очрашуга чакыру кәгазе дә бирде. Борис Николаевич нәкъ менә шунда әйтте дә инде үзенең тарихка кереп калган: «Суверенитетны күпме үзләштерә аласыз – шуның кадәр алыгыз», – дигән сүзләрен.

Хәрби хезмәтемне тәмамлап, Казанга әйләнеп кайткач, язмыш инде безне милли хәрәкәт юлында озакка һәм нык итеп бәйләде. Татар иҗтимагый үзәге рәистәше һәм төп идеологларыннан берсе буларак, Рашат Сафин Татарстанның дәүләт бәйсезлеген хокукый вә гамәли яктан ныгыту өчен барган көрәшнең барлык этапларында да вакыйгаларның үзәгендә булды. Мәсьәләнең халыкара хокук нормалары белән генә чикләнмәвен, ә күпкә катлаулырак булуын һәм геосәясәткә дә барып тоташуын аңлагач, ул, урам сәясәтеннән бераз читләшеп, проблеманың теоретик ягына ныклап алынды. «Татар инануы» дигән хезмәтендә Рашат абый үзе бу хакта болай искә ала: «Әле хәрби хезмәтем вакытында ук гомум идарәчелек системасының бер отышлы мәсләген үзләштергән идем: вакытыңны вә энергияңне башкалар булдыра алган гамәлгә сарыф итмә, алар майтара алмаган (яки теләмәгән) эшләр белән шөгыльлән. Этник проблемалар турында язу нияте тугач, әлеге принципны истә тотып, милли хәрәкәтнең агымдагы сәясәтеннән читләшә төштем һәм татар язмышын анализлау һәм аның киләчәген фаразлау юнәлешендә эзләнә башладым».

Эзләнүләргә керешү сәбәпләрен автор үзе болай аңлата: «XX гасыр азагында, суверенитет кризисы тууы сәбәпле, милли хәрәкәттә дәүләтчелек идеясенә карата икеләнү туды. Дәүләти бәйсезлеккә омтылу – ялгыш юл, милләт максаты – рухи бәйсезлек, дип, сәяси мөстәкыйльлекне инкарь итүчеләр дә булды. Татарга боларның кайсысы кирәк: рухи бәйсезлекме, әллә дәүләтиме – иҗтимагый фикерләү шундый дилемма алдында калды. Башка милләтчеләр шикелле, мин дә аларга тиешле бәя эзләдем. Дөресен әйткәндә, мондый (йә берсен, йә икенчесен генә мотлаклаштырган) куелышта аларның берсе дә канәгатьләндерми татарны, чөнки милләт иминлеген аерым-аерым алар берсе дә гарантияләми».

Ә эзләнү нәтиҗәләре исә хәйран калырлык. Рашат абый ул чорда, һич арттырусыз, фәнни тикшеренү институтларының гына көченнән килердәй гаять катлаулы һәм зур тырышлык таләп итә торган эшне башкарып чыга алды. Нәтиҗәдә, татарның милли яңарыш теориясе яңа биеклеккә күтәрелде – ул милләт язмышына багышланган һәм

тирән эчтәлекле өч яңа хезмәт белән баетылды. Аларның беренчесе – «Татар юлы» (Татарстан китап нәшрияты, 2002) – яшәү тарихыбызны геосәяси яктан анализлауга багышланган. Икенче китапта – «Татар миссиясе» (Татарстан китап нәшрияты, 2006) – үткәнебез-киләчәгебез инде эзотеризм кысаларында тикшерелә. Хезмәтнең өченчесендә – «Татар инануы» (Уфадагы «Полиграфдизайн» ААҖ нәшрияты, 2014) – исә татар миссиясенең илаһи кануннарга нигезләнүе дәлилләнә һәм милләт язмышына анализ метафизик (дөньяның мәңгелек һәм тәҗрибә үткәреп булмый торган башлангычларын даими дип саный торган фәлсәфи тәгълиматка таянган) карашлардан чыгып ясала.

Автор фикеренчә, милләтне яшәтүче, аның җаны – милли мәдәният. Ә ул милләтнең яшәү җирлегенә һәм аның аңындагы психологик куелышка бәйле. Шуңа күрә беренче китабын ул милләт язмышының яшәү җирлегенә бәйле булган ягына һәм шуннан чыгып билгеләнгән идеягә («Татар күңеле – Далада») багышлый. Автор әйтүенчә, Дала хуҗасы – татар, һәм бу – тәкъдирдән (ягъни котылгысыз).

Икенче китапта инде сүз күбрәк татарның илаһи бурычы турында, авторча итеп әйтсәк, рухи омтылышыбызны гәүдәләндергән милли идея («Татар исламы») тирәсендә бара. Автор үзе билгеләп үткәнчә, алдагы яшәеш белән кызыксынучы шәхесләрне даими борчыган сораулар бар: Кешелек кая бара? Бүгенге глобаль кризис сәбәпләре нәрсәдә? Аннан чыгу юллары бармы? Татарның киләчәге һәм кешелек җәмгыятендә тоткан урыны нинди булыр? Аның үзен саклау, тәрәккыят кылу һәм хөрлеккә ирешү шарты нидән гыйбарәт? Бу дөньяга ул нинди миссия үтәү өчен яралтылган? Китапта автор әнә шул сорауларга җавап эзли. Аның фикеренчә, XXI гасырда глобальләшү идеологиясе исламга нигезләнә, ә аның гамәли өлгесен күрсәтү бурычы объектив рәвештә татарга йөкләнә.

Хезмәтнең өченчесе татар миссиясенең илаһи кануннарга нигезләнүен (ягъни аның объективлыгын-табигыйлыгын) искәртү вә дәлилләү ниятендә язылган, дидек. Ә нидән гыйбарәт соң ул миссия? Автор аны мөселман дөньясын мөшриклектән арындыруда һәм кешелекне Күк аңы халәтенә ирештерүдә Аллаһ тәкъдирен реальләштерү тырышлыгында күрә. Бүгенге традицион исламны ул адәми-империячел сәясәт аша гарәпләштерелгән җәмгыяви бертөрлелек берлеге (асылда, гарәп исламы) буларак бәяли. Татар исламы исә, динебезне әлеге уйдырмалардан вә мөшриклектән арындырып, Рәсүлебез заманындагы сафлыгына кайтарган (ягъни вакыт-пространство таләпләрен исәпкә алган) һәм илаһи тәгълиматка нигезләнеп формалашкан гомумкешелек цивилизациясе (ягъни илаһи ислам – җәмгыяви күптөрлелек бердәмлеге). Фикерен дәвам итеп, ул: «Татарга ислами мәдәният һәм Рәсүлебез тәгълиматын заманча аңлату сәләте бирелгән икән, бу – Аллаһтан һәм тикмәгә түгел. Димәк, без пәйгамбәрлек-нәбилек вазыйфасын үтәүгә сыналабыз», – ди.

Автор фикеренчә, дин, җәмгыяви институт буларак, халыкны илаһи кануннар кысаларында тоту (кавем Аллаһтан аерылмасын, эволюцион сәяхәтендә адашмасын) өчен кертелгән. Шуның белән бергә, ул һәрчак адәми-сәяси ихтыяҗга да хезмәт иткән. Кешенең рухи үсеше (Аллаһка кайтуы) исә җәмгыяви тәрбия аркылы тәкъдирләнгән. Аллаһ аны яралтылышта бертөрлелекне күптөрлелеккә җибәрү (инволюция) һәм яңадан элекке хәленә (бертөрлелеккә) кайту (эволюция) шәкелендә ниятләгән. Китү-кайту циклында кешегә, авырын да, җиңелен дә кичереп, фанилыктагы яшәү шартларының төрлесен үтеп, акылын үстерергә, дөнья төзелешен вә илаһи кануннарны (табигать законнарын да) өйрәнергә һәм, шуларның нәтиҗәсе буларак, аңын камилләштерергә тәкъдир кылынган. Китү-кайту циклы Акыл эрасына кергәч, бу инде җәмгыяви ихтыяҗга әверелә һәм, шуңа җавап буларак, «акыл диннәре» туа. Төрки ба-

баларыбыз да кайчандыр охшаш ихтыяҗ кичергән һәм, тәңречелектән исламга күчеп, интеллектуаль ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ирешкән.

Диннәр эволюциясенә кагылышлы фикерен дәвам итеп, автор бик тә кызыклы нәтиҗәләргә килә: тәңречелек һәм ислам – бер үк диннең төрле этаплары. Конфессияләр тарихын да ул танып белү сөреше буларак бәяли. Димәк, асылда, кешелек һәрчак бер диндә булган, тик, үзенең акылы үсешенә тәңгәл рәвештә, Алланы төрлечә күзаллаган. Ул тарих йөрәк белән (иррациональ) иманудан башланган һәм Аның барлыгын вә берлеген акылга таянып (рациональ) тануга кадәр үскән. Китү чорында кешелек әле мәҗүсилектә булган. Мөшриклек диннәре исә Җир аңыннан Күкнекенә борылуны тәэмин итү өчен иңдерелгән. Автор әйтүенчә, бүген инде кешелек үзенең эволюцион хәрәкәтендә, әлеге борылыш чорын тәмамлап, ахырзаман эрасына күчеш кичерә. Ә кайту юлының тугрысын-тулысын (Аллаһ хозурына кадәргесен) һәм асылын бары хак динебез ислам гына ачыклый. Ул, кайту юлының соңгы маягын күрсәтеп, кешегә иң югары омтылыш ирегe бирә, башка диннәрдәге кебек, эволюцион сөреш максатын аның түбәнге баскычлары дәрәҗәсендә чикләми – шуның белән, инсан Аллаһтан башка беркемнең дә колы түгел, дигән рухи бәйсезлек карашы тәрбияли. Автор фикеренчә, ислам дине, Алла коллыгы – үз язмышың өчен җаваплылык, дигән мәсләк урнаштыра һәм үзенең шаһәдәт формуласы нигезендә бу мәсьәләдә кешегә тулы ышаныч күрсәтә. Башка конфессияләрдә бу юк.

Ә кайту юлының соңгы этабына кагылышлы фикерләрен автор болай аңлата: «Исламда иң хөрмәтле пәйгамбәрләр – алты. Җиденчесе – Аллаһка кайткан инсан үзе. Шуңа күрә, эволюцион сөреш кешенең Аллага әверелүе белән түгел, ә аның хәзрәти Мөхәммәд халәтенә ирешүе белән чикләнә. Кыскасы, Ислам – Адәми затны Аллаһка кайту сәяхәтенең сикәлтәле юлындагы соңгы баскычка күтәрү (рәсүли аңга ирештерү) өчен иңдерелгән дин. Менә ни өчен аны ахырзаман дине дип тә атыйлар». Бу җәһәттән, шәхес буларак, авторның үзенә кагылышлы, аны ахыргача ачып күрсәткән һәм Аллаһка кайту сәяхәтенең соңгы баскычына күтәргән бер фактка тукталып үтү дә урынлы булыр.

Тормышының соңгы елларында без Рашат абый белән атна саен диярлек очрашып, аралашып һәм гәпләшеп яшәдек. Бәхәсләшкән чакларыбыз да булмады түгел. Чөнки дөреслек бәхәсләрдә туа. Бу яктан ул беркайчан да үз сүзен хакыйкатькә тиңләмәде, мәгәр әйткәнен фактлар белән дәлилли дә белде. Сүзебез, әлбәттә инде, икебезне дә борчыган уртак проблемалар турында иде. Шаһәдәтне йөрәге белән генә түгел, ә Хакның инсанга тәгаенләгән иң зур бүләге – акыл дәрәҗәсендә дә кабул иткән зат буларак, ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр милләт гаме, шулай ук мөселман дөньясы һәм кешелек проблемалары белән яшәде. Соңгы елларда сәламәтлеге какшавын да ул Аллаһ сынавы буларак кабул итте. Ә инде инсульт аяктан еккач, аңа гына хас тәкъвалык вә ихтыяр көче тагын бер кат күренде: якыннарын (һәм үзен дә) авыр хәлдә озак борчымас өчен булса кирәк, медицина ярдәменнән ул тулысынча баш тарткан. Шулай итеп, Рашат Габделбәр улы фанилыктагы соңгы сынавын да хасият белән үтеп, Аның хозурына кайтты.

* * *

Бу дөньяда бар нәрсә дә чагыштыру аша беленә. Таныргa кирәктер, Рашат абый Сафинның татар язмышына багышлап язылган әлеге рухи-фәлсәфи вә сәясииҗтимагый трилогиясе яңа чорда милләтнең киләчәген, күпкырлы һәм тирән анализга таянып, заман таләпләре югарылыгында фаразлаган тәүге җитди хезмәт булып тора. Шунысы да мөһим, ул – ана телебездә, аның бөтен матурлыгын, сихри көчен

һәм фикерне төгәл белдерү сәләтен дә җәлеп итеп, татар менталитетына туры китереп язылган хезмәт. Шуңа күрә аны, эчтәлеге һәм формасы ягыннан, XX гасыр азагы-XXI гасыр башы татар иҗтимагый аңы үсешендәге яңа күренеш буларак та бәяләргә кирәктер. Концептуаль проблемалар белән беррәттән, автор анда игътибарны татар милли хәрәкәтенең бүгенгесе һәм киләчәге өчен бик тә мөһим булган дүрт факторга юнәлтә. Беренчесе – дингә кайту үзмаксат түгел, ул җәмгыятебезгә иман яңарту (һәм саклау) ысулы буларак кадерле. Икенчесе – милләтебезнең үсеш стратегиясен материалистик-фәнни караштан чыгып кына бәяләү алгарышка юл ачмаячак. Чөнки ортодоксаль фән Кеше-Җир мөнәсәбәтләрен (физик дөнья законнарын) генә өйрәнә. Шуңа автор аны тормыш итү өчен кирәкле, әмма җитәрлек булмаган шарт, дип бәяли. Ә инсан Җир белән Күк арасында яши. Димәк, адәми затка Күк йогынтысын да белергә кирәк. Анысын инде автор Изге Китаплардан укып белергә һәм алардагы илаһи гыйлемлек серләрен эзотеризм (заманча терминда – эниология фәне) аша ачыкларга киңәш итә. Өченче фактор – халыкта Кеше-Алла мөнәсәбәтләренә игътибар җитмәгәнгә, милләтебезнең тәкъдири миссиясен (татарның бу дөньяга исламны заманча аңлау вә аңлату өчен җибәрелгәнен) танып эш итмибез. Шуның аркасында – монысы инде факторларның дүртенчесе – киләчәгебезне күзаллаганда ияртүчеләр түгел, ә иярүчеләр (диндә – гарәпкә һәм төреккә, сәясәттә – урыска, икътисадта – яһүдкә, мәдәнияттә – Көнбатышка) буларак фикер йөртәбез. Бу милли яшәеш системасының бербөтенлеге җуелуына китерә, ди автор.

Хезмәтләрдә традицион (гарәби) ислам белән татар исламы арасындагы аерма һәм ислам варислыгы мәсьәләләренә дә җитди игътибар бирелә. Әлбәттә, үзгәлек хакында сүз барганда, йола дәрәҗәсендәге аерма гына күздә тотылмый. Төрлелек мәгънәви тирәнлек белән дә билгеләнә. Әйтик, традицион ислам шаһәдәтне берьяклы – тәүхиди вариантта гына белә. Шуңа күрә анда үз язмышын кору буенча кешенең ирке һәм җаваплылыгы танылмый. Татар исламы исә – тәүхиди-иҗтиһади ислам. Аның нигезен, мөшриклектән арынып, тәүхиди бераллалыкның асылын аңлаган һәм чынбарлыкка мөнәсәбәттә, тәкъдир белән беррәттән, аны реальләштерүдә кешенең ирекен вә җаваплылыгын, димәк, адәми иҗтиһадны да таныган караш тәшкил итә, ди автор. Ә бу инде, кеше – тәкъдирне гамәлгә кую буенча Аллаһның Илчесе, дигәнне дә аңлата.

Ислам варислыгына килгәндә, Рашат абый аны татарның Гыймран нәселеннән булуы белән һәм Коръән сүрәләренә таянып дәлилли. Автор аңлатуынча, Гыймран нәселе Атлантидада яшәгән туранлылардан килә. «Эзотеризм өйрәтүенчә, – ди ул, – Ак һәм Сары расаларга Нух пәйгамбәр өммәтеннән булган һуннар (ягъни Бөек Туфаннан сакланып калган туранлылар) нигез салган. Соңрак алар төркиләр исеме белән йөртелгән. Ибраһим пәйгамбәр заманнарында бераллалык идеясен саклаучы әлеге төркиләрне Якын Көнчыгышта хәнифләр атамасында белгәннәр. Ибраһим пәйгамбәр үзе дә шушы токымнан булган: «Ибраһим яһүд тә, христиан да түгел, ул фәкать Аллаһны бер дип таныган хәниф иде. Ул мөшрикләрдән дә түгел» (Коръән, 3:67). Бу һәм башка аятьләрнең (әйтик, 4:125; 2:135) уртак мантыйгына таянып фикер йөрткәндә, – ди автор, – хәнифләр Гыймран нәселеннән булып чыга». Ә әлеге дәлилләр һәм кайбер тарихи факторлар аны, ахырзаман цивилизациясенә нигез салу бурычы, исраил токымы һәм ислам варисы буларак, тәкъдири рәвештә татарга йөкләнә, дигән нәтиҗәгә дә этәрә.

Боларның һәммәсен дә исәпкә алып, аксакал-милләтче татар милли хәрәкәтенең стратегик юнәлешләрен түбәндәгечә билгели: 1) иң әүвәл, татарга йөкләнгән тәкъдири миссияне үтәү максатында, иярүчеләр рәтеннән чыгып, ияртүчеләр ролендә фикерли башларга; 2) кулавыз булу өчен тугры юлны дөрес күзалларга; 3) моңа ирешү ниятендә илаһи кануннарны өйрәнергә; 4) алар метафизик карашлыларга ачыла; димәк, 5) гео-

Р.Сафинның «Татар инануы» китабын тәкъдим итүдә катнашучылардан бер төркем (2014 ел, декабрь)

тарихи бурычларыбызны истә тотып, ислам метафизикасының асылына төшенергә; 6) яшәү вакытыбыз ахырзаман чорына күчеш этабы булганлыктан, аның таләбенә тәңгәл мәсләкнең (дөньяга карашның) асылын ачыкларга; 7) боларның бөтенесен гамәлгә ашыру юлларын табарга.

Әлбәттә, әлеге юнәлешләрне гамәлгә ашыру милләтебездән гаҗәеп дәрәҗәдәге үзоешканлык, акыл һәм тырышлык таләп итә. Аллага шөкер, аның эчке потенциалы әлегә моның өчен җитәрлек һәм иң мөһиме – Күкләр аны сыный, әмма рәхимлелек тә күрсәтә. Җиһан халкы кичерә торган бүгенге чарасызлык һәм рухи деградация чорында исә бу – татар өчен генә түгел, бөтен мөселман дөньясы һәм инсаният өчен дә уникаль мөмкинлек. Рашат абыйның хезмәтләрендә сүз әнә шулар хакында да бара.

Хуш, болары һәммәбезгә дә яхшы аңлашыла булыр. Ләкин бу дөньяда теоретик карашларның җәмгыять тарафыннан кабул ителүе, ягъни тану һәм танылу кебек нәрсәләр дә бар бит әле. Кызганычка, Рашат абый фанилыкта хезмәтләренең һәм үзенең танылуына тулысынча ирешеп китте, дип әйтә алмыйбыз. Чөнки, ихтимал, күпләр аның язганнарын аңлау дәрәҗәсендә фикер йөртергә әле әзер дә булмагандыр (әйтик, «Татар инануы» дигән китабы Казанда дүрт ел, басылмыйча, чират көтеп ятты. Ахыр чиктә, милли зыялыларыбыз тырышлыгы белән ул, аз санда булса да, Уфада нәшер ителде). Әлбәттә, Рашат абыйның хезмәтләре татар милли элитасы тарафыннан югары бәяләнде, әмма эш милләткүләм дәрәҗәдәге танылуга кадәр үк барып җитмәде. Нәтиҗәдә ул, рәсми танылу да ала алмыйча, бакыйлыкка күчте. Хәер, үзен таныту аның өчен ул кадәрле үк мөһим дә түгел иде кебек. Ә менә хезмәтләренә карата битарафлыкка (бигрәк тә дин әһелләренең илтифатсызлыгына) ул нык борчылды.

Әйе, мөшриклекнең тамырлары әлегә җәмгыятьтә дә, дин әһелләре арасында да нык. Әмма андыйларга Хакның җәзасы да катгый: глобаль кризис көннән-көн тирәнәя бара, ә кешелек җәмгыяте рухи деградациягә юл тота. Ни кызганыч, билгесезлек һәм рухи томан эчендәге хәтәр юллар чатында бүген татарның да шактый өлеше чарасызлык халәте кичерә. Әмма еракта аның фидакарь улы калдырып киткән һәм татарның үзенә



Р.Сафинның соңгы автографларыннан берсе

генә аңлаешлы рухи вә әхлакый маяк шәйләнә: ул – илаһият кануннары буенча яши башлау һәм ошбу игелекле эшләрдә башкаларга үрнәк булу юлы. Шуңа күрә, Рашат абый күрсәтеп калдырган юнәлешләрне тәгаенләп, шул тарафларда акыл белән хәрәкәт итү хәзер инде татар өчен тәкъдир кушуы да булып тора. Димәк, аның мирасын өйрәнү һәм ниятләрен гамәлгә ашыру иң әүвәл милләтнең үзе өчен кирәк. Ә бу инде Рашат абыйның газиз милләтенә Күкләр югарылыгыннан кайтуын да аңлата.

Хәлбуки, китү-кайту әйләнеше милләтләрнең үзләренә дә хас. Әйе, алар арасында да төрле киртәләргә юлыгучылар, ярты юлда адашып калучылар яисә кире кайтырга теләмәүчеләр (үзенең тәкъдири миссиясен һәм урынын аңламаучылар) булырга мөмкин. Ул гына түгел, кайту шарты әле милләт яшәешендә юл күрсәтердәй шәхесләр булу-булмавына да бәйле. Кулавызсыз юлга чыккан юлдан язар, ди мәкаль. Шөкер, татарда андый кулавызлар булган, бар һәм булыр да, шәт. Димәк, кайчандыр дөньякүләм дәрәҗәдә дан-шөһрәт казанган татарның сәяси аренадан китүе котылгысыз булган кебек, аның анда (метасәясәткә) кире әйләнеп кайтуы да тәкъдирдән.

***

XX гасыр башында татарның ул чакта әле яшь, әмма өметле язучысы һәм булачак милли әйдәманы Гаяз Исхакый үзенең «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестен яза. Бу әсәр дискриминация һәм милли йомыклык шартларында яшәгән татарны сискәндереп җибәрә һәм үзенең киләчәге хакында ныклап уйланырга мәҗбүр итә. Шул рәвешле, инкыйразга йөз тоткан татар тарихында милли борылыш чоры башлана. Ул, нигездә, сакланып калу өчен көрәш шәкелендә бара. Чөнки Хак Тәгалә, сакланганны саклармын, дигән. Әмма тоташка киткән саклану тактикасы үзе дә чарасызлыкны аңлата. Шуңа күрә, тәкъдир кушуы XX гасыр ахырында алгы планга милләтнең тагын бер фидакарь улын – Рашат Сафинны чыгара. Ә аның хезмәтләрен һәм эзләнү-табышларын Г.Исхакый өслүбендә атасак, ул «Ике йөз елдан соң алгарыш» рәвешендә яңгырар иде. Чыннан да, милли борылыш чоры алдыннан татарны гафләт йокысыннан Гаяз Исхакый уяткан кебек, нәкъ бер гасырдан соң, милләтнең инде кайту эрасы да җитүен искәртеп, Рашат Сафин оран салды һәм кайту юлларын да күрсәтте. Иншаллаһ, татар милләте өчен генә түгел, кешелек дөньясы өчен дә ул бәрәкәтле кайту булыр! ■

Безнең мирас №7 июль 2019

Минтимер ШӘЙМИЕВ: «Туган тел проблемаларына күз йома алмыйбыз»*

Болгар һәм Зөя шәһәрләрен торгызу эшләреннән соң, Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе күптелле белем бирү комплекслары булдыру өстендә эшли башлады. Бу мәктәпләрдә балалар өч телдә белем алачак. ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Андрей Кузьмин белән әңгәмәсенең икенче өлешендә мәгариф һәм туган тел мәсьәләләренә ни өчен битараф кала алмавы, яңа комплексларның элита мәктәпләреннән нәрсә белән аерылачагы турында сөйләде.

– Минтимер Шәрипович, Сезнең эшчәнлек хәзер мәгариф өлкәсенә юнәлде. Моның сәбәбе нидә? Бу республика, милләт, балалар өчен аеруча кискен мәсьәлә булгангамы?

– Мин бу проблеманы бөтен кеше өчен дә, бөтен ил өчен дә актуаль, дип саныйм, гәрчә совет заманындагы мәгариф системасы үз вакытында бик яхшы булса да. Моны инкарь итеп булмый. Мин үзем – авыл егете. Безнең Калинин районы үзәгендә

* Әңгәмә кыскартып бирелә. Тулысынча https://www.tatar-inform.ru сайтыннан укырга мөмкин (Ред.)

(*1935-1959 нчы елларда ТАССРдагы хакимият-территория берәмлеге хәзерге Актаныш районы. – Ред.*) бер генә рус гаиләсе бар иде – Выборновлар, әтиләре – банк идарәчесе. Алар рус телен онытканнар инде, дип шаярталар иде. Безнең мәктәптә, рус теле һәм әдәбиятыннан кала, бөтен фәннәр татар телендә укытылды. Шуңа карамастан, укытучыбыз әйбәт булганга, русча без бик грамоталы язабыз. Мин текстларга, дөрес язылышка һәрчак игътибар итәм, аппаратта моны бөтенесе белә. Система яхшы иде, диясем килә.

Әмма хәзер дөнья ачылды, без дә дөньяга ачылдык. Билгеле булганча, элек ил ябык иде. Кайберәүләр, белеме-әзерлеге булмаган килеш, тел белмичә, Америкага яисә башка илләргә чыгып китте. Каядыр чит-ят җирдә, күләгәдә яшәп ятуны бәхет дип булмый, гәрчә үзләре моны бик танырга теләмәсә дә.

Үзебезне һәм үз илебезне хөрмәт итәбез икән, без көндәшлеккә сәләтле булырга тиеш. Дөнья ачылды, аны ябарга кирәкми дә, бу мөмкин дә түгел. Узган ел Казанда, ЮНЕСКО юнәлеше буенча, кешелекне саклау турында конференция булды. Мин бер танылган фәлсәфәче чыгышын тыңладым, аңа сораулар да бирдем. Глобальләшү һәм техник алгарыш процесслары кешедән тормый, диде ул, гәрчә алар кеше акылы һәм кулы белән эшләнсә дә. Танып-белү процессы дөньяның үзе кебек чиксез һәм аны туктату мөмкин түгел.

Миңа математикадагы чиксез олы һәм чиксез кече зурлыклар турындагы төшенчә ошый. Кече зурлыклар турында болай диләр: «Алар һәрвакыт нульгә омтыла, ләкин нуль түгел». Яки чиксез олы зурлыклар – инде йөзләрчә галактикалар, күпме планеталар ачылган! Санлы икътисад та хәзер искиткеч зур тизлектә үсеп бара. Мин, инде кичәге көн кешесе булсам да, бөтен нәрсәнең тиз һәм колачлы үсүен тоеп торам. Моңа ничек битараф булырга мөмкин?!

Без, беренче чиратта – татарлар, татар теленә бәйле мәсьәләләрне бик авыр кабул иттек. Күп еллар дәвамында без Россия Конституциясе һәм Татарстан Конституциясе буенча төгәл эшләдек. Ләкин туган телләргә басым ясарга маташучы көчләр табылып тора. Моңа юл куярга ярамый. Ошыймы бу кемгәдер, ошамыймы, туган тел – беренчел төшенчә. Мин һәрвакыт әйтә киләм: бу турыда сүз башлаганчы, үз туган телегездән мәхрүм калып карагыз, ул чакта ни диярсез? Бу – гадел искәртү. Мәсьәлә үзеңә кагылмаганда, фикер йөртүе бик җиңел. Ул бик нечкә материя, игләп эшләргә кирәк.

Проблема чыннан да бар, чөнки Россия – күпмилләтле ил. Тыныч кына, сабыр гына, көчне һәм вакытны кызганмыйча эш итү зарур. Кешеләр күңелендә шик-шөбһә тудыру нигә кирәк?!

Әлеге нәрсәләр бик сак эш итүне сорый. Үзебезгә дә туган телне өйрәтүнең нәтиҗәлерәк методикаларын эшләргә кирәк булган. Без дөньяга ачылгач, белем бирү алымнары үзгәрде. Шаккатарсың. Мин хәзер белем бирү комплекслары белән шөгыльләнә башладым. «Инде ярты ел беренче сыйныфта укыйм», – дим барысына да. Үзем өчен шушы яңа дөньяны ачам. Кембридж системасын һәм дөньядагы башка тәҗрибәләрне өйрәнәбез. Хәзер бит балалар да башка, аларга бөтендөнья мәгълүмат киңлеге ачык. Балалар бакчасыннан ук башлап, бик күп нәрсәне сеңдерә алалар. Башлангыч мәктәпне дә кушып җибәрсәң, белем бирүгә акыллы караш булганда, аларны бик күп нәрсәгә өйрәтеп була. Моны дөнья тәҗрибәсе дә күрсәтә, галимнәр дә шул фикердә тора.

Без ачкыч эзлибез, өйрәнәбез, дөнья ачык – өйрәнер нәрсәләр бар. Инде бу юлдан Татарстан гына бармый, Мәскәүнең үзендә дә йөзләрчә белем бирү комплекслары бар.

ЮНЕСКО оешмасы хәзер Франция тәкъдим иткән карар проектын карый.

Мәгълүм ки, ЮНЕСКО мәгариф, мәдәният, фән мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Бу проект буенча, ЮНЕСКО әгъзасы булган дәүләтләрдә ким дигәндә ике чит тел өйрәнү бурычы куела. Дөньяда менә шундый эш бара, моны тормыш үзе таләп итә.

Без Татарстанда туган тел проблемаларына күз йома алмыйбыз. Төрле милләттән булган ата-аналар арасында аңлашылмаучылыклар тудыру нигә кирәк?!

Иң мөһиме – бик яхшы үрнәгебез бар. Беренче белем бирү комплексы өчен нигез итеп ни өчен 165 нче мәктәпне сайладык соң? Бу мәктәпнең директоры Айдар Шәмсетдинов – Россия буенча иң яхшы мәктәп директорларының берсе. Аның мәктәбендә андый проблемалар юк. Ул үз эшен рус мәктәбе нигезендә башлап җибәргән. 165 нче мәктәптә берничә милләт баласы укый. Үзара аралашканда кайберләре русча сөйләшә, кайберләре – татарча, аннары бергәләп инглиз теленә күчәләр, кемдер катнаштырып сөйли. Мәктәп умарта күчедәй гөжләп тора. Мин мәктәптә укыганда әткәй белән умарталыкка йөри идем, шуңа күрә мондый эшлекле гөжләү миңа бик таныш.

– Ә нәрсә беренчел – күптеллелекме, әллә заманча укыту алымнарымы?

– Бөтенесе бергә.

– Ярый, ачтык та, ди – болар элиталы биш-ун мәктәп булып кына чыкмасмы соң? Ә калганнарга нишләргә? Яки бу мәктәпләр методикалар эшләү буенча әйдәп баручы итеп ниятләнеләме?

– Алар маяклар булырга тиеш. Хәзер бит кайбер җирләрдә шулай ук инглиз телен дә укыталар, ләкин ул түләүле дә, кыйммәт тә. Ә без башкачарак эшләргә тырышачакбыз.

Апрель башында без бөтен тәкъдимнәрне Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов янына җыелып карап чыктык, ничегрәк, нәрсәдән башлауны уйладык. Башлап җибәргәндә алты белем бирү комплексы булдыру хупланды.

Эшне Казаннан башлавыбызның сәбәбе шунда ки, биредә әлеге проблеманың иң куерган урыны – телләр турындагы канунның, Россия Конституциясенең, Татарстан Конституциясенең аерым маддәләре үтәлеше дә. Без күп кенә сорауларга җавап табарга тиешбез. Ни өчен бу белем бирү комплексларын оттырышсыз вариант дип саныйбыз соң? Беренчедән, бу белем бирү базасын матди яктан яхшырту була. Дөрес, безнең республикада, башка төбәкләр белән чагыштырганда, ул болай да начар түгел. Без белем бирү комплексын мәктәп тә, бакча да булган җирлектә ясыйбыз. Инде эшләнгән методика буенча барабыз, мәктәпләрнең берсе нигез итеп алына, үзгәртеп корырга кирәк икән – башкарабыз. Мәсәлән, 165 нче мәктәпнең гамәлдәге бинасына янкорма төзибез. Ләкин бу янкорма гына түгел, ул алга таба башлангыч мәктәп бинасы булачак. Ә яңа урында – Бондаренко урамында – урта мәктәп төзибез. 1025 балага исәпләнгән урта мәктәп бинасы проектын сайладык. Һәм болар барысы да бер комплекс тәшкил итәчәк: балалар бакчалары, башлангыч мәктәп һәм урта мәктәп.

– Мондый мәктәпне тәмамлап чыккан укучылар нинди булачак?

– Алар югары дәрәҗәдә белемле кешеләр булачак.

– Төрле телләрдә сөйләшә торганмы? Белемнәре дә Россиянең яки чит илләрнең теләсә-кайсы югары уку йортына керерлек дәрәҗәдә булачакмы?

– Без көндәшлеккә сәләтле балалар әзерләп чыгарырга тиеш. Бу очракта ата-аналарга һәм мәктәпләрдәге ата-аналар советларына зур роль бирелә.

Иң төп мәсьәләләрнең берсе – кадрлар әзерләү. Без татар теле укытучылары җитми, дибез. Инглиз теле буенча да әлегә шул ук хәл. Күптән түгел Казан университетында булдык. Көне буе ял да итмичә биналары буйлап йөрдек. Лабораторияләрен карадык, чит ил студентлары ничек укый, шулар белән кызыксындык. Кытайдан,

Рамил Гали фотолары

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Андрей Кузьмин

Италиядән, Испаниядән, Франциядән һәм башка илләрдән студентлар бар. Алар рус телен өйрәнә.

Бу мәсьәләгә Мәгариф һәм фән министрлыгы да кушылды, педагогия көллиятләре, институтлар да. Алар Чаллыда, Алабугада бар, тик ныклап уйларга, тикшерергә, киңәшләшергә кирәк – нәрсәнедер башкача корырга, өстәмә чаралар күрергә. Хәзер моның белән республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан федераль университеты ныклап шөгыльләнә.

– Минтимер Шәрипович, Сез ни өчен нәкъ менә шушы мәсьәлә белән шөгыльләнәсез? Россиянең бөтен бер Мәгариф министрлыгы бар, Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы. Бездә күпме мәктәп, институт. Сезне ул нәрсәсе белән «эләктереп» алды?

– Бу – безнең бөтен яшьләребез язмышы. Социаль-икътисади үсеш күрсәткечләренә карасаң, без бит күп эшләргә сәләтле ләбаса. Уйлап кына карагыз – елына 600 миллиард сумга якын инвестиция – бу бит кайберәүләрнең төшенә генә керергә мөмкин! Әле кайчандыр халыкка бер миллион квадрат метр торак төзү турында хыяллана идек, ә хәзер 2,4 миллион квадрат метр төзибез. Күп мәсьәләләрне үз көчебез белән хәл итә алабыз. Әлбәттә, мәгариф мәсьәләсе катлаулырак булыр, бигрәк тә милли факторны исәпкә алганда. Нигә әле без моны күрмәмешкә салышырга тиеш? Бу проблемаларны тиешенчә хәл итәргә һәм шул ук вакытта көндәшлеккә сәләтле балалар әзерләргә акылыбыз җитәргә тиеш. Бу бит – безнең балаларның язмышы, моның белән шөгыльләнмәскә мөмкинмени?!

– Димәк, бу хәзер безнең иң әһәмиятле проблема, шулаймы?

– Әйе, бу инде өлгереп җиткән мәсьәлә. Без бит хәзер гел мәктәпләрдә йөрибез, Татарстанда да, Мәскәүдә дә. Мәсәлән, Грефның банк мәктәбе бар (*монда сүз, мөгаен, Сбербанк идарәсе рәисе Герман Грефның хатыны Яна Греф ачкан Хорошёв прогимназиясе турында барадыр. – Ред.*). Ләкин анда һәркем укый алмый. Ә без исә теләгән һәр бала кереп укый алырлык итәргә телибез.

Нигә алты комплекс? Икесе – Казанда, Чаллыда, Әлмәттә, Түбән Камада һәм Ала-

бугада – берәр. Аларны оештыргач, алга таба караячакбыз. Бу системага әле шәһәр читендә ел әйләнәсе эшли торган белем бирү кампуслары да керәчәк.

Төзелешкә кагылышлы сорауларның барысын да Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов карап чыкты. Әлбәттә, чыгымнар булачак. Хәзер иң мөһиме – кадрлар әзерләү. Ана телләре инглиз теле булган оста укытучылар бик аз, аларның хезмәте югары бәядә. Университетларда үзебезнең педагогларны яхшы дәрәҗәдә әзерләргә кирәк.

– ...һәм татар теле укытучыларын да.

– Әйе, мин бөтен комплекс турында әйтәм. Министрлыкта хәзер моның белән шөгыльләнәләр. Биредә кемнедер гаепләп тә булмый, ләкин вакыты килеп җитте. Дөньяның ачык булуы шартларында бу мәсьәләгә тотынырга кирәк. Теләге булган һәркем укый алырлык булсын. Тагын бер кат әйтим: матди нигезе акча кертүне таләп итә, ләкин булганын исәпкә алып эшләргә кирәк. Кайдадыр балалар бакчасына капиталь ремонт ясарга, кайдадыр өстәмә корылма төзергә, янкорма эшләргә, кайдадыр заманча җиһазлар белән тәэмин итәргә. Заманча белем бирү тирәлеге оештырырга кирәк. Аралашу, уку, өйрәнү барышында балалар башына белем үзе «керәм» дип торсын.

Бу гади юл түгел, ләкин башкасы бармы соң? Булса, күрсәтсеннәр миңа. Вакыт тиз үтә, нишләп без моны эшләмәскә тиеш? Без эшли дә, акча таба да беләбез. Ихтыяҗ туган очракта, бюджетны да шушы юнәлешкә бераз борырга туры килер, бәлки. Хәзер безгә эшне башларга, сынап карарга, юллар табарга, ялгышларны төзәтергә кирәк – башкача булмый. Мөмкинлек бар, уңганлык-булганлык халкыбызның канында ул. Дөньядан артта калсак, үкенечле булачак. Киләчәк хакына килешү юллары табарга кирәк.

Беренче комплексны без «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» дип атадык. Бу гыйбарә очраклы гына алынмады, ныклап уйладык. Бу – белем аркылы тынычлыкка-татулыкка таба адымнар дигән сүз.

Укучылар һәм укытучылар арасындагы каршылыкларның, низагларның бөтен дөньяга яңгыравы кемгә ошый?! Мондый хәлләргә күп еллар эшләгән педагоглар да дучар ителә, шунысы бигрәк тә аяныч. Алар булсын дип тырыша, тик замана баласына ничек аңлатырга, ничек йогынты ясарга, күңеленә хуш килерлек итәргә икәнен белмиләр. Яшьләр күңеленә, әлбәттә, бөтен нәрсә дә хуш килми, ләкин үзара аңлашу юлларын табарга кирәк.

Белмим, ышандырырлык итеп сөйлимме мин, юкмы – ләкин мин моның белән шөгыльләнергә кирәк дип саныйм. Шушы җирлектә кадрлар да әзерләргә, булган бөтен ысулларны да эшкә җигәргә кирәк. «Хәрәкәттә – бәрәкәт», – дип юкка гына әйтмибез бит. Хәрәкәтсез бернигә дә ирешеп булмый. Без хәзер юлда, шуңа да мәктәпләрне «Адымнар» дип атадык. Бу адымнар алга таба киң юлларга, күтәренке күңел белән белем алуга, балаларыбызның кеше булып үсүенә китерергә тиеш, дип уйлыйбыз.

– Әңгәмәбезне менә шушы күтәренке рухта тәмамларга теләр идем, Минтимер Шәрипович, чөнки Сезнең киләсе очрашуыгыз башланырга тора.

– Бу әңгәмә чиксез булырга мөмкин иде.

– Бик зур рәхмәт Сезгә.

– Сезгә рәхмәт. ■

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА – 100 ЕЛ

ТАССР

Елый-елый укыган китап

Гәрәй Рәхим

Моннан 65 еллар элек, ягъни 13 яшьләремдә 4-5 нче сыйныфларда укыганда миңа беренче мәртәбә китап җене кагылды. Шунсы кызык, бу «җен» миңа үз теләгем белән килмәде, аны миңа әнием һәм күрше-тирәдәге биш-алты керәшен хатыны көчләп такты.

Эш шунда ки, сугыш һәм сугыштан соңгы ул елларда авылның бер урамы, тыкрыгы, берәр очы тирәсендә яшәүче 5-6 хатын, йорт эшләреннән бушап караңгы төшкәч, сукыр лампасы булган бер өйгә җыелып кич утыралар һәм шунда төн буе диярлек кайсы йон эрләп, кайсы оек-бияләй бәйләп, кайсы чигү чигеп, безнең кебек укый-яза белгән бала-чагадан кычкырып китап укыталар иде. Безнең әни, күрше хатыннар белән еш аралашучы буларак, озын кышкы кичләрдә биш-алты хатынны биләмгә өйгә чакырырга ярата. Әтиебез колхоз рәисе булганга, бездә керосинлы сукыр лампа да бар, җитмәсә, мин бик оста итеп кычкырып китап укый да беләм. Хатын-кыз биләме өчен койган да куйган мөмкинлек инде.

Менә шул хатыннар кич саен кул эшләрен тотып, кесәләренә айбагар (безнең керәшеннәр көнбагышны «айбагар» диләр) тутырып, безнең өйгә, сукыр лампа яктысына җыелалар һәм минем кулга кирпеч калынлык татарча китап тоттыралар да шуны кычкырып укырга кушалар. Кушкач, нишлисең, кычкырып китап укыйм, алар эскәмияләргә, сандык өсләренә, сәкеләргә тезелеп утыралар да кесәләрендәге айбагарларны авызлары-

Г.Рәхимнең тугызынчы сыйныфта укыган чагы. 1958 ел

на берьюлы түндереп йон эрли, оекбашбияләй бәйли, чигү чигә башлыйлар. Таң атканга кадәр өйдә «черт-черт» айбагар ярган һәм минем дәртләнеп-ярсып китап укыган тавыш кына ишетелә. Иртән әнкәй идәннән бер чиләк айбагар кабыгы көрәп ала. Шунсы да бар, тыңлаучыларым кулыма вак-төяк, ягъни юка һәм бәләкәй китап тоттырмыйлар, ә Лев Толстойның татарчага тәрҗемә ителгән «Яңадан туу», «Сугыш һәм солых» романнарын, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Газинур», Гомәр Бәшировның «Намус» романнарын гына укыталар. Шуңа күрә һәр китапны дистәләрчә биләм кичендә генә укып тәмамлый ала идем.

Матур әдәбиятка, әдәби китапларга мәхәббәтем, аларның бөек уйлап табучылык галәмәте булуларына гомерлек ышанычым нәкъ әнә шул биләм кичәләрендә шытып чыкты, үсте.

Әмма «Безнең мирас» журналы белергә теләгән, үзем өчен генә шәхси булган «Хәтергә уелган китап» болар арасында түгел иде. Дөрес, алда әйткәнемчә, Лев Толстой, Габдрахман Әпсәләмов һәм Гомәр Бәшировның (ул чакта әле Галимҗан Ибраһимов әсәрләре илгә кайтып җитмәгән иде) мин керәшен хатыннарына кычкырып укыган бу романнары, һичшиксез, язучы булып китүемә гаять зур йогынты ясадылар. Әмма әле болар дикция аша нигездә тыңлаучыларыма – әлеге керәшен хатыннарына тәэсир итү өчен укылдылар. Шәхсән үзем өчен генә, бары тик минем әдәби-сәнгати интим хисләремә генә кагылган «Хәтергә уелган китап», ягъни шигъри әдәби әсәр күренекле һәм катлаулы язмышлы Фатих Кәримнең «Ант» поэмасы булды. Бу әсәрне 1959-61 нче елларда туган авылым китапханәсе мөдире булып эшләгән чакта укып туя алмый идем. Әле дә ап-ачык күз алдымда: бу поэманы бакчабызны урталай кисеп аккан Аналык елгасы ярындагы мунчабызда, кешедән качып, хисле интонация белән, елый-елый кычкырып укый идем:

Аникинның пост сәгате тула,
Биноклен ала күзеннән.
Үлән чыклы, күкрәгендә шуып
Кире китә килгән эзеннән...

Ләкин ул чик сакчылары янына кайтып җитә алмый, чик бозучы пулясы йөрәгенә килеп кадала. Әнә бит, үлем ярасы алган Аникин, яр буендагы юеш үләннргә кайнар канын тамыза-тамыза, чик сакчылары өенә табан шуыша. Бераздан ул шунда мәңгегә күзен йома. Мин дә, нәкъ Аникин кебек япа-ялгызым, кара мунчада үкси-үкси елыйм.

Нәкъ менә шушы поэманы елый-елый укыган елларда үземнең беренче шигырьләремне дәфтәрне мунча сәкесенә куеп яза башладым. Дөрес, алар әле бик зәгыйфьләр, тәҗрибәсезләр иде.

Алдарак искәртеп үткәнемчә, «Хәтергә уелган китабым» туган авылымдагы туган өем мунчасында елый-елый укыган әнә шул поэма булды. ■

Безнең мирас №7 июль 2019

КЕРӘШЕННӘР БАШКАЛАСЫ

Рәдиф Сәгъди

Керәшен татарлары турында сүз чыкса, легендар шәхесләр исемә төшә. Шуларның берсе – армия генералы, Җиңү ордены кавалеры Алексей Иннокентьевич Антонов. Немец фашистларына әсирлеккә эләгеп тә илен сатмаган, Австриядәге үлем лагеренда – Маутхаузенда вәхшиләрчә җәзалап үтерелгән профессор, хәрби фәннәр докторы, генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое Дмитрий Михайлович Карбышевны барыбыз да беләбез. Брест крепостенда тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән Петр Михайлович Гаврилов – чын мәгънәсендә безнең горурлыгыбыз. Лаеш өязенең Әлбәдән авылында туып үскән Советлар Союзы Герое турында кинофильмнар төшерәләр, ләкин татар, керәшен икәнлеген әйтми үтәләр! Татарның бөеклеге аннан гына кимемәсә дә, күңел рәнҗи.

1812 елгы Ватан сугышында партизаннар хәрәкәтенә җитәкчелек иткән каһарман, Батый хан нәселеннән булган гаярь сугышчы Денис Давыдов үзенең мемуарларында, татарларның батырлыгына сокланып: «Татарлардан да яхшырак беркем дә сугыша алмады, алардан хәтта Дон казаклары да көнләшә!» – дип язган.

Бүгенге көндә керәшен татарлары күпләп төпләнеп яшәгән төбәкләр, тел аермалыгы, сөйләм һәм этнографик күренешләрдән чыгып, алты төркемгә бүленә. Шуларның беренчесе – Кама буе төркеме үз эченә элеккеге Казан, Лаеш, Мамадыш өязләрен ала. Аңа Яшел Үзән, Әтнә, Дөбьяз, Биектау, Арча, Балтач, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Теләче, Саба, Мамадыш җирлекләре, шулай ук Татарстан Республикасына чиктәш булган Киров өлкәсенең Малмыж районы да керә. Әлбәттә, керәшен татарларының күпчелеге Мамадыш биләмәләрендә гомер сөрә. Чулман һәм Нократ

Мамадыш шәһәренең хәзерге һәм революциягә кадәрге күренешләре

елгаларының ярларына матур-матур керәшен авыллары урнашкан. Хәтта биредән Казан ханлыгы чорында зур сәүдә юлы да үтеп, аны Җөри даругасы дип атаганнар. Мондагы табигать гаҗәеп гүзәл. Терлек, мал-туар асрыйм, дисәң, елга үзәннәре, әрәмәлекләр җәелеп ята. Шактый гына калку таулары бар, алардан йөзләгән чишмәләр агып төшә.

Шушы җирлектә Ылыя авылы да үзенә урын тапкан. Авылның аксакаллары сөйләве буенча, баштарак алар, Кукмара ягындагы Аксыбы авылыннан күчеп килеп, Лыя белән Шыя елгалары кушылган җиргә төпләнгән булалар, ә бүгенге урынында куе урман үсеп утырган. Аны агачка кисеп, төпләп, урын хәстәрләгәннәр. Бу күченешләр VII гасырның ахыры-VIII гасырның башларына туры килә. Кояш чыгышы ягында Кәҗүнний (Казенный) тавы да бар. Ылыя авылы халкы исә Юкәче авылы чиркәвенә караган. Кешеләр күбрәк дәүләт карамагындагы урман кисү, сал агызу кебек авыр эшләрдә, солдат хезмәтендә була. Ылыя саласының данлыклы пәһлеваны Василий Федорович Гаврилов та халык теленә риваять булып кереп калган. Тумыштан куәтле үсмер Казанда Юнкерлар мәктәбендә укый. Аның турындагы риваятьләрнең берсенә тукталыйк. Имеш, яңгырлы көннәр булгандыр инде, Мамадыш тавын менгәндә, юл тыгыла: түбән төшеп тә, югары менеп тә булмый. Ул бер-бер артлы алты атны күтәреп читкә куйгач кына юл ачыла. Икенче бер очракта Лубиян авылы белән Кызыл Яр авылы урыслары, үтеп барганда, аны таламакчы булалар. Ул, аларны кисәтер өчен, берсенең фуражкасын салдырып ала да, өй чатын җилкәсе белән күтәреп, шунда кыстырып куя. Әлбәттә, мондый көч аңа табигатьтән генә бирелмәгән. Ике потлы герләрне койма аша



ыргытып та, циркта жилкәсенә поезд рельсы куеп, унике кешене күтәреп тә чыгышлар ясаган ул. Аның сурәте астына: «Русский лев – Василий Гаврилов» дип язылган була. Әлеге пәһлеван турында күп кенә язмалар булуы да мәгълүм. Юнкерлар мәктәбендә укыганда урысчаны ныклап өйрәнгән егеткә авылдашлары «Урыс Бәчесе» – Василие дигән кушамат та тагалар. В.Гаврилов революция, Гражданнар сугышы чорында аклар ягында сугыша. Эсерлар партиясендә торган булуы да бик мөмкин. Аның циркта казак Иван Поддубный белән көрәшеп каравы да билгеле. Ләкин нәтиҗәсе генә билгесез, тарих томаны артында калган. Соңыннан: «Циркта өстенә автомобиль менгергәч басылып үлгән икән!» – дигән хәбәр тарала. Тик ул дөреслеккә туры килми, чөнки В.Гавриловның авылдашлары сугыш башында – 1941 елда Свердловск вокзалында очраталар. Димәк, ул яңа хөкүмәт эзәрлекләвеннән генә качып киткән булып чыга. Үлеме турындагы хәбәрне дә үзе тараттырган. Шулай ук Ылыя авылына бәйле шәхес – Россиянең атказанган рәссамы Семен Игнатьев та, икенче бер сурәтче Владимир Захаров та – чыгышлары буенча җирлектән.

Районның бүгенге көндәге җитәкчесе Анатолий Петрович Иванов үзе дә – Ылыя чишмәсе суларын эчеп, Нократ аланнарында көтү көтеп, балык тотып, печән чабып, утын ярып үскән шәхес. Аның әти-әнисе Феодосия белән Петр бирегә мәктәптә укырга Керәшен Комазанынннан күчеп килгән булсалар, өлкән балалары Клара белән Иван Җөридә туганнар. Ылыяда төпләнгәч, Анатолий, Светлана, Николайлары дөньяга килә. Мин алар арасыннан хәлбуки Анатолий Петровичны гына якыннан

Анатолий Ивановның туган авылы - Ылыя

беләм. Төрле йомышлар, үтенечләр белән килә торгач (аларның да күпчелеге матбугат белән бәйләнгән), яхшы гына аралашып кителде. Аның ярдәме белән, керәшен татарларына багышланган фәнни конференцияләр дә үткәрелеп тора. Аларга багышланган язмалар, тарихи мәкаләләр «Безнең мирас» журналында да даими басылып, халыкка таратыла. Бүгенге көндә ике-өч китап чыгарырлык материаллар туплангандыр инде, чөнки бу кавемнән булган иҗатчылар, язучылар, тарихчылар белән даими эш алып барыла. Әлбәттә, боларның барысы да район җитәкчесенең хәер-фатихасы белән башкарыла. Питрау бәйрәменең ел саен биредә үткәрелүе дә Иван Михайлович Егоров белән Анатолий Петрович Ивановның үзара хезмәттәшлек итүенә, тырышлыгына бәйле. Питрау бүгенге көндә иң саллы җыеннарның берсенә әйләнеп, татар, урыс, чуаш, мари, удмурт халкы аны бергә бәйрәм итә. Бу көнне, туган якларын сагынып, бөтен дөнья керәшеннәре дә кайта. Зур оештыру сәләте, түземлек сорый торган әлеге олуг чараны башкарып чыгу бар кешегә дә бирелмәгән! Шул ук вакытта «керәшеннәр башкаласы» Мамадыш та җитди үзгәрешләр кичерә. Анатолий Петрович җитәкчелек иткән чорда 200 барак сүтелгән, күп катлы 60 йорт салынып, күпме гаиләләр заманча фатирлы булган. Җитәкченең әйтүенә караганда, үзәктә балалар саны да арта бара. «Нишлисең, алга киткән Европа илләрендә дә авыл хуҗалыгында эш итүчеләр өч кенә процент. Без дә шул тарафка юнәлеш алабыз, ахры. Дөрес, халыкның телен, гореф-гадәтен, йолаларын, авыз иҗатын саклаучы булып, һәрчак авыл торды. Хәзер инде шәһәр-калаларда да барсын да нык уйлап, мирасыбызны саклап калуга зур игътибар бирергә, җирлек тудырырга кирәк. Ә калганын тарих үзе күрсәтәчәк, үзе китереп чыгарачак. Барысы да халык-милләтләрнең үзләреннән тора», – ди ул, яшьләрнең шәһәргә тартылуына аңлатма биреп. Әйе, шәһәр-бистәләрдә халык саны арта. Яшьләрне авылда калдыру өчен төп ике юнәлештә хәрәкәт итәлә. Беренчесе – өйләр төзү, эш урыннары булдыру. Икенчесе аның, әлбәттә, социаль мохит-тирәлекне яхшырту.

Әлеге максаттан чыгып, йортлар салу дәвам итә. Шулай ук 400 җир кишәрлеге шәхси өйләр салу өчен дә бирелгән. Күп балалыларга 200 кишәрлек бүленгән. Соңгы

Җөри мәктәбенең тарих укытучысы, төбәкне өйрәнүче Владимир Кузнецов (сулда) һәм драматург Рәдиф Сәгъди

вакытта гына да 17 мең квадрат метр торак төзелгән. Инде эш урыннары булдыру өчен дә зур тырышлык куела. Ишек һәм тәрәзәләр җитештерү, шулай ук пленка ясау, КамАЗ заводы өчен комплектлар әзерләү цехлары аякка баскан. Хәзерге көндә гранит эшкәртүне җайга салу буенча эшләр алып барыла. Голландия технологиясе буенча теплицалар да корылачак. Кытай һәм иранлылар белән дә сөйләшү-килешүләр процессы бара. Чөнки иң төп мәсьәлә – эш урыннары булдыру. Авылларда кул эше киму дә халыкның шәһәргә агылуына китергән. Хәзер бит авыл хуҗалыгындагы техника йөзләрчә кешене алыштыра. Халыкка әле, эш урыннарыннан тыш, ял өчен дә мөмкинлекләр тудырырга, рухи ихтыяҗны да канәгатьләндерергә кирәк. Шуларны истә тотып, Нократ яры күтәртелгән. Биредә су коену өчен пляжлар саны да, тамак ялгап алыр өчен кафелар да арта бара. Матурлау, төзекләндерү эшләре даими дәвам итә. Шулай ук Яшьләр бакчасын аякка бастыру эше дә. Киләсе елга федераль каналлар буенча 60 миллион сум акча бүленгән инде. Ул ипподром, чаңгы һәм тимераяк базалары, бозлавык, чана шуу, тау чаңгысында ял итәр өчен урыннар әзерләүгә тотылачак. Яр буендагы элеватор сүтеләчәк, нәтиҗәдә, яр буе тагын да ачылып, матураеп китәчәк. Соколка аша Чулманда яңа күпер дә салынса, эш тагын да тизрәк барачак. Аръяктагы Түбән Кама, Чаллы, Зәй, Чистай кебек калалар белән ара тагын да якынаячак. Ә инде Мамадышны керәшен халкының башкаласы дип йөртүгә килгәндә, моңа да нигез бар! Районда керәшеннәр яшәгән 35 авыл бар, шуның 18е – чип-чиста керәшен авылы. Биредә яшәүчеләр, бөтен татар халкы кебек үк, бик тырыш. Республика районнарының алтысын керәшен егетләре җитәкли. «Иң мөһиме – хөкүмәт җитәкчелегенең дә, җирле халыкның да ышанычын аклау!» – ди Анатолий Петрович, әңгәмәбезгә йомгак ясап.

Ә керәшеннәрнең башкаласы Мамадыш Нократ ярында борынгы заманнардан бирле горур басып тора. Үсә, үзгәрә бара. Шушы калкулыктан ул үзенең үткәнен, бүгенгесен, киләчәген барлый. Аның киләчәге, әлбәттә, Анатолий Петрович Иванов кебек булдыклы шәхесләр кулында... ■

КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ МАТБУГАТ ИФТАРЫ

3 июньдә, Рамазан аеның соңгы көнендә, «Безнең мирас» журналы редакциясе вафат булган авторлар – язучы, галимнәр (Фирдәвес Гарипова, Рифкать Әхмәтҗанов, Флүн Мусин, Миркасыйм Госманов, Мәсгуть Гайнетдин һ.б.) рухына багышлап, ифтар мәҗлесе оештырды. Редакция хезмәткәрләре һәм мәшһүр җырчыбыз Миңгол Галиев шул ук көнне иртән Яңа татар бистәсе зиратында җирләнгән мәшһүрләребезнең каберләрен дә зиярәт кылды.

Владимир Васильев («Татар-информ») һәм Ленар Гобәйдуллин фотолары

ГРАМОТА

Керәшен татарлары математигы Игнатий Алексеев

Ләлә Мортазина

Татар педагогик фикере үсешендә үзенчәлекле эз калдырган күренекле шәхесләр арасында татар телендә математика укыту, керәшен татарлары арасында мәгърифәт тарату өлкәсендә зур эш башкарган Игнатий Алексеев та бар.

Игнатий Алексеевич Алексеев 1881 елның 23 декабрендә Казан губернасының Чистай өязе (Татарстанның хәзерге Чистай районы) Ишәле исемле керәшен авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа[1]. Истәлекләргә караганда, ул яштән укырга бик сәләтле, тырыш булган, сигез яшендә үк үзлегеннән укырга-язарга өйрәнгән. Малайга 10 яшь тулганда әтисе үлеп киткән. Ятим калса да, ул бар тырышлыгын, үҗәтлеген куеп укыган, төп игътибарын гыйлем өйрәнүгә биргән. Нәкъ менә шуңа да мәктәпкә укырга керүенең беренче елында ук ике еллык курсны тәмамлап, мәктәпнең иң яхшы укучылары рәтендә саналган. Өяздән килгән инспекторның кечкенә малайның арифметик мәсьәләләрне бик тиз чишүен күреп мактап, үсендереп куюы аңа канатлар үсти[2]. 1895 елда туган авылында башлангыч мәктәпне бары тик «бишле» билгеләренә

[1] Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда. Т.2. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. – Б.6.
[2] Сафина А. Галим-педагог Алексеев Игнатий Алексеевич // Татар педагогик фикер үсеше мәсьәләләре. – Казан: 2011. – Б.150.



И.А.Алексеев һәм А.Н.Григорьевның керәшен мәктәпләре өчен «Яңа тормыш» дигән уку китабының тышлыгы (1928)



И.А.Алексеевның «Югары математика нигезләре» дәреслегенең тышлыгы (1953)

Галим бала кечкенәдән үк үз телендә укырга һәм фикерләргә тиеш, ана телендә укыганда ул башка фәннәрне дә тизрәк үзләштерә ала дип санаган. И.Алексеев математика укытучыларының да туган телгә карата сакчыл мөнәсәбәттә булуларын таләп иткән.

генә тәмамлаганнан соң, белемгә омтылган яшүсмер егет Казан шәһәренә килә. Н.И.Ильминский һәм аның шәкерте В.Тимофеев тарафыннан 1863 елда ачылган, башлангыч белем бирә һәм Казан губернасы керәшен мәктәпләре өчен укытучылар әзерли торган Казан үзәк керәшен-татар мәктәбенә[3] укырга керә. Монда да ул үзен тырыш, әзерлекле укучы итеп күрсәтә. Белем үзләштерүдәге уңышларын күргән мәктәп җитәкчелеге аны, ике ел укыганнан соң, Казан укытучылар семинариясенә күчерә. Биредә И.Алексеев 1897-1901 елларда укый. Шул чор кагыйдәләре буенча, әлеге уку йортын тәмамлаучылар мәҗбүри рәвештә 6 ел дәвамында казна хисабына укытучылык итәргә тиеш булалар. Алексеев та туган төбәгенә – Чистай өязенә кайта. Биредә ул Түбән Никиткино земство училищесында, Ишәле мәктәбендә укыта һәм 1908 елда, педагогик белемен тагын да арттыру, камилләштерү максаты белән, Казан укытучылар институтына укырга керә. 1911 елда әлеге институтны тәмамлаганнан соң, Чиләбе укытучылар семинариясендә (1911-1918), Казан рус-әҗнәби укытучылар семинариясендә (1918-1922) педагоглык эшчәнлеген алып бара. И.Алексеев 1922-1931 елларда Казанда Партия мәктәбендә математика укыта.

Октябрь революциясеннән соңгы еллар – азчылык милләтләр арасында милли күтәрелеш еллары. Бу чорда керәшен графикасына нигезләнгән газета-журналлар

---

[3] 1918 елда бу мәктәп Керәшен укытучылар семинариясе итеп үзгәртелә.

Г.Бакиров, М.Рәхмәтуллин, И.Алексеевның 4 нче сыйныф укучылары өчен «Математика» дәреслегенең тышлыгы (1928)



И.Алексеев, Х.Халиков һәм З.Ишаевның «Математика. Элементар курс» дәреслегенең тышлыгы (1932)

чыгару, аерым оешмалар төзү күренеше киң колач ала. 1918 елның гыйнвар-июль айларында, мәсәлән, керәшен татарларының «Керәшен гәзите» дигән газетасы чыга. И.Алексеев керәшен татарлары җәмгыятенең органы булган әлеге басманы нәшер итүдә зур тырышлык куя, аның редакторларының берсе була[4]. Бу чорда ул бигрәк тә тәрҗемә, керәшен татарлары арасында популяр белемнәрне тарату, мәгърифәтчелек эше белән шөгыльләнә. Аз гына вакыт аралыгыда гына яшәп калса да, әлеге газета керәшен татарлары тормышының төрле якларын яктыртуда зур роль уйный. РКПбның Татарстан өлкә комитеты 1921-1922 елларда керәшен секциясе органы булган «Белемнек» («Белемлек») газетасын гамәлгә куйганда да Игнатий Алексеевның катнашы була.

1919 елда Дәүләт нәшриятының (Госиздат) Казан бүлегендә керәшен нәшрият бүлеге ачыла. Аның башында, Л.Мөхәммәдиева күрсәтүенчә, И.Алексеев һәм журналист Н.Оспенников тора[5].

1918 елның августында Казанны чехлар басып алганнан соң, моңарчы чыгып килгән большевистик рухтагы газета-журналлар тыела, күбесе ябыла, ә аларның мөхәррирләре, шул исәптән Игнатий Алексеев та төрмәгә ябыла, тик озакламый азат ителә[6]. Барлык башка матбугат чаралары белән бергә ябылган «Керәшен гәзите», И.Алексеев тырышлыгы белән, кабат торгызыла, ләкин ул башка исемдә – «Кызыл әләм» буларак чыга башлый[7]. 1922-1929 елларда исә аның дәвамы булган «Кинәш» («Киңәш») газетасы дөнья күрә[8].

[4] Мухамадеева Л. Средства массовой информации кряшен в первой половине XX века //- http://tuganaylar.ru/blog/blog/sredstva-massovoy-informatsii-kryashen-v-pervoy-polovine-khkh-veka
[5] Мухамадеева Л. Издательская деятельность кряшен (1920-1930 гг.) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2016. – №3/4. – Б.289.
[6] Григорьев А. 25 жыл // Кинәш. – 1929. – 13 октябрь.
[7] Мухамадеева Л. Средства массовой информации кряшен в первой половине XX века //- http://tuganaylar.ru/blog/blog/sredstva-massovoy-informatsii-kryashen-v-pervoy-polovine-khkh-veka
[8] Татарская энциклопедия. В 6 т. Т.3. – Казань: ИТЭ, 2006. – Б.295.



И.Алексеев, Г.Шәрәф. «Якты юл»: керәшен школларында балаларны укырга, язарга өйрәтү өчен. Букварь һәм уку китабы (1926)

ВКПбның Татарстан өлкә комитетының керәшен секциясе органы булган «Киңәш» газетасының 1929 елгы 13 октябрь санында Игнатий Алексеевның педагогик хезмәт эшчәнлегенә 25 ел тулуга багышланган «25 җыл» дигән мәкалә басылып чыга[9]. Әлеге мәкаләдә педагогның керәшен татарлары мәгарифен үстерүгә керткән өлеше шактый тулы яктыртыла. Керәшен семинариясен кору, иске керәшен мәктәбе урынына яңа, заманга туры килерлек мәктәп булдыру өчен куйган тырышлыгы ассызыклана, татар мәгарифе үсешенә керткән хезмәтләре барлана. *«Меня шушы кыска гына, őстян геня саналыб киткян иптяш Алексеевнын 25 жыллык хезмятен искя алыуны сорой, анын тырыш хезмят интеллигенциясенен бер хадерле агзасы икянен кюрсятя»*, – диелә әлеге мәкаләдә.

1919-1921 елларда И.Алексеев педагогик курслар оештыру эшенә зур өлеш кертә, шул заман өчен иң актуаль проблемалардан саналган керәшен татарлары өчен китаплар, дәреслекләр чыгару белән шөгыльләнә. Нәкъ шушы елларда РСФСР Халык мәгариф комиссариатының Азчылык милләтләр үзәк советында керәшен авторларының Мәскәүдә керәшен хәрефләре белән бастырылган китаплары таратыла. Алар арасында И.А.Алексеевның А.Н.Григорьев белән берлектә язылган «Беренче май» дигән китабы да (1927) була[10]. И.Алексеевның керәшен мәктәпләре өчен дәреслекләр төзүгә керткән өлеше дә зур. Аның А.Григорьев белән берлектә керәшен мәктәпләрендә Әлифбадан соң уку китабы буларак язылган «Яңа тормыш» дәреслеге (Казанда 1928 елда басылып чыга), В.Горохов белән авторлыкта эшләнгән «Нур» китабы, «Яңа тормыш» дәреслеге РСФСРдагы керәшен мәктәпләрендә әле шактый вакытлар актив кулланышта була[11].

[9] Григорьев А. 25 жыл // Киңяш. – 1929. – 13 октябрь.
[10] Мухамадеева Л. Издательская деятельность кряшен (1920-1930 гг.) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2016. – №3/4. – Б.292.
[11] Мухамадеева Л. Издательская деятельность кряшен (1920-1930 гг.) // Гасырлар авазы – Эхо веков. –

Игнатий Алексеевич 1926-1931 елларда Өлкә партия-совет мәктәбендә, керәшен техникумында, рабфакта укыта, төрле педагогик курслар эшен оештыруда катнаша, керәшен педагогик курслары советы рәисенең урынбасары вазыйфасын башкара. Татар коммунистик университетында башта ассистент, соңрак доцент итеп билгеләнә. Кайбер мәгълүматлар буенча, 1930 елларда ул Татгосиздат редакторы булып та эшли[12]. 1931 елдан соңгы хезмәт эшчәнлеге Казан финанс-икътисад институты белән бәйле. 1940 елда физика-математика фәннәре буенча кандидатлык диссертациясе яклап, шактый әзерлекле, тәҗрибәле галим булып җитешә.

И.Алексеевның фәнни-педагогик эшчәнлегенең иң төп юнәлеше, әлбәттә, совет мәктәбе өчен гаять әһәмиятле булган математика укыту мәсьәләләре белән бәйле. Бу яктан караганда, ул совет чорында математиканы татар телендә укыту методикасын эшләүчеләрнең берсе буларак каралырга хаклы. И.Алексеевның укучысы Т.Хәкимуллин да тикмәгә генә, «Математика» дигән серле дөньяны ачарга ярдәм иткән укытучысының эшенә бәя биреп, аны «математика укыту өлкәсендә эшләүче татар педагогларының иң күренеклеләреннән берсе»[13], дип атамагандыр, мөгаен. Игнатий Алексеевичның исеме, башлангыч һәм урта мәктәпләрдә математика укыту буенча күп санлы әсбаплар, мәкаләләр авторы буларак, 30-50 нче елларда татар мәктәпләре укытучыларына яхшы таныш була. Шуның белән бергә, озак еллар дәвамында татар мәктәпләре өчен чыгарыла торган математика дәреслекләренең күбесе аның мөхәррирлегендә чыгып килгән.

Шул ук вакытта, Игнатий Алексеев, галим буларак, гыйльми хезмәтләр, югары мәктәпләр өчен дәреслек һәм кулланмалар да язган. Аның партия мәктәбенә һәм татар коммунистик университетына керергә әзерләнүчеләр өчен 1930 елда басылып чыккан «Математика дәресләре», «Математика. Элементар курс» (1931), «Югары математика нигезләре» (1953) дигән дәреслекләре, татар студентларына югары белем алуда зур ярдәмче булу өстенә, 20-30 нчы еллар башында Татарстанда бик актуаль булган татар телендә югары белем бирү юнәлешен тормышка ашыруда да әһәмияткә ия булган.

Методист-галим, татар телендә белем бирү проблемасын хәл итүдә, төгәл һәм камил методикадан тыш, мөкәммәл һәм татар теленең үсеш закончалыкларына туры килгән, шул ук вакытта фән югарылыгында эшләнгән атамалар, ягъни терминологиянең дә әһәмияте зур булуын яхшы аңлаган. «Югары математика нигезләре» дәреслегеннән соң татарча-русча математик атамалар сүзлекчәсе бирелү, бер яктан, әлеге мәсьәләне хәл итүгә булышлык итсә, икенче яктан караганда, татар урта мәктәбен тәмамлап, югары техник уку йортларына укырга керергә теләүче абитуриентларның алга таба рус телендә югары белем үзләштерүләрен җиңеләйтүне дә күздә тоткан.

Гомумән алганда, И.Алексеев телгә карата гаять игътибарлы булган. Галим бала кечкенәдән үк үз телендә укырга һәм фикерләргә тиеш, ана телендә укыганда ул башка фәннәрне дә тизрәк үзләштерә ала дип санаган. И.Алексеев математика укытучыларының да туган телгә карата сакчыл мөнәсәбәттә булуларын таләп иткән. Кайбер укытучыларның баланың мәсьәлә яки мисалны дөрес чишүләре белән генә канәгатьләнеп, аның телендәге кытыршылыкларга, сөйләм кимчелекләренә, ялгышларына күз йомуларын да тәнкыйтьләгән. Аның фикеренчә, укучы математикада бирелә торган формулаларны, кагыйдәләрне, гамәлләрне, терминнарны дөрес үзләштерергә һәм әдәби яктан дөрес итеп сөйләп бирә белергә, аның теле шома, фикере төгәл булырга тиеш. Монда, әлбәттә, математика укытучыларының роле искиткеч зур.

2016. – № 3/4. – Б.292

[12] Мухамадеева Л. Издательская деятельность кряшен (1920-1930 гг.) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2016. – № 3/4. – Б.291.

[13] Хәкимуллин Т. 35 еллык хезмәт // Совет мәктәбе. – 1939. – №10-11. – Б.24.



— 25 —

Minem simjə.

Ətej. Ənej. Dədəj. Əвej. Вaвaj. Min.

Min uqьjьm. Ətej qamьt tөzətə. Ənej cəj qajnata. Dədəj uqьj. Baвaj caвata jasьj. Idəndə məce ujnьj. Uramda et өrə. Bala вişektə jata. Əвej вişek tirвətə. Dədəj də tik utьrmьj - uqьj. Min də uqьjm.

Ənej — ənejlər.

Əвej — əвejlər.

Dədəj—dədəjlər.

И.Алексеев һәм В.Гороховның керәшен мәктәпләре өчен «Нур» (1929) уку китабы

И.Алексеевның математика укытуга караган кайбер карашларына тукталып узыйк. Тәҗрибәле методист буларак, ул математика мәктәптә балаларга җиңел һәм аңлаешлы итеп укытыларга тиеш, дип санаган. «Арифметика методикасы буенча җыентык» дигән методик әсбабында галим арифметика дәресләрендә төрле методларга таяну мөһимлеген, нәтиҗәдә, укучыда математик тикшерүләрдә фикер йөртүнең киңәюе, сыгылмалылыгы артуын искәртә. Ул шулай ук әлеге фәннең нигезен тәшкил иткән мәсьәләләр чишүгә зур игътибар бирергә кирәклеген дә ассызыклаган, «мәсьәләләр чишү балаларны арифметикадан алган белемнәрен практик тормышта куллана белергә өйрәтә, баланың логик уйлый һәм фикер йөртә белү сәләтенең үсешенә ярдәм итә» дип санаган. Ләкин шул ук вакытта, аның фикеренчә, бу шактый катлаулы һәм җитди эштә балаларның акыл үсешен, белемнәрен, психологиясен нык игътибарда тотарга кирәк, мәсьәләләр эчтәлеге белән балага якын һәм аңлаешлы булырга тиешләр[14]. Ягъни, бүгенге фән күзлегеннән чыгып караганда, бу укучыларның яшь үзенчәлекләрен, акыл үсешен, фикерләү мөмкинлекләрен, сәләтен һәм кызыксынуларын истә тоту дигән сүз була. Әлеге принциплар хәзерге педагогикада да иң әһәмиятлеләрдән санала.

Игнатий Алексеевның татар мәгарифе үсешенә керткән өлеше һәм киң җәмәгатьчелек эшчәнлеге Татарстан хөкүмәте тарафыннан да билгеләп үтелә. 1929, 1939 елларда мәгърифәтче-галимнең педагогик эшчәнлегенә 25, 35 ел тулу матбугатта шактый тулы яктыртыла. Аның 35, 50 еллык юбилейлары Казан финанс-икътисад институты галимнәре тарафыннан зурлап үткәрелә. И.Алексеевның Татарстан фәнен һәм мәгарифен үстерүгә керткән күпьеллык нәтиҗәле хезмәте хөкүмәт тарафыннан олы бәяләнә, 1951 елда аңа «ТАССРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. ■

[14] Алексеев И. Беренче класста арифметик мәсьәләләр чишү турында // Совет мәктәбе. – 1953. – №5. – Б.24.

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе

Радик Исхаков

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе бинасы. 2019 елгы фото

1860-1870 еллардагы реформалар нәтиҗәсендә керәшен татарлары, чуаш, мари һәм удмуртларның башлангыч белемне туган телдә алу мөмкинлеге булган милли уку йортлары барлыкка килә. Бу уку йортлары мәдәният үсешенә, милли зыялылар барлыкка килүгә зур йогынты ясый. Идел буеның фән-мәгариф һәм административ үзәге булган Казан шәһәрендә атаклы миссионер Н.И.Ильминский идеологиясе нигезендә эшләүче беренче уку йорты – Казан үзәк керәшен-татар мәктәбенә нигез салына.

Төбәк халкының мәгариф торышы белән бик яхшы таныш булган Н.И.Ильминский «әҗнәби»ләргә мөнәсәбәтле дини һәм мәктәп сәясәте системасын тамырдан үзгәртергә кирәк, дигән фикергә килә. Төбәктәге рус булмаган халыкларга христиан динен массакүләм көчләп тагу мөмкин түгел икәнен аңлап, ул рухы белән милли булган мәктәпләрне христиан динен тарату өчен җирлек итеп файдалану һәм мәгариф ярдәмендә «әҗнәбиләрне рухи яктан руслаштыру» идеясен тәкъдим итә. Миссионер яңа концепцияне эшләү чорында керәшен татарлары өчен мәктәп мәгарифен үстерергә, дәреслекләр һәм христиан дине әдәбиятын татар теленә тәрҗемә итәргә сәләтле, яңа ачылачак башлангыч мәктәпләр өчен педагогик кадрлар әзерли торган аерым мәгариф үзәге булдырырга кирәк дигән карарга килә. Бу максатларга ирешер өчен, Н.И.Ильминский тарафыннан 1864 елда Казан шәһәрендә керәшен татарлары өчен махсус уку йорты ачыла. Хакыйкатьтә бу мәктәп 1863 елдан – В.Т.Тимофеев (1836-1893) туган авылы Чиябаштан өч ир баланы үз квартирасында грамотага һәм христиан тәгълиматына өйрәтә башлаган вакыттан ук эшли башлый[1].

«Ильминский системасы»ның нигезендә рус булмаган халыкларның үз туган телләреннән файдаланып православиегә түнтәрү яки яңа чукынганнарда христиан динен ныгыту идеясе ята. Моның өчен башлангыч белемне татар телендә бирә торган мәктәпләр барлыкка килә, кириллица нигезендә татар һәм башка милли телләрдәге алфавитлар эшләнә, дини эчтәлектәге китаплар татар яки башка милли телләргә тәрҗемә ителә. Әлеге басмалар мәктәпләрдәге уку программасына кертелә, милли мәхәлләләрдәге йолаларны татар телендә башкарганда, дога-келәүләрне укыганда файдаланыла башлый. Үз кан кардәшләрен, авылдашларын чукындыра, аларны христиан диенә күндерә торган рус булмаган христиан руханилары формалаша. Нәтиҗәдә, гади халыкның православ диненә ининуы арта, рус булмаган милли зыялылар барлыкка килеп, керәшен хәрефләре белән укый-яза белүчеләрнең дә саны ишәя.

Н.И.Ильминский мәктәп ачу һәм аңа рәсми статус бирү нияте белән 1864 елның августында Казан уку-укыту округы попечителенә Казандагы керәшен татарларын В.Т.Тимофеев җитәкчелегендә укыту өчен шәхси уку йорты ачуны сорап мөрәҗәгать итә[2]. Бу тәкъдим П.Д.Шестаков тарафыннан хуплап кабул ителә. 1864-1865 уку елында ук инде рәсми теркәлгән мәктәп үз эшен башлап җибәрә. Ир балалар шәхси акчаларга вакытлыча файдалануга алып торылган әзер фатирда яшәргә, әти-әниләре тарафыннан, хәлләренә карап кием һәм азык-төлек белән тәэмин ителергә тиеш була. Уку өчен акча алынмый[3]. Бу мәктәпнең эшчәнлеген күзәтеп тору вазыйфасы Н.И.Ильминский һәм академия бакалавры Е.А.Маловка тапшырыла[4].

Арча кырында урнашкан, өч укучы, бер укытучы һәм аның гаиләсе яши торган кечкенә генә шәхси пансион берничә елдан шактый зур мәктәпкә әйләнә. Икенче елда биредә укучыларның саны 20гә җитсә, 1866 елда ике мәртәбә арта. Укырга теләүчеләрнең саны ишәю белем бирү процессын тагын да камилрәк оештырырга һәм аерым бина төзүгә ихтыяҗ тудыра. 1867 елда мәктәп Н.И.Ильминскийның тырышлыгы, П.Д.Шестаков һәм Казан архиепискобы Антоний (Анфитеатров) ярдәме белән сәүдәгәр Арефьевның Арча кырында төзеткән бинасында урнаша. 1867-1868

[1] Знаменский П. Отец Василий Тимофеевич Тимофеев. – Казань, 1896. – С.5-7.
[2] Витевский В.Н. Н.И. Ильминский. Директор Казанской учительской семинарии. – Казань, 1892. – С.13.
[3] Казанская центральная крещено-татарская школа. – Казань, 1886. – С.76.
[4] Витевский Н.И. Указ. соч. С.13.

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе директоры Т.Е.Егоров укучылары белән. XX гасыр башы фотосы. (Чичерина С.В. У приволжских инородцев. – СПб, 1905)

уку елында Казан үзәк керәшен-татар мәктәбендә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен мөстәкыйль бүлекләр эшли башлый[5].

Яңа системада укыта торган беренче уку йорты буларак, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе атаклы миссионерлар Н.И.Ильминский һәм В.Тимофеев тарафыннан эшләнгән алдынгы методиканы гамәлгә ашыру өчен үзенә күрә бер лаборатория дә була. Беренче елларында Казан үзәк керәшен-татар мәктәбенең анык уку планы һәм штаты булмый. Миссионерлар фикеренчә, мәктәптәге гадәти уку процессы педагогик эшчәнлеккә һәм өйрәнергә кирәк булган предметларга юнәлешне үзе бирергә тиешле санала. Н.И.Ильминскийның эмпирик характердагы әлеге системасы В.Тимофеевның педагогик эшчәнлеген кирәкмәгән бюрократик регламентлардан азат итә, дәүләт тарафыннан расланган программалар белән дә чикләми. Шул сәбәпле, дәүләт структураларының матди ярдәме, кайгыртуы булуына карамастан, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе шәхси уку йорты булып кала. Ул Халык мәгариф министрлыгына да, Изге Синодның училищелар советына да буйсынмый. Мәктәп җитәкчелегенең укыту һәм тәрбия эше буенча карарларны мөстәкыйль кабул итүе миссионерларга керәшен татарларының дини һәм мәгариф проблемаларын якыннанрак белеп, тизрәк хәл итәргә мөмкинлек бирә. Дөрес, 1872 елда оешкан Казан укытучылар семинариясенә генә формаль булмаган буйсыну була, әмма бу мөнәсәбәт уку йортлары җитәкчеләре В.Тимофеев һәм Н.Ильминскийның, ә алар вафатыннан соң Т.Егоров һәм Н.Бобровниковларның үзара дустанә мөнәсәбәтенә нигезләнә.

Шул сәбәпле, мәктәптә иң беренче планда дини белем бирү булып, уку йортын тәмамлаучылар керәшен татарлары арасында христиан мәгърифәтен таратырга тиеш санала. Мәктәптә *«...төп укыту предметлары – татарча (әмма урыс хәрефләре белән) басылган китаплар буенча Ходай боерыклары дәресләре, догалар, изгеләр тари-*

[5] Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар в Поволжье. – Казань: Таттосиздат, 1941. – С.102-105.

Мәктәп җитәкчесе Т.Е.Егоров һәм П.В.Егорова (Тимофеева) мәктәп укучылары арасында. XX гасыр башы фотосы. (Чичерина С.В. У приволжских инородцев. – С.П-б., 1905)

хы һәм кыскача катехизис» була. Яңа һәм Иске Закондагы сюжетларны аңлату өчен немец рәссамы Юлиус Шнорр фон Карольсфельдның дини темага язылган картиналарын файдаланганнар. Православ нигезләре иң беренче көннәрдә үк укытылган. «Букварь»ны тәмамлаган укучылар татарчага тәрҗемә ителгән «Бытия», «Ходайның акыл кенәгәсе»н һәм «Матвей язган ару Евангелие»не укуга күчкән[6]. 1871 елда Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе янында иман йорты төзелгәннән соң, иртәнге һәм кичке гыйбадәтләр мәҗбүри итеп куела. Чиркәү җыруына аеруча зур игътибар бирелә. В.Т.Тимофеев беренче уку елында ук үз укучыларыннан хор оештыра. Әмма Н.И.Ильминский чиркәү җыруы керәшен татарларында православ диненең ныгуына эмоциональ тәэсир итәчәк, дип ялгыша.

Дини фәннәр белән бергә биредә рус теле, арифметика һәм сызым, география фәннәре дә укытыла. Баштарак белем бирү укучыларның туган телендә алып барыла. Татар теленә тәрҗемә ителгән православ әдәбияты белән танышып, туган телдә укырга һәм язарга өйрәнгән укучылар рус телен өйрәнергә керешә. Мәктәптә рус телен укыту методикасы дини әдәбиятны «тәрҗемә кылу»га нигезләнгән була. Телнең грамматик формалары белән танышу Н.И.Ильминскийның кыргызлар өчен төзегән рус грамматикасы нигезендә башкарылып, шуннан соң гына рус телендә Изге тарих һәм Инҗил укылган. Уку процессында бу китапларны татар теленә тәрҗемә итү белем бирү һәм материалны истә калдыруның бер ысулы булган. Укуның беренче елларында мәктәптә гыйлем алу вакыты чикләнми – укучыларның үз ихтыярына гына нигезләнә.

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбендә укучылар үзләрен гаиләдәге кебек тотып, бернинди ясалма форма, тән һәм башка төрле җәзалар булмаган. Мәктәптә укытуның нигездә дини фәннәр белән генә чикләнгән булуы В.Тимофеевның гыйлем дәрәҗәсе югары булмауга – нибары 4 класслы мәхәллә училищесын гына тәмамлаганлыгына бәйле. Әмма укучыларның белемгә омтылышы көчле була. Керәшен татарлары ара-

[6] Витевский Н.И. Указ. соч. С.14

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе. 1872 елгы фото

сында христиан мәгарифен тарату өчен, В.Тимофеев, үз укучылары белән җәйге каникул вакытында авылларга чыгып, халыкка православ китапларын, догалар укыган, укучыларының укый-яза белүләрен күрсәтеп, балаларны Казанга укырга чакырган. Шул сәбәпле мәктәпнең исеме тиз арада халык арасында танылу ала. Бирегә Казан губернасыннан гына түгел, Уфа, Самара һәм Вятка губерналарында яшәүче керәшен татарлары үз балаларын җибәрә башлый. Шулай ук татар телен белүче ар, чирмеш, чуаш һәм мукшы балалары да кабул ителә. 1872-1873 елларда мәктәптә укучыларның саны 165кә җитә. Шуны да искәртик: Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен тәмамлаучылар арасында православ текстларын чуаш теленә тәрҗемә итүче, чуаш әлифбасын булдыруда катнашкан педагог, фольклорчы Сергей Николаевич Тимрясов (1851-1910), мукшы (эрзә) әлифбасына нигез салучы педагог, «Инҗил» һәм башка христиан дини китапларын эрзә теленә тәрҗемә иткән дин әһеле, этнограф Авксентий Филиппович Юртов (1854-1916) та бар.

1867 елдан Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен үстерү өчен, Изге Синод тарафыннан 1000 сум акча бүлеп бирелә башлый. 1869 елда бу сумма 4050 сумга кадәр җиткерелә. Шул ук елда Халык мәгариф министрлыгы тарафыннан мәктәп өчен яңа бина төзелешнә 10000 сум, ә миссионер укытучы В.Т.Тимофеевны бүләкләү өчен 500 сум акча тәгаенләнә[7]. Алга таба мәктәпнең ихтыяҗларын кайгырту максатына да даими финанс карала. XX гасыр башында мәктәпнең еллык бюджеты 14105 сум 86 тиен тәшкил итә. Чыгымның 5923 сум 88 тиенен – Халык мәгариф министрлыгы, 3450 сумын – Православ миссионерлык җәмгыяте, 700 сумын – Изге Синод, 500 сумын –

[7] Письма Н.И. Ильминского к графу Дмитрию Андреевичу Толстому, Обер-прокурору Святейшего Синода, 31 марта 1866 года. // Казанская центральная крещено-татарская школа. – Казань, 1887 – С.176-180.

Казан земствосы, 500 сумын мәктәпнең хәйриячесе, чиркәүләр төзелешенә (шул истәптән керәшен авылларында да) акчасын кызганмаган сәүдәгәр Павел Васильевич Щетинкин (1845-1918) финанслаган. Моннан тыш, Казан Руханилар академиясе профессорлары, Казанның эре сәүдәгәр-хәйриячеләре, патша гаиләсе тарафыннан да мәктәп укучыларына махсус стипендияләр булдырыла[8].

В.Т.Тимофеев. 1860 нчы еллар башы (Gokgoz S.S. Yevfimiy Aleksandroviç Malov. Idil - Uralda islam karsiti rus misyon siyasete. - Ankara: Hacettepe Üniversitesi 2007)

1878 елда Казан үзәк керәшен-татар мәктәбенең уку программасы киңәйтелә – ике класслы авыл училищесы курсына тәңгәлләштерелә. Программаны үзгәртеп кору уку системасын унификацияләү, хәрби реформа кебек империядә барган гомум процессларга бәйле. Мәктәп курсын тәмамлап земство һәм министерство башлангыч мәктәпләрендә укытучы булып эшләр өчен уку планы Мәгариф халык министрлыгы программаларына туры килергә, ә уку йортын тәмамлаучылар, мәҗбүри аттестация узып, имтихан тапшырырга тиеш була. Программага туры килсен өчен, предметларның саны, укытучыларның штаты арттырыла, кануни укытучы вазыйфасы кертелеп, аңа В.Тимофеев тәгаенләнә. Патшаның 1878 елның 29 маендагы карары нигезендә, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе 3 нче разрядка кертелә һәм анда тәрбияләнүчеләр хәрби бурычтан азат ителә. Мәктәп ике класска бүленеп, анда укырга түбәндәрәк дәрәҗәдәге «әҗнәби» училищеларын тәмамлап, башлангыч белем алганнар да кабул ителә. Ике класста да уку вакыты, укучыларның өлгерешенә карап, өч елдан да ким булмаган[9].

1883 елда мәктәптә өченче, ә 1901 елда дүртенче класс ачыла. Рус тарихы, табигать белеме, физика һәм рәсем сәнгате дәресләре кертелә, рус һәм чиркәү-славян (иске рус) телләрен укыту тагын да киңәйтелә[10]. Уку йортын тулысынча үзгәртеп кору эше 1908 елда, тәрбияләнүчеләр өчен үрнәк педагогик башлангыч училище ачылганнан соң тәмамлана.

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе оешкан вакытта ук башлангыч миссионер мәктәпләренә укытучылар әзерләргә тиеш була. 1865-1866 елларда беренче чыгарылыш укучылары тарафыннан Никифоровода кызлар, Әрнәш һәм Апаз авылларында ир һәм кыз балалар бергә укый торган мәктәп ачыла. Бу мәктәпләр турыдан-туры Казан үзәк керәшен татар мәктәбенә буйсынып, П.Знаменский язганча, аның «кечкенә колонияләре»н тәшкил иткән[11]. 1867 елда Казанда оешкан миссионерлык Изге Гу-

[8] РГИА. Ф.733. Оп.173. Д.101. Л.5.
[9] РГИА. Ф.733. Оп.170. Д.1046. Л.2.
[10] Отчет Казанской центральной крещено-татарской школы за 1903-1904 учебный год. – Казань, 1904. – С.1-2.
[11] Знаменский П.В. На память о Н.И. Ильминском. К двадцати пятилетию братства святителя Гурия. – Казань: Тип. Ильяшенко, 1892. – С.196.

рий туганлыгы, 1870 елларда Православ миссионерлык җәмгыятенең Идел буе комитетлары рус булмаган халыкларга башлангыч дини белем таратуны максат итеп куйганнан соң, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе педагогик кадрлар әзерли торган төп үзәккә әверелә. Аның җитәкчелеге, алда әйтелгән миссионерлык оешмалары советы белән бергә, керәшен авылларында ачылган мәктәпләрдәге мәгариф эшенең торышын контрольдә тоткан. Нигез салынганнан алып 1914 елга кадәр Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен 4449 укучы ир һәм 1887 кыз бала тәмамлый. Ир балалардан 636сы, кызлардан 260ы авыл башлангыч мәктәбе укытучысы таныклыгы ала[12].

1867 елдан башлап, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбендә авыл мәктәпләрендәге укытучылар өчен еллык педагогик курслар оештырыла башлый. Гадәттә әлеге курсларга алдагы елларда бу мәктәпне тәмамлаганнар килгән. Биредә укытуның яңа ысулларына, рус телен һәм «миссионерлык фәннәре»н өйрәнүгә аеруча зур игътибар ителгән[13]. 1890 нчы елларда курсларга Идел-Уралның башка төбәкләреннән дә милли башлангыч мәктәп укытучылары килә башлый. Аерым алганда, 1895 елда курсларда катнашкан 78 кешенең 58е – Казан, 9ы – Сембер, 7се – Вятка, 1се – Пермь, 1се – Саратов, 2се Уфа губернасыннан була. Шуларның 26сы – татар, 15е– чуаш, 12се – мари, 8е – удмурт, 6сы – рус, 1се – мукшы милләтеннән[14].

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе, үз эшчәнлеген киңәйтеп, керәшен татарларының мәгариф, дини һәм мәдәни үзәгенә әйләнә. Укучыларның һәм укытучыларның тырышлыгы белән Инҗил һәм башка христиан дине китапларын татарчага тәрҗемә итү юнәлешендә зур эшләр башкарыла[15]. Үз чиратында әлеге керәшен-татар басмалары Урта Идел буеның башка халыклары теленә тәрҗемә итү өчен дә нигез булып тора. Н.И.Ильминский искәртүенчә, мәктәп укытучылары һәм укучылары, миссионер тәрҗемәчеләргә зур ярдәм күрсәтеп, «Изге Гурий туганлыгы каршындагы Православ миссионерлык җәмгыятенең тәрҗемә комиссиясе» әгъзасы булып та тора. Аларга басмага әзерләнә торган китапларның хаталарын тикшерү, җирле сөйләшләргә туры килсен, ягъни җиңел аңлаешлы булсын өчен, керәшен татарлары авылларына барып, изге китапларны халыкка укып карау, яңа басмаларны тарату кебек вазыйфалар йөкләнә. Башкалар белән чагыштырганда, христиан дини әдәбияты татар теленә, шул исәптән чуаш теленә дә шактый күп тәрҗемә ителгән. Бу эштә Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе һәм Сембер чуаш укытучылар мәктәбе зур роль уйный, ә башка милләтләрдә мондый мәгариф үзәкләре булмый. Тулы булмаган мәгълүматка караганда, 1914 елга кадәр Казан үзәк керәшен-татар мәктәбендә 565139 данә тираж белән 77 китап татар теленә тәрҗемә кылына. Алар, нигездә, дини-дидактик эчтәлектә язылган.

Күренекле миссионер оештырган әлеге уку йорты керәшен татарларының мәгариф үсешенә, дини үзбилгеләнүләре ныгуына, нигездә үз укучыларыннан торган керәшен зыялылары формалашуга зур йогынты ясый. Н.И.Ильминский системасы Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе ярдәмендә Урта Идел буендагы рус булмаган башка халыкларның да милли мәгарифенә, аларда христиан диненең ныгуына сизелерлек тәэсир итә. ■

[12] Ильминский Н.И. О системе просвещения инородцев и о Казанской центральной крещено-татарской школе (к пятидесятилетию системы и школы, а также необходимые справки к указу №8608 о просвещении инородцев). – Казань, 1913. – С.93.

[13] Отчет о деятельности Братства святителя Гурия за семнадцатый учебный год. С 4 октября 1883 года по 4 октября 1884 года. – Казань, 1884. – С.11.

[14] Горохов В.М. Указ. соч. С.110.

[15] Ильминский Н.И. О применении русского алфавита к инородческим языкам // Николай Иванович Ильминский. Сборник статей по поводу 25-летия со дня кончины его (27 дек. 1891 г.) – Казань: Центральная тип., 1916. – С.134.

«ТАТМЕДИА» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Татарстан китап нәшрияты,
«Безнең мирас» журналы редакциясе

ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс 2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр үткәрелә.

Конкурска үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

Конкурска юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга һәм барлык катнашучыларга сертификат биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

РИКША

Япониядә минем өчен сәер булып күренгән иң беренче нәрсә рикша булды. Шуңа күрә иң башта аның турында мәгълүмат бирергә телим. Рикша – кеше утыртып йөртә торган, ике тәгәрмәчле арба. Болай гына аңлатып китү, әлбәттә, җитәрлек түгел, тагын бераз ачыклый төшәргә кирәк. Япониянең җир өсте мәйданы бик аз. Нигездә, ул өч меңгә якын кечкенә-кечкенә утраудан гыйбарәт. Болар арасында шулкадәр кечкенәләре бар ки, берничә генә йорт салып, аларда берничә генә гаилә яши. Бу утрауларның гомуми мәйданы 417412 квадрат километр тәшкил итә һәм шул кечкенә генә илдә яшәүче халыкның саны 50000000нан артып китә. Һәр квадрат километрга якынча 400дән артык[1] кеше туры килә. Моннан һәрвакыт кар астында яткан тауларны һәм янар тауларны алсак, һәр квадрат километрга 500ләп кеше туры киләчәк. Менә шул коры җир өсте мәйданының аз булуы сәбәпле, Япониядә хайван үрчетелми икән.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Фикеребезчә, бу урында бераз төгәлсезлек бар. Бер квадрат километрга 120гә якын кеше туры килә. Бу да аз сан түгел, әлбәттә (тәрҗ. иск.).

Хайваннар юк дәрәҗәсендә аз, шунлыктан, хайваннар башкара торган хезмәтләрне дә кешеләр башкара икән. Мәсәлән, Русиядә ерак җирләргә йөкне арба җигелгән ат ярдәмендә ташыйлар. Төркиядә – үгезләр, буйволлар җигелә, Гарәбстанда – дөяләр ярдәмендә, Япониядә исә, бу эш кешеләр тарафыннан башкарыла. Нинди генә авыр йөк булмасын, барысын да кешеләр ташый. Кеше тарафыннан тартып йөртелә торган бу арбаларга «рикша» диләр.

бачылар кебек. Кечкенә генә гәүдәле япон кешесе арбаны шулкадәр кызу тартып бара ки, шаккатарлык.

Мин бу турыда күп сораштым: арба тартучы кешеләрнең бөтен көчләре – аякларында. Аларның балтырлары башка кешеләрнекенә караганда калынрак, хәтта авырулары да күбесенчә аякларында була икән. Башка эшчеләр белән чагыштырганда, боларның гомерләре дә кыскарак икән. Токио шәһәрендә 14000 рикша бар. Элегрәк алар тагын да күбрәк



Бу рикшалар шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да күп. Бер авылдан икенче авылга әлеге рикшалар белән барырга мөмкин. Бик ерак юлларга да чыгалар. Үр югары, үр түбән – гел шул рикшалар йөри. Рикшаның тизлеге, әгәр таләп ителсә, сәгатенә 12 километрга кадәр җитә ала, уртача 8-10 километр ара үтә.

Мин, махсус, рикша белән юл йөреп, шуны күрдем: арба тартып һәм йөгереп баручы кеше уртача сәгатенә 10 километр юл үтеп, бертуктамыйча 2,5-3 сәгать бара ала. Моның бәясе – безнең акча исәбе белән беренче сәгать – алты тиен, икенче сәгате – өч, аннан соң һәр сәгате – ике тиен. Нәкъ менә безнең арбулган. Электр трамвайлары күбәйгәч, рикшалар ике тапкыр диярлек кимегән. Хәзерге вакытта саннары һаман да кими бара, хөкүмәт тә боларны киметер өчен шактый көч куя икән. Гомумән, хөкүмәт хайван үрчетү фикерен алга сөрә башлаган. Микадо җәнаплары бу эшне шәхсән үзенең вазыйфасы итеп саный, ди. Мин Япониядә яшәгәндә, рикша белән бик күп юл йөрдем. Бервакыт хәтта бер авылдан үтеп барганда бер газета хәбәрчесе фоторәсемгә төшереп алган булып чыкты.

Бу турыда, ягъни рикша хакында Кытайдан да язачакмын, шул сәбәпле, монда сүзне кыска тоттым.

Безнең мирас №7 июль 2019

ЙОКОХАМА

Япониянең атаклы сәүдә портларының берсе – Йокохама шәһәре. Мин Япониягә килгәч, башта биредә яшәдем һәм япон милләтен дә иң беренче биредә таныдым, дип әйтсәм дә урынлы булыр, чөнки юлда күргәннәрем бары тик очраклы күренешләр генә иде.

Йокохамада 200000нән күбрәк кеше яши. Бу бик зур шәһәр һәм Япониянең Аврупа белән сәүдә итү өчен ачылган беренче порты да булып тора. Мин бирегә беренче тапкыр 20 октябрьдә[2] килдем. Иртән иртүк шәһәр карарга чыктым. Йорт хуҗасына: «Монда кире әйләнеп кайта алыр өчен миңа адресыгызны бирегезче», – дидем. Аның белән японча сөйләшәбез. Мин дәфтәргә алдан язылганнарга карап, әйтергә теләгән фикеремне аңлатырга тырышам. Вазгыять телне өйрәнергә мәҗбүр итә. Йорт хуҗасы миңа: «Безнең шәһәребездә бары тик бер генә бакча бар. Рикшага: «Мокой кэрин» (ягъни, «Бакча каршысында»), – дисәгез, шунда ук аңлар һәм бирегә китерер», – диде.

Өс-башым, әлбәттә, японнар өчен бик сәер булып күренгәндер. Күне буе йөрдем, ләкин сәерсенеп караган бер генә кеше дә очратмадым. Ә менә японнарның бар нәрсәсе дә мине гаҗәпләндерә иде. Иң беренче булып игътибарымны җәлеп иткән нәрсә шул булды: халык искиткеч хәрәкәтчән, урамнарда кеше ташкыны ага диярсең. Баручыларның һәм кайтучыларның исәбе дә, очы-кырые да юк. Болар, йөгереп диярлек, бик тә кызу йөриләр.

Бигрәк тә ирләрнең дә, хатын-кызларның да аякларындагы агач башмакларның тыкыртысы бик сәер булып тоелды. Әле дә шөкер, урамнарда күтәртмә юллар юк, урамнарга көнгә берничә тапкыр су сибелә, шул сәбәпле, бик ачык ишетелми, алайса, колакларны тондырыр иде.

Йокохаманың төньяк чиге – диңгез, як-ягын таулар әйләндереп алган. Шәһәрнең бер өлеше калкулыкларга урнашкан булса да, күбрәк өлеше – тигезлек. Дөресрәге, ул бөтенләе белән елга өстендә торган кебек. Шәһәр аркылы әллә ничә елга, канал агып үтә, күперләрне санап бетерерлек түгел. Бөтен көн буе, трамвайга утырып, Йокохаманың бер ягыннан икенче ягына бардым, кайттым. Электр трамвае Йокохамада чагыштырмача күп түгел, трамвай йөрмәгән якларына җәяү барып килдем.

Шәһәрнең кай җиренә генә барсаң да, японнарның һәртөрле осталыкка ия бик эшчән милләт булуын күрергә мөмкин. Кая карама – халык ташкыны. Бөтен урамнар зур һәм кечкенә кибетләр, остаханәләр, фабрикалар белән тулы. Бер генә җирдә дә тик утырган бер генә кеше дә очрата алмассың. Кайда нинди зур бина күренсә, мәктәп булып чыга. Хөкүмәт йортлары, консуллыклар, кунакханәләрне исәпкә алмасаң, мәктәпләрдән кала, зур биналар һич юк. Шәһәрдәге бөтен йортлар диярлек – бер катлы, ике катлылары бик сирәк очрый.

Һәр урам башында телефон һәм полиция алачыклары японнарга хас ысул белән төзеп куелган. Телефон алачыгы тормаган бер генә урам башы да күрмәссез. Моннан тыш, күз төшә торган ачык урыннарга, кызыл төскә буялган, кеше буендагы юан баганаларны хәтерләтә торган почта әрҗәләре куелган. Бер ягында хат сала торган тишек бар. Мондый почта әрҗәләрен башка бер генә мәмләкәттә дә күрмәдем. Иртәнге сәгать 6дан төнге 2гә кадәр һәр сәгать саен бу почта әрҗәләрен ачып, хатларын алалар.

Караңгы төшә башлаганчы, шәһәр буйлап йөрдем. Кичке ашны ашаганнан соң, тагын йөрергә чыктым. Йокохаманың халык иң күп йөри тор-

---

[2] Бу урында китапта тәшрин-е әүүәл (октябрь) дип язылса да ул, төгәлсезлек булып, тәшрин-е сани (ноябрь) булырга тиеш, чөнки алдарак ноябрь турында сүз барды (тәрҗ. иск.).

ган бер төшендә, берсе урамның уң ягында, берсе сул ягында урнашкан, бөтен кирәк-ярак сатыла торган ике кибет бар. Шул кибетләрдә йөрергә дип бара идем, юлда бер рус кешесен очратып, сәлам бирдем. Танышып киттек: бу кешенең Петербургтан махсус җибәрелгән офицер икәнен аңладым. Миннән: «Кая барышың?» – дип сорады. «Бераз йөрергә чыктым. Кибеткә дә керермен дигән идем», – дип җавап бирдем. «Әйдә, бергә йөрербез. Минем дә эшем юк, вакыт үткәрер өчен генә чыккан идем», – диде.

Бергә кибеткә кереп, карап йөрдек. Кечкенә генә кибет икән, искитәрлек берни дә күрмәдем. Кабат урамга чыктык. Соңыннан аралашканда шуларны белдем: бу кеше – Русиядә телләр өйрәтә торган уку йортында япон телен өйрәнгән, аны тәмамлаганнан соң, берничә тапкыр Япониядә булган белгеч икән.

Русиядә Хәрбия нәзарәтенә Департамент диләр. Азия илләренә караган мөдирлекнең вазыйфасы – Азия халыклары, аларның хәлләре турында мәгълүмат туплап, Департаментны хәбәрдар итү. Шул сәбәпле, Азиядә яши торган халыкларның телләре мөдирлек таләбе буенча махсус өйрәтелә һәм бу илләрне яхшы танып-белү өчен, белгечләр җитештерүгә дә күп көч куела. Мәсәлән, Төркестан белгече, Кытай белгече, Һиндстан белгече, Анатолия (Кече Азия) белгече, Сирия белгече, Африка белгече һ.б. кебек һәр кыйтганың үз белгече бар. Кытай кебек зур илләрнең көнбатышы, көнчыгышы, көньягы, төньягы өчен дә хәтта аерым-аерым белгечләр җитештерелә. Монголиянең, Тибетның, Төркестан Кытаенның аерым белгечләре бар. Боларның күбесе бер үк вакытта офицер да, топография белгече дә. Барысына да һәр ел бу илләргә барып, анда яшәү өчен махсус акча бүлеп бирелә. Кайберләренә гаҗәеп күп акчалар, исемнәре үзгәртелгән паспортлар да бирелергә мөмкин. Моннан якынча ун еллар элек, Левкин фамилияле бер офицер, Куропаткин башкомандующий булып торган заманда, 15000 сум акча белән Һиндстанга җибәрелгән иде. Мөхәммәд Хәсән улы исеме белән, дәрвиш кыяфәтенә кереп, ике ел буе бу илдә яшәгән иде.

Инде менә бу юлы Йокохама урамында очрашып, танышып дуслашкан әфәнденең дә югарыда әйтеп кителгән белгечләрнең берсе булуын сүзләреннән

аңладым. Япон телен белмәвем сәбәпле, бу кеше миңа файдалы булыр, дип уйлап куйдым. Ул көнне бер сәгатьләп бергә йөрдек. Шул арада да мин әлеге кешедән бик күп нәрсә сорашып белдем.

ЯПОНИЯДӘ СУКЫРЛАР

Язганнарымны укучылар барысы да, мөгаен, бик аптырап: «Бу кеше Япониягә сәяхәт иткән, иң башта рикшалар, аннары соң сукырлар турында язуының максаты ни икән?» – диячәк. Шул сәбәпле, моңа бераз ачыклык кертүне кирәк дип таптым. Япония турында да, башка мәмләкәтләр турында да фәнни мәгълүматлар бирүне максат итеп куймадым. Бары тик сәяхәт иткәндә күргән һәм игътибар иткән нәрсәләрем генә язачакмын. Әлбәттә, язмаларым күргән нәрсәләрем белән бәйле булачагы ачык аңлашыладыр. Күзәтүләремне һич кенә дә бизәкләп тезмәячәкмен, табигый хәлендә бирәчәкмен. Шуңа күрә дә алда рикшалар турында аз гына яздым. Инде менә хәзер сукырлар турында язачакмын.

Әлеге яңа танышкан белгеч белән урамнарда йөргәндә, безгә бөтен җирдә, бөтен урамнарда курайга охшаган уен коралы тотып, шуңа өреп көй чыгарган кешеләр очрады. Бу минем игътибарымны бик нык җәлеп итте, чөнки көй дә түгел, кызганыч дип әйтерлек бер аваз чыга иде ул «курайлардан». Бераздан шул ук моңсу көйгә җыр кебек бернәрсә көйләгән кешегә очрыйсың. Икесенең дә авазлары гаять моңсу, берсе икенчесенә бик охшаш. Аермасы бары шунда: берсе үз авызы белән көйли, икенчесе бу көйне курай кебек нәрсәгә өреп чыгара. Әлеге кешеләрнең киемнәре дә бик охшаш.

Бик кызыксынганга, мин болар турында әлеге белгеч юлдашыма сорау бирдем:

– Бу кешеләр кем, ник бу кадәр кызганыч дип әйтерлек моңсу авазлар чыгаралар?

– Болар – сукырлар, барганда арбалар бәреп китмәсен, дип, үзләрен шул рәвешле белдерәләр.

– Болар ник бу кадәр күп? Болай, караңгы төшкәч, кая баралар? Мин бүген көне буе шәһәрдә йөрдем, ник берсен очратыйм?! Сукыр кеше дә күрмәдем. Хәзер алар бик күп.

Белгеч юлдашым өстәп берни әйтә алмады һәм минем бу хактагы мәгълүматым ярым-ярты калды. Бераздан юлдашым белән саубуллашып аерылдык. Кунак йортына кайттым. Бераз вакыт үткәрим, дип, балконга чыгып утырдым. Аннан да ишетеп утырам: шәһәрнең бөтен ягыннан теге сукырларныкы дигән аваз ишетелә. Күп, бик күп. Игътибар итмәс җиреңнән игътибар итәрсең. Кызыксынуым инде чиктән ашты: йорт хуҗасын чакырдым, яныма утырттым. Башта бу авазларга игътибар иттердем, аннары:

– Бу нәрсә? – дип сорадым.

– Эммаа, эм-маа, – дип җавап бирде.

Тагын сорадым, тагын шул ук җавап. Шунда ук кулыма «Японча-русча сүзлек» алдым, карадым. Иероглифын табып, йорт хуҗасына күрсәттем: «Әйе, әйе, шул», – диде. Биредә бу «эммаа» сүзе «массаж» дип тәрҗемә ителгән иде. Менә бит, бу «эммаа» белән сукыр[3] арасында бернинди бәйләнеш тә юк икән. Аптыравымның чиге-чамасы юк иде. Үзем көләм, үзем уйланам. Йорт хуҗасы – бик игътибарлы, бик яхшы кеше – аптырап утырганымны сизде. Урамнан үтеп барган теге «сукыр»ларның берсен чакырды, кунакханә хезмәткәренә нидер әйтте. Биш минут та үтмәгәндер, килеп: «Рәхим итегез, сезгә «эммаа»ны күрсәтим», – диде. Киттек. Хуҗаның бүлмәсендә бер карават кебек нәрсә куелган һәм анда бер «сукыр» кыз утырып тора. Йорт хуҗасы барып караватка сузылып ятты. Бу кыз аңа массаж

[3] Габдерәшит Ибраһимов китабында «сукыр» мәгънәсендә госманлы телендә киң кулланылган гарәпчә а'ма сүзен кулланган. Сүзләрнең бу тышкы охшашлыгы да кызыклы булып тоелгандыр, мөгаен (тәрҗ. иск.).

ясый башлады. Йорт хуҗасы: «Менә «эммаа»ның кем икәнен аңладыгызмы инде?» – диде.

Шулай итеп, мәсьәлә чишелде. Һич кенә дә белгеч рус офицеры аңлатканча түгел икән бит. Кызганычка якын моңсу авазлар чыгара торган ул кешеләр сукыр түгел, ә массаж осталары икән. Японнарның гадәте: кич авышып, йокларга ятарга вакыт җиткәч, массаж ясаталар икән. Шуңа күрә бу «эммаа»лар, кич җитүгә, урамнарга чыгалар, үзләренең массаж остасы икәнлекләрен белдерер өчен, ирләр «курай» өреп, хатын-кыз исә авызы белән теге көйне көйлиләр икән. Массаж ясатырга теләге булган кеше аларны чакырып ала икән. Минем таныш рус белгечем аларны сукыр дип белә, ә көй көйләп йөрүләрен, акча теләнеп йөриләр, дип аңлый икән. Әле бу гына да түгел.

Русларда белгечләр һәм шәркыятьчеләр арасында моның кебекләр аз түгел. Бервакыт, моннан егерме еллап элек, Петербургта цензура ислам китапларына гаять көчле басым ясый башлаган иде. Хәтта Кәламуллаһны[4] да цензор тикшерүеннән үткәрделәр. Шик тудырган сүзләренең берсе – *кяфир/куфр/куффар* сүзләре булды. Ягъни мөселманнар кяферләргә ап-ачык дошман, бу сүзләр аларны кимсетү, хурлау өчен кулланыла, имеш. Шул сәбәпле, *куфр* сүзен бөтенләе белән сызып атачаклар, имеш – ахмаклык белән җаһиллекнең чиге-чамасы юк. Берара «Кәлам-ы Кадим»нән[5] «*Кул йа әййүбел-кяфирун сурәсе*»н чыгарып ташларга маташканнар иде. Менә шул елларда әлеге белгечләрнең иң бөеге, иң мәшһүр профессор цензор булып тора иде. Бу кеше берара әлеге сүзгә шулкадәр бәйләнде: *кәф-фе-ре* хәрефләреннән барлыкка килгән никадәр сүз булса, барысына да мәлгунь кулын тидерде. Хәтта фикъһ китапларында *кәфарәт* сүзен һәм тасауф китапларындагы[6] *фикер* сүзен дә тынычлыкта калдырмады. Күрәчәге фетнәләр белән тулы атаклы вакыйгадан булды.

Мондый белгечләр, әйе, юк түгел, ләкин төп гаеп белгечләрдә түгел, белгечнең кем икәнен белмәгән хөкүмәтнең сукырлыгында яки кешеләрнең вөҗдансызлыгында. Бу вөҗдансыз кешеләр, хөкүмәтнең җаһиллегеннән файдаланып, үзләрен белгеч итеп күрсәтәләр, форсат чыгуга, эш күрсәтә башлыйлар. Үзләре намуссыз инде, нәтиҗәдә, хөкүмәтне дә намуссызга чыгаралар.

Хөрмәтле укучыларым, гафу итәрсез, бераз читкә киттем.

Мин – Йокохамада, иртә-кич гел шәһәрдә йөрим, аркылыга-буйга йөреп чыктым. Әгәр гадәттән тыш арулыгы булмаса, Йокохама турында: «Безнең шәрык шәһәрләренең берсе», – дияр идем. Урамнарның тарлыгы, өйләрнең гадилеге, халыкның әдәбе һәм әхлагы шәрык шәһәрләрен хәтерләтә. Тик арулык, чисталык – искиткеч, чүп түгел, тузан да күрә алмассың. Иртәнге намаздан соң йөрергә чыгам. Шул вакыт хатын-кызларның өйләренең – эчендәге түгел – тышындагы тузанны сөрткәннәрен, кайчакларда хәтта юганнарын күрә идем. Бик гаҗәпләнә идем: хатыннарның аркаларына кечкенә балалары бәйләнгән, күп вакыт бала йоклаган була. Япониядә баласыз хатын бик сирәк очрый. Балалар гел хатыннарның аркаларына бәйләнгән була, шунда ук йоклыйлар да, аналарының эшләренә дә комачауламыйлар. Иң дәрәҗәле гаиләләрдә дә бу гадәт сакланган.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[4] Коръән-е Кәрим (тәрж. иск.).
[5] Коръән-е Кәрим китабы (тәрж. иск).
[6] Фикъһ китабы – Ислам кануннары китабы, тасауф китабы – суфыйчылык белән бәйле китаплар (тәрҗ. иск.).

ГАБДУЛЛА БУБИ ҺӘМ АНЫҢ «ИЖТИҺАД ЗАМАНЫ ҮТТЕМЕ, ЮКМЫ?» КИТАБЫ

Айдар Гайнетдинов

Габдулла Буби (Габдулла Габделгаллям улы Нигъмәтуллин) – мәшһүр дин галиме, җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог. Ул 1871 елның 9 ноябрендә хәзерге Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Габдулла төпле белемне әтисенең мәдрәсәсендә алган. 1895 елда Иж-Бубый мәчетенең имамы итеп сайланган. 1902 елда шул авылда ир һәм кыз балалар өчен аерым абруйлы мәктәп-мәдрәсә оештырган. Габдулла Буби шулай ук зур тырышлык куеп, кызлар һәм ир-егетләр өчен ике еллык рус-татар мәктәпләре ачкан. Ул Төркиягә, Гарәбстанга сәяхәт кылган, белемнәрен камилләштергән.

Габдулла Буби 1904-1906 елларда, «Хакыйкать, яхуд тугрылык» исемле очерклар язып, тагын да ныграк танылган. Кадимчеләрнең яла ягуы аркасында, 1911 елда, панисламизмда һәм хөкүмәткә каршы булуда гаепләнеп, төрмәгә ябылган, шәкертләре куып таратылган.

Габдулла Буби шуннан соң 1913 елда гаиләсе белән Кытайның Голҗа шәһәренә киткән, анда татар мәдрәсәсе оештырган. Февраль инкыйлабыннан соң Русиягә кайткач, Троицк шәһәрендә кызлар мәдрәсәсендә укыткан. 1918 елның җәендә исә туган авылындагы мәктәпне торгызган. Г.Буби 1922 елның 7 февралендә туган авылы Иж-Бубыйда вафат булган. Шундагы зиратта җирләнеп, газиз анасы Бәдрелбанат белән Габдулла Бубиның икесенә бер кабер ташы куелган.

Г.Буби байтак кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган: «Мөкаләмәи гарәбия», «Фәраиз», «Логия яхуд мантыйк фәне», «Тәгаддөде зәүҗати хифзы сыйххәти тәтъбикъ», «Мохтасар нәхү гарәби», «Тәзәүвеҗдә сәгадәт», «Тәрәкъкые фөнун вә мәгариф динсезлеге мөҗибме», «Хакыйкать яхуд тугрылык» (8 кисәктән торган), «Татарча хөтбә уку дөресме?», «Гыйльме хәл», «Сарфы гарәби» һ.б. Ләкин аның «За-

мане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» («Иҗтиһад заманы үттеме, юкмы?») дигән китабы башкаларыннан аерылып тора, чөнки анда, ул заманда гына түгел, хәтта хәзерге заманда да бик актуаль булган проблемалар күтәрелгән. Г.Бубиның әлеге бибәһа хезмәте 1909 елда басылып чыкканнан соң, бик күпләрнең күзләре ачылуына һәм йөрәкләре фикер коллыгыннан азат ителүенә сәбәпче булган. Бу китапта, беренчеләрдән булып, күренекле татар галимнәре Г.Курсави, Ш.Мәрҗани күтәреп чыккан тәкълид һәм иҗтиһад мәсьәләләре энәсеннән җебенә кадәр җентекләп аңлатылган, халыкка хаклык, туры юл күрсәтелгән.

Кайбер тарихчылар «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәтен Г.Буби үзе язмаган, фәкать Ибне Каййим атлы гарәп галименең «Игълям әл-мөвәккыйгыйн» [«Имза куючыларга белдерү»] исемле китабын татарчага гына тәрҗемә иткән, дип әйтәләр. Бу сүзләре белән алар әлеге китап белән тулысынча танышып чыкмаганлыкларын, игътибар белән укымаганлыкларын күрсәтәләр. Чынлыкта исә, әлеге хезмәтнең өчтән бере – Г.Бубиның үз сүзләре, үз иҗат җимеше. 69 битле китапның 23 нче битендә ул болай язган: *«Шул ук вакытта, бу тарихтан бик күп соң, ягъни һиҗрәттән 751 елда вафат булган Ибне Каййим, шәригать дәвам ителгән кебек, иҗтиһадның дәвам ителүен сөйләгән һәм тик бу турыда «Игълям әл-мөвәккыйгыйн» исемле бер китап язган. Минә минем бу дәрәҗә-максатым шул китапны тәрҗемә итеп, милләт улларыма күрсәтү һәм иҗтиһад бетте, дигән заманнан соңгы галимнәр һәм бөек адәмнәр ни сөйләгәннәр – шуны мәйданга кую. Хәтта иҗтиһад заманы бетмәде дигән сүз яңа сүз түгел, бәлки иске сүз икәнлек билгеле булсын! Минә минем максатым – бу. Әгәр тәкълиднең ислам һәм мөселманнар башына китергән бәлаләре минем йөрәгемне бу кадәр яндырып куырмаса, мин туп-туры бу китапның тәрҗемәсенә керешер һәм төрле китаплардан хәтеремдә калган бу озын кереш өлешне язып маташмас идем. Минә шул хәсрәтләр, минә шул ачы хакыйкатьләр минем каләмемне бу сүзләрне язарга мәҗбүр итте. Инде максатка килим дә Ибне Каййимнең сүзләрен тәрҗемә итүгә тотыныйм».* Димәк, хезмәтнең 23 битендә Г.Бубиның үз фикерләре, уйланулары урын алган, 23 биттән алып 62 нче биткә хәтле өлешендә Ибне Каййимнең «Игълям әл-мөвәккыйгыйн» әсәренең кыскача тәрҗемәсе бирелгән. 62 нче биттән 69 нчы биткә кадәр тагын Г.Буби сүзләре һәм Сәед Мөхәммәд Рашиднең «Әл-мәнар»да басылган «Реформатор белән мөкаллиднең бәхәсе» исемле китабының кыскача тәрҗемәсе китерелгән. Шулай итеп, «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы дәгелме?» хезмәтен Г.Бубиныкы итеп санарга нигез бар, Ибне Каййим китабыннан өзекләрне ул фәкать үзенең фикерен куәтләү өчен тәрҗемә иткәнлеге аның бу сүзләреннән аңлашыла: *«Әгәр: «Иҗтиһад заманы үтмәде һәм билгеле бер имамның сүзенә тәкълид тиешле түгел», – дип әйтү сез [әйткән] кебек, көферлек һәм адашу булса, бездән элек кяфер, бездән элек азгын Ибне Каййим һәм дүрт имам үзләре булырга тиешле иде, азрак инсафлык кылыгыз!»*

Һәр кеше «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?» хезмәте белән үзлегеннән танышып чыга алмый. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, ул гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән шактый аерыла торган рәвештә. Шуңа күрә аны кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен, барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып эшләргә булдык, ягъни мөмкин булганча хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Гарәп телендәге кайбер җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде, аңлашылмаган сүзләргә яки терминнарга астөшермәләрдә аңлатма бирелде.

Безнең мирас №7 июль 2019

ЗАМАНЕ ИЖТИҺАД МӨНКАРЫЙЗМЫ, ДӘГЕЛМЕ?

Габдулла Буби

Кешеләрнең акыллары көннән-көн прогресс тапкан һәм бу прогрессның әсәрләре дә иң надан һәм иң ахмак адәмнәрнең дә күзләрен камаштырыр дәрәҗәдә күренеп торган бер заманда бу сорауны бирү һәм: *«Коръәнне аңлау фәкать элекке кешеләргә махсус, алар беттеләр, Кыямәт заманына кадәр [Аллаһ] мондый адәмнәрне яңадан тудырмас»,* – дип әйтү никадәр түбәнлек булса, аңа җавап бирү максаты белән алтыннан кыйммәтле гомерне әрәм итү дә, хакыйкатьтә, шулкадәр ахмаклык. Ләкин эшнең ни вакытта хакыйкать көенчә торганы бар? Әгәр хакыйкать төрле хыяллар арасына кереп югалмаса, гыйлем исеменнән бу кадәр фикерләр язылмас һәм без дә бу китап карауны мәҗбүри күрмәс идек. Асылы акыл белән фикердән гыйбарәт булган һәм һәрбер хөкемендә акыл белән фикергә мөрәҗәгать иткән исламны ижтиһад[1] хөрриятеннән тәкълид[2] боендырыгына (камытына. – ***А.Г.***) атарлар һәм Китап [Коръән] белән Сөннәт[3] бөтенләй җимерелеп, болар урынына, фәлән-фәләннең сүзе торыр, дип кемнең хәтеренә (башына. – ***А.Г.***) килер? Әгәр эш хәтергә (башка. – ***А.Г.***) килер дәрәҗәсендә генә калса, ул вакытта бер дә кайгырмас [идек], мөселманнар башына бу бәлаләр дә килмәс [иде], сабыйлар аталарының хәтта аракы эчүгә кадәр һәрбер кабахәт эшләрен күркәм санаганнары кебек, безнең дә соңгыларыбыз элекке [кешеләрнең] максат һәм уйларын бер дә аңламыйча, һәрбер эшләгәннәрен, хәтта һәлакәткә китерә торган хөкемнәрен дә күркәм санап, тәкълид [кылырга] һәм ияреpгә тырышмаслар иде. Ләкин, бик зур кызганычка каршы, эш ул дәрәҗәдә генә калмаган. Бәлки мөкаллидлек[4] бәласе дәһшәтле сортта мәйданга чыккан, ислам бинасын җимергән, изге шәригатьне нигезеннән чыгарган һәм бу мөкаллидләрнең[5] золым камчылары астында ислам нуры бөтенләй сүнүгә якынлашкан. Соңгы фәкыйһләрнең[6], Коръәндә юк (булмаган. – ***А.Г.***) хәез-нифас[7] хөкемнәренә караган йөзләрчә сәхифә язган хәлдә, Коръәннең эче тулы кирәкле хөкемнәргә карамауларына сәбәп тә менә бу тәкълид. Болар фикъһ[8] хөкемнәренә сарыф иткән заманнарының (вакытларының. – ***А.Г.***) уннан берен Коръән Кәримнең бик күп җирдә әмер иткән кирәкле хөкемнәрен карауга сарыф итсәләр, бәлки мөселманнар бу кадәр наданлык һәм ахмаклыкка төшмәсләр иде. Әгәр болар, [һиҗри белән] беренче гасыр мөҗтәһидләре[9] кебек, фәкать хаклыкка ирешүне таләп итсәләр (эзләсәләр. – ***А.Г.***), билгеле [булган] бу адашуда һәм көферлектә гаепләүләр, нәфрәт-ләгънәтләрнең һичберсе булмас иде. Аллаһның рәхмәтен шайтан гына кызгана. Сезгә Аллаһның җәннәте тар булган кебек тоела, мине, кыйбла әһеленнән булган кардәшегезне, тик сезгә яисә элекке [замандагы] бер кешегә бер фикердә каршы булган өчен, адашуда һәм көферлектә гаепләргә

---

[1] Ижтиһад – нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән хөкем һәм нәтиҗә чыгару.
[2] Тәкълид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча ияру.
[3] Сөннәт – Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең өйрәтмәләре, гамәлләре һәм сүзләре.
[4] Мөкаллидлек – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча ияру.
[5] Мөкаллид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярүче.
[6] Фәкыйһ – ислам хокукы һәм шәригать мәсьәләләре белгече.
[7] Хәез-нифас – хатын-кыз гаурәтеннән килә торган кан төрләре.
[8] Фикъһ (фикых) – ислам хокукы.
[9] Мөҗтәһид – ислам чыганакларыннан үз тырышлыгы белән нәтиҗәләр чыгаручы галим.

Хөснефатыйма һәм Габдулла Бубилар Голҗа татар кызлар мәктәбенең беренче чыгарылыш кызлары белән. Голҗа (Кытай), 1917. (Фото А.Мәхмүтованың «Лишь тебе, народ, служенье!» (2003) исемле китабыннан)

тотынасыз? Хөрмәтле сәхабәләр һәм бөек имамнар[10] иҗтиһадта бер-берсе белән каршы фикердә булырлар иде, ләкин һичберсе башка берәүне адашуда һәм көферлектә гаепләмәс, аны дошман санамас иде. Шуның өчен Әбү Хәнифә белән Шәфигый арасындагы фикер каршылыкларына караганда, Әбү Хәнифә белән ике шәкерте – Әбү Йосыф һәм Мөхәммәд – арасындагы каршылыклар күбрәк [булган], дигәннәр.

Менә боларның каршылыклары фикер хөррияте һәм сүз хөррияте мәгънәсендә булганлыктан, Мөхәммәд (с.г.в. – Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) өммәтенә рәхмәт иде. Әмма соңра бер заман килде, Аллаһ Тәгаләнең Коръән Кәримдә яһүд һәм нәсараларны гаепләгән урынында: *«Алар, Аллаһны ташлап, үзләренең галимнәрен һәм заһидләрен Раббы итеп алдылар»* [Коръән, 9:31] дигән сүзенә карышып, шәригать дәлилләрен куеп, элекке кешеләрнең сүзенә дәлилсез тәкълид кылына башлануы, һәрбер фирка бер имамны ияртүче [итеп] тотып, мәзһәптә[11] фанатизм куәтләнде. Һәрбер төркем үз мәзһәбенә каршы фикердә булган башка төркемгә дошманлык кыла

---

[10] Бу китапта «имам» сүзе «мулла» мәгънәсендә кулланылмый, элекке замандагы мәшһүр дини галимнәр күздә тотыла.

[11] Мәзһәп – мөселман хокук системасына нигезләнгән дини юнәлеш (агым).

башлады. Һичбер төркем башкасының дәлилен белмәс һәм хаклыкка ирешүне теләмәс бер хәлгә төште. Һәрбер фирка башкасын сүгеп һәм хур итеп, үз фикердәшләрен күбәйтү исәбенә керде, бер-береңне кыралмау күбәйде, ызгыш-талаш артты. Һичберсенең максаты хаклыкка ирешү һәм ялганнан котылу түгел, бәлки каршы фикердә булган көндәшне җиңү һәм кеше арасында галим исемен чыгару иде. Димәк, фикердәге бу каршылыклар ислам милләтенә кая рәхмәт, киресенчә, ләгънәт булып китте. Гүя Аллаһ Тәгаләнең: *«Кешеләрнең ислам динен үзгәртеп бозулары Аллаһтан аларга китап иңмәгәннән һәм рәсүл килмәгәннән түгел, бәлки китап иңдерелеп, рәсүл күндерелеп, ислам дине тулысынча ачык итеп аңлатылганнан соң инсафсыз галимнәр бер-берсенә хөседләнеп, дошманлашып, Аллаһ хөкемнәренә хилафлык кылдылар, ислам динен бозып бетерделәр»* [Коръән, 3:19], – дигән сүзе болар хакында иңде. Аллаһ Тәгалә һәрбер урында акылга мөрәҗәгать иткәнлектән, исламча мөстәкыйль фикер һәм тәклид белән ислам капма-каршы куелган иде. Әгәр эш шул хәленчә барса, акыллар куәтләнер, хаклык ялганнан аерылыр һәм тәкълидтән дә качу булыр иде. Ләкин, кызганыч ки, эш шул хәленчә бармады. Коръән-Кәрим: *«Китап әһелләре*[12] *китапларын үзгәрттеләр, куйдылар һәм, дин исемендәге кешеләрнең сүзләренә сукырларча тәкълид кылып, хәрәмны – хәләл, хәләлне хәрәм иттеләр»*, – дип әйтә торып, безнең дә соңгы дин исемендә булган кешеләребез үз шәехләренең сүзләренә сукырларча тәкълид кылдылар. Боларның: «*Имамнар сүзләренә тәкълид вәҗиб һәм аларның фәтваларын шәригать текстларына тәкъдим итү тиешле»*, – дигән сүзләре белән гамәл кылдылар. Шул ук вакытта, үзләре башка тарафтан имамнар сүзләренә каршы булса да, бу шәехләрнең сүзләренә тәкълид кылалар һәм әйтәләр ки: *«Болар Аллаһ сүзен һәм имамнар сүзләрен безгә караганда белүчерәк, шуның өчен болар сүзенең Аллаһ сүзе һәм имамнар сүзләренә каршы төсле күренүе безнең үз акылларыбызның җитешсезлегеннән»*. Менә шулай һәрбер фирканең иярүе: фәкать шәехләре дөрес күргән хөкемнәрдә генә имамнарына тәкълид кылдылар, иҗмаг[13] буенча ялган булган мөкаллидкә тәкълидне ихтыяр кылдылар һәм Аллаһ Тәгалә: *«Аллаһ сезгә тарлыкны теләми* [Коръән, 5:6]. *Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, авырлыкны теләми»* [Коръән, 2:185], – дип әйтә торып, ислам шәригатен теләгән кадәр тарайттылар, иҗтиһад хакында бик күп мөшкел мәсьәлә турында Аллаһ китабы һәм Рәсүл сөннәтендә табылачак киң ишекләрне караңгы тәкълид пәрдәсе белән капладылар. Болар һичбер акыл йөртмәгәнлектән һәм һәрбер дәлилне наданлыклары белән кабул иткәнлектән, алар белән сөйләшергә дә мөмкин түгел, бәлки аларны тотып, туп-туры сырхауханәгә җибәрергә [кирәк]. Чөнки болардан мөселманнар башына килгән зарар, файдаларына караганда, берничә мәртәбә күбрәк. Фәкать боларның залим солтан һәм әмирләргә файдалары тигән.

Чөнки залимнәр һәрвакыт наданлыктан файдаланырлар һәм болганчык суда балык тотарга теләрләр. Залимнәрнең дөньяда иң курыккан нәрсәләре – гыйлем һәм мәгърифәт. Тәкълид кебек гыйлем һәм мәгърифәтне юк иткән башка һичбер нәрсә юк. Халыкны тунар һәм теләгән золымны йөртү өчен иң беренче юл – иҗтиһад һәм хөррият фикерне бетерү. Шуның өчен дә залимнәр: *«Иҗтиһад заманы үтте»*, – дигән фәтваны үз заманнарындагы галимнәрдән йә куркытып, йә сатып алганнар.

Бүген бу тәкълид бәласе шулкадәр гомумиләшкән һәм шулкадәр тамыр җәйгәндер ки, әгәр бер адәм Коръән белән Сөннәткә кайтуга чакырдымы, аннан нәфрәтләнәләр, качалар һәм төрле көферлекләрдә гаеплиләр. Шул ук вакытта, Аллаһ Тәгалә: *«Сез: «Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягькуб һәм башка пәйгамбәрләр яһүд динендә яки насара*

[12] Китап әһелләре – христианнар һәм яһүдиләр.
[13] Иҗмаг – ислам галимнәренең бердәм фикерләре һәм карашлары.

динендә иделәр», – дип әйтерсезмени?» – дип аңлаткан ки, хөрмәтле пәйгамбәрләрнең (г.с.) һичберсе тәкълид боендырыгына кермәгәннәр, бәлки тик дәлилдән аңлашылган хаклыкка ияргәннәр. Тәкълид, ияру һәм бер кешедән ишеткән яисә бер китапта күргән нәрсәләрне фотограф кебек сөйләп тору – һәммәсе пәйгамбәрләрдән (г.с.) соң барлыкка килгән бидгатьләр[14]. Менә әфәндебез [Мөхәммәд] (с.г.в.) шул бидгатьләрне бетереп, дәлилләргә кайтару өчен торгызылган һәм: *«Шул вакытта ияртүчеләр үзләре ияргән кешеләрдән бизәрләр һәм ерак булырлар»* [Коръән: 2:166], – дип дәлилсез ияручеләр гаепләнәләр һәм хурланалар. Аллаһ Тәгалә: *«Шайтан өндәгән батыл юлларга иярмәгез. Дөреслектә, ул шайтан – сезнең өчен ачык булган дошман. Шайтан сезне явыз, гөнаһ эш белән, шәригатьтә һәм акыл буенча кабахәт булган эшне кылырга өндәр. Шулай ук шайтан сезгә Аллаһ Тәгалә хозурына сез белмәгән нәрсәгезне, ягъни потларга табыну, хәләл ризыкларны һәм киемнәрне хәрәм дип әйтергә боерыр»* [Коръән: 2:168-169], – дип, дәлилсез, гыйлемсез сөйләгән адәмнәрне, ягъни мөкаллидләрне шайтанга ияручеләр дип гаепли торып, ахыргы буыннарның Коръән һәм хәдистән баш тартулары һәм, бер мәзһәпкә керделәрме, каршыларына тау кебек дәлилләр китерелсә дә, фикерләрендә һаман нык торулары – бик каты гаҗәпләндерә торган хәл. Болар, тулы ахмаклыкларыннан, тәкълид белән динне саклыйбыз, дип уйлыйлар. Шул ук вакытта, әгәр тәкълид белән һәм Аллаһ белән кол арасында арадашчы ясап, аять вә хәдисләрдән баш тартулары һәм колларның йөрәкләрен ул Рәхимлеләрнең рәхимлесеннән (Аллаһтан. – ***А.Г.***) суыту белән динне саклау хасил булса, Аллаһ Тәгалә: *«Һәркайчан аларга: «Аллаһы Тәгалә иңдергән нәрсәгә иярегез»*, – дип әйтелсә, мөшрикләр әйтерләр: *«Аллаһы Тәгалә иңдергән нәрсәгә иярмибез, бәлки аталарыбыз нәрсәгә гыйбадәт кылдылар, без дә шул нәрсәләргә гыйбадәт кылабыз»* [Коръән: 2:170], – дип, тәкълиднең ялганын һәм тәкълид юлының бозыклыгын сөйләмәс һәм моннан соң*: «Аталары дин эшеннән бернәрсәне белмәсәләр дә, туры юлда булмасалар да, аларга ияререләрме?»* [Коръән: 2:170] – дигән сүзләрне аңламаган һәм дәлилләргә карамаган адәмнәрне хайван урынына иңдермәс иде. Әгәр мөкаллидләрнең аңлый торган йөрәкләре булса, менә бу аять берүзе дә тәкълидтән, иске гадәтләрне изге санаудан нәфрәтләндерүдә һәм Аллаһ китабы белән Рәсүл сөннәтеннән баш тартуның хәрәм икәнлеген күрсәтү дә җитә.

Бу аять аңлатадыр ки, боларның тәкълид кылган затлары, хаклыкка ирешү өчен һичбер дәлилгә карамаганлыктан, һәммәсе хатада. Хаклыкны белү өчен дәлилгә карый торган кешенең, бервакыт хатага төшсә дә, икенче вакыт тагын фикерләп, дөреслеккә кайту ихтималы бик якын. Шуның өчен акыллы адәмнең һәрберсе, ялган гозерләр күрсәтеп, Аллаһ иңдергән нәрсәләрне ташлап, башка бер кешегә, акылы никадәр камил булса да, тәкълидне, сукырларча ияруне дөрес күрмәс һәм бик ачык белер ки, кеше никадәр акыллы һәм никадәр үз-үзен тотышы яхшы булса да, бервакыт фикерендә хата кылмыйча калмас. Шуның өчен [нәрсә дә булса] сөйләүчегә рухсыз тәкълид кылырга түгел, бәлки дәлилгә карап сүзенә иярергә тиешле.

Дәвамы бар

Текстны басмага филология фәннәре кандидаты
Айдар Гайнетдинов *әзерләде.* ■

[14] Бидгать – догмат һәм гыйбадәт мәсьәләләрендә Коръән һәм пәйгамбәр (с.г.в.) өйрәтүләренә туры килмәгән фикерләр, гамәлләр, йолалар һәм сүзләр.

«ТУГАН ТЕЛ»ГӘ ҺӘЙКӘЛ КИРӘК

Зиннур Мансуров,
Татарстанның халык шагыйре

Китап сөючеләр белән очрашуларның берсендә миңа мондыйрак сорау биргәннәр иде: «Күп гасырлы татар әдәбиятында телдән төшмәүче иң күренекле әсәрне атасагызчы?» Беркадәр югалып калу халәтендә ике-өч исемне хәтергә китердем. Әүвәл «Кыйссаи Йосыф» аң-зиһендә чагылып узды. Бүтән язма җәүһәрләрне берәм-берәм искә алдым. Әмма әлеге көтелмәгән сорауны тәгаен җавапларга җөрьәт итмәдем. Кичә тәмамлангач кына кинәт уйга килде – халыкта киң танылганы «Туган тел» ләбаса! Төрле даирәләрдә сорашу үткәрсәк тә, без шундый нәтиҗә чыгарыр идек. Бу әдәби әсәрне күпләр яттан белә. Һичшиксез, ил-көн аны даим кабатлап тора, заманча атаманы кулланып әйткәндә, ул бик югары рейтингка ия.

Чыннан да, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның «Туган тел»е инде бер гасырдан артык халкыбызга хезмәт күрсәтә. Мондый мәхәббәтне казану табигый эзлеклелектә бара. Ошбу шигырь «Балалар күңеле» җыентыгында (1909 ел) беренче тапкыр гавам хөкеменә тапшырыла. «Туган тел» кыска гына вакытта мәктәп-мәдрәсә шәкертләренең яраткан әсәренә әверелә. Аны уку елы башлану һәм тәмамлану тантаналарында да, төрле бәйрәмнәрдә дә хор белән уку-көйләү гадәткә керә. Шулай итеп, газиз ана телебезне хакыйкый данлау баскычына күтәреп язылган үзенчәлекле мәдхия төбәктән төбәккә, халыктан халыкка, илдән илгә, кыйтгадан кыйтгага таралыш ала.

Мәгълүм булганча, Габдулла Тукай 1911 елның апрелендә Әстерханга бара. Ул утырган «Тургенев» пароходы Саратов шәһәре пристанендә тукталыш ясый. Шулчак палубага Беренче мәхәллә кызлар мәктәбе мөгаллимәсе Мәүсүфә Яраева, аның артыннан кулларына чәчәк бәйләме тоткан укучылар төркеме күтәрелә. Аларга «Туган тел» инде күптән таныш – шигырь белән остазлары китаптан укып таныштырган. Истәлектә «китап» дип әйтелгәне, мөгаен, «Балалар күңеле» җыентыгы булгандыр. Ташка басылган әсәр шәһәрдән шәһәргә күчә. Габдулла Тукай Петербургка баргач та (1912 елның апреле) «Туган тел»не кызлар хоры башкара. Башкалада мондый чыгышлар соңрак та кабатлана. Мәсәлән, Петербург җәмгыяте хәйрия мәктәбе 1914 елның апрелендә шагыйрьнең вафаты җәһәтеннән искә алу мәрасиме үткәрә. «Туган тел»не сөйләгән хорга күпләр ихтыярсыз кушылып китә. Шигырьдәге мөкатдәс сүзләр аларның күңеленә уела.

Әле Габдулла Тукай үзе исән елларда ук бу шигырь Урта Себергә кадәр барып җитә. Ул чакта Иркутскидан 76 чакрым ераклыкта яманатлы каторга үзәк төрмәсе урнашкан була. Менә шушы Александровски авылында мәктәп тә эшләп килә. Биредә Мөбәрәкҗан Әмиров тоткыннарның балаларын укыта. Мәгариф һәм мәдәният эшлеклесе үзенең истәлегендә шагыйрьнең тезмә әсәрләрен ятлатуы хакында сөйли. «Туган тел», «Бәйрәм бүген» шикелле шигырьләре дәрестән соң хор белән җырлана иде, – дип искә ала ул. – Зиндан биналарыннан туктаусыз богау тавышлары ишетелеп торса, мәктәп эчендә Г.Тукайның «Туган тел», «Пар ат», «Мәхбүс» кебек әсәрләре яңгырый иде».

И төрки татар йөзенә
Нурлы ямь чәчкән Тукай;
Гади халыкка «Туган тел»
Хак юлын ачкан Тукай!

Кырым татар шагыйре Әмди Гәрәйбәйнең «Тукайга» дип исемләнгән әлеге ихлас багышлавында «Туган тел»нең башка төрки кавемнәр өчен дә кадерле булачагына ышаныч белдерелә. Шигъри фараз дөрескә чыга. Чын шигырьгә чик-киртәләр юк. Ике тапкыр Уфага сәфәр кылган шагыйрьнең язганын аерылгысыз бергәлектәге татар-башкорт галәме аеруча якын күрә. Бу уңайдан Башкортстанның күренекле драматургы Нәҗип Асанбаевның эчкерсезлек белән искәртүен кабатлап узу да җитә. Аның кагыйдәгә торырлык мондый сүзләре бар: «Үзенең йөрәгендә Габдулла Тукайга олы ихтирам тойгысы сакламаган, кайнар рәхмәтен белгертмәгән чын башкорт кешесе табылмас. Без дә, әлифбаның тәүге хәрефләре белән танышканда, шагыйрьнең «Туган тел»ен күңелгә беркеттек. Инде аны хәзер башка буын ятлый».

Аллаһ теләктәшлек кылып, шулай була күрсен! Телләребезнең кечтеки генә үзгәлеге безне аеры-чөере хәрәкәт итәргә этәрмәсен, киресенчә, телләребезнең биниһая зур уртаклыгы безне катлаулы дөньяда берләштереп яшәтсен.

Җиңел кул белән милләткә һәдия кылынган «Туган тел» шигыре инде ерак Төркестанга – кардәш халыклар күпләп гомер сөргән Урта һәм Үзәк Азия тарафларына канатланып оча. Биш меңле мәҗмуга, кулдан-кулга йөри-йөри, миллионнарга килеп ирешә. Әдәбият сөючеләр арасында таралып кына калмый, шул илгизәр «Туган тел» уку йортларының түренә уза. Атаклы үзбәк мәгърифәтчесе Габдулла Авлони әлеге шигырьне мәктәп дәреслегенә кертә. Шул рәвешле «Туган тел», танылу офыкларын киңәйтеп, төрки кавемнәрнең уку программаларында лаеклы урын ала. Үзбәкстанның халык шагыйре Гафур Голәм бик хаклы төстә билгеләп үткәнчә, «Инкыйлабка кадәрге Россиядә яшәгән халыклар, патша хөкүмәтенең аз санлы милләтләрне кол итүгә юнәлтелгән милли сәясәтенә каршы барып, бер-берсе белән якынлашырга, Тукайча әйткәндә, үзара «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» көн күрергә тырыша иде».

Казакъ халкы да аны үз шагыйре итеп таный. «Г.Тукай исемендәге мәктәп», «Г.Тукай уку өе»... Элеккерәк елларда казакъ-татар мәгърифәт учакларын шулай атап йөртү гадәткә кергән. Танылган казакъ шагыйре Җакан Сыздыков ошбу мәктәпләрнең берсендә белем алуын, «Туган тел»не хорга җыелып җырлауларын зур горурлык белән искә төшерә: «Асылташтай нурлы сүзләр тезгән, рухландыргыч зирәк остазым Тукайны мин һич онытмам».

Күренекле рус шагыйре, тәрҗемәче, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Семен Липкин узган гасырның илленче еллары ахырында казакъ әдәбияты классигы Мохтар Ауэзов белән очраша. Тәрҗеманлык хакында сөйләшеп китәләр. Әңгәмә барышында Габдулла Тукай әсәрләре, тәгаенрәк әйткәндә, «Туган тел» шигыре искә алына. Дәһри идеология куштаннарының даһи шагыйрь мирасына оятсызларча тыкшынуы – кысуларны хәтсез кичергән Мохтар Ауэзовны тәмам чыгырыннан чыгара. «Нишлисез, мин ул шигырьне бала чагымнан ук яттан беләм, – дип ачуын кабарта әдип, Семен Израилевичны гаепле санагандай. – Нигә соңгы ике юлны кисәсез?» Нинди шигъри сәтырларның күздә тотылуы хәзер инде һәркемгә дә мәгълүм. Аллаһ саваплы итсен, шуларны хәтергә төшереп үтик:

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Россия империясенең татарлар һәм башка төрки халыклар гомер сөргән якларында галәбәле «Туган тел» мәдәният тарихында моңарчы күрелмәгән киң танылуга ирешә. Ул, рәсми виза-рөхсәт алмыйча гына, чит илләргә дә үтеп керде. Дистәләрчә



телдә рухани аваздашлык тапкан ошбу әсәр берьюлы байтак мәмләкәттә хокуклы рәвештә яши башлады. Чыннан да, аны үз иткән илләр дөнья йөзендә аз түгел. Алар безгә яхшы мәгълүм: Австралия, АКШ, Болгария, Германия, Канада, Кытай, Польша, Румыния, Төркия, Финляндия, Япония... Әлеге дәүләтләрдә көн күрүче тугандаш халыклар Габдулла Тукайның берләштерү көчен тоймыйча калмый. Безнең кавем дәвамчылары туып-үскән күп кенә төбәкләрдә «Туган тел» җәмгыятьләре эшләп килүен дә беләбез. Төрле мәкам белән көйләп башкарылган атаклы шигырь көндәлек тормышта башка мөһим вазыйфалар да башкара. Шушы урында күренекле төрек шагыйре Мостафа Өнәрнең күпләр тарафыннан ихлас әйтелердәй сүзләре искә төшә. «Минем татар телен өйрәтүче хәлфәм, – дигән ул, – татар халкының кечкенә Апуштан бөек Тукайга әверелгән сөекле шагыйре Габдулла Тукай булды». Кардәш каләм әһелләренең уртак фикеренә Турсун Каһари драматик төсмер өсти: «Габдулла Тукай – Гоминьдан зинданнарында аның шигырьләрен татар телендә яттан сөйләгән хәтсез уйгыр шагыйрьләренең остазы».

Элгәрләр хак искәрткәнчә, ил яшәве – җыр белән. Әлеге мәкаль «Туган тел»нең илаһилык югарылыгындагы тарихи йөкләмәсен, аның халык тормышындагы әһәмиятен аеруча тулылыкта ачып бирә. Чынлыкта ул җәмгыятебез яшәешенә шулкадәр тирән кереп урнашты ки, безнең бүгенге рухи-мәдәни хәрәкәтне инде аннан башка күзаллап булмыйдыр. «Туган тел» җыры төрле концертларда да, әдәби-музыкаль кичәләрдә дә, тантаналы бәйрәмнәрдә дә, рәсми форумнарда да бердәм рәвештә башкарыла. Татарстан җыр һәм бию ансамбле аны бөтен СССРга, шулай ук күп кенә чит илләргә дә таратты... Санау озынга сузылырга мөмкин. Телебезгә хөрмәт белдерелгән чаралар болар белән генә чикләнми.

Үзен милләт баласы итеп исәпләгән һәркем «Туган тел»не күңелдән көйли белергә сәләтле. Гавамча әйткәндә, олысы да, кечесе дә. Мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшев тә аны малайлыктан ук кальбенә беркеткән. Кайта-кайта гаҗәпләнәсең, ул халык ихтыяры җирлегендә үзенчәлекле гимнга әверелде бит! Моның тәгаен шулай булуын дәлилли торган тәэсирләндергеч мисалны Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев хатирәсеннән дә китерергә мөмкин. Ул Бөтендөнья татарларының Казанда үткәрелгән (1992 ел) 1 нче оештыру конгрессын искә ала: «Шыгрым тулы зур залның аягүрә басып, сөенечле яшьләрен яшермичә: «И туган тел, и матур тел», – дип җырлавы хәзер дә күз алдымда саклана. Җир шары буйлап

электән сибелеп яшәгән милләтебезне Тукайның «Туган тел»е әнә шулай яңадан берләштереп куйды».

Ышанычлы төстә әйткәндә, шагыйрьнең шундый шаһ-әсәрне язар өчен бөтен яктан да әзерлеге булган. Һәм аңа ихтыяри теләге дә, әхлакый хакы да этәреш биргән. Нәкъ менә ул! «Туган тел»не бүтән авторның иҗат итүен инде күз алдына да китерәсе килми. Әйе, шулай расларга тиешбез, чөнки Габдулла Тукай яңа милли әдәбиятка, хәзерге татар теленә какшамас нигез салышкан.

«Белгәнебезчә, Тукайның «Мөхәммәдия» дәвере, ягъни борынгы китаплардагычарак югары стильдә гарәп, фарсы сүзләрен мул кулланып иҗат иткән чоры бар, – ди Нәкый Исәнбәт, аның тырышлыкларын танып. – Тукайга, бүгенге әдәби телнең нигезен салу өчен, элеккеге әдәби телне, аның традицияләрен ныклап өйрәнергә, иҗади үзләштерергә кирәк булган». Шушы юнәлештә иҗтиһад кылу күркәм нәтиҗәләргә алып килә. Җамал Вәлиди билгеләп үткәнчә, «Тукай татар теленә право, гражданство институты бирде... Бөтен милләткә татарча әдәби җирлектә сөйләшү дәртен кузгатты». Ә Сибгат Хәким, фикердәшләрен тыңлап утыргандай, үзенчә гомумиләштерү ясый: «Туган тел – Тукай теле, татар теле, татар әдәбиятының теле. Менә Тукай теле нинди киң мәгънәдә кулланыла бездә!»

Милләтнең яшәүчәнлеген ныгыту юлында шулай җан атып йөргән фидаи шагыйрь ничек инде «Туган тел» кебек гасырлар кичәрлек шигъри әманәт калдырмасын?!

Гадәттә, дөнья гизәргә насыйп кылынган җырның ике канаты да, ягъни шигыре дә, көе дә көчле булырга тиеш. «Туган тел» бу яктан да мөкәммәл, югыйсә аны миллионнар яттан башкармас иде. Җыр сүзләре белән шулай табигый аһәңлеккә кереп, мәгънәви тәңгәллеккә ирешкән көй ничек табылган соң? Бериш сәнгать белгечләре әлеге мәгълүм шигырьнең «Сәлим бабай» көенә җырлануын алга сөрә. Татар музыкаль фольклорын җыючы һәм өйрәнүче күренекле галим Мәхмүт Нигъмәтҗанов исә «Туган тел»нең икенче канатын халкыбыз кичергән фаҗигале язмыш сәхифәләренә китереп бәйли. Ул Георг Шюнеманның 1918 елда Лейпциг шәһәрендә чыккан «Казан татарларының көйләре» исемле хезмәтенә юлыга һәм анда Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында әсирлеккә эләккән милләттәшләребезгә багланышлы бер җырга игътибар итә. Немец галиме тарафыннан язып алынган 19 көй арасында күпләргә таныш яңгырашлы «Мәхбүс» дип аталганы да бар. Профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов раславынча, ул ноталары буенча нәкъ менә «Туган тел»гә, дөресрәге, аның хәзерге көенә тулысы белән туры килә. Димәк, кайтаваз – ерактан. Хикмәти Хода, «Туган тел»нең хәтта көе дә ачы горбәттә күпне кичерергә өлгергән.

Форсат чыккан чакта беркадәр ачыклап үтик. Беренче Бөтендөнья сугышы барышында байтак татарлар әсирлеккә эләккән. Мәхбүсләр башлыча Германиядә, мөселман лагерьларында тотылган. Билгеле инде, безнең милләттәшләр нинди генә шартларга куелмаган, аларның рухи асылы барыбер үтәли күренә. Күңел түгелмичә тормый. Тоткынлыкта татар җырлары, аерым тәэсирле шигырьләр, халык иҗаты әсәрләре, башка үрнәкләр яңгыраган. Иректән мәхрүм ителгәннәрнең җан асрау рәвешендә, әлбәттә, милли йолаларда анык чагылыш тапкан. Төпченүчән немец галимнәре исә боларның һәммәсен дә өйрәнгән. Игътибарга лаеклылары махсус тәлинкәләргә, балавыз цилиндрларга ыктыматлап яздырылган.

Шулай фараз итәргә мөмкин: Габдулла Тукай үзенең шигыренә әлеге көйне гүяки җыр-моңлы вөҗүде белән тартып китергән. Моның сәбәпләре тирәндә ята. Шагыйрь музыка сәнгатенә беркайчан да битараф булмаган, алай гына түгел, үзендә хәтта җырчылык сәләте барлыгын да таныган. «Мин кечкенәдән үк җырчы идем, – дип

искә ала ул тамак чарлаган шәкерт чагын. – Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый белми идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атнакичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде». Һәм аннары Габдулла Тукай җитдилек белән өстәп куя: «Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды».

Мәдрәсәдә үткәрелгән җыр-бию мәҗлесләрендә беренчелекне алган Габдулла, үзеннән-үзе аңлашылганча, теләсә кайда авыз эченнән нидер көйләргә яраткан. Иртә белән юыну бүлмәсендә дә ул кинәт кенә җырлап җибәргән. Чордашлары аның Җаектагы күңел ачу урыны – Хан урманчылыгында онытылып көй сузуын искәртә. Чаган елгасы буенча да шул җырлар кабатланып тора. «Тукай бераз милли көйләремезне сайрагач...» Сабакташы Ярулла Муради үзенең истәлегендә, әнә, хәтта «сайрау» сүзен кулланырга җөрьәтләнгән. Ә Габдулла Кариев мәдрәсәдә укыган чакта аның «һөнәрчел» булуы, хәтта рус шигырьләрен дә көйләп йөрүе турында искә ала. Кече атнакич уеннарында ул җырлаган да, зур маһирлык белән кубыз да тарткан. Коръәнне җентекләп үзләштергән Габдулла, Каһирә университетында белемен тирәнәйткән Камил Мотыйгыйның өенә йөреп, Мисыр мәкамен дә өйрәнгән.

Кемдәдер сорау туарга мөмкин: музыкага һәвәс Габдулла Тукай нинди көйләрне күбрәк яраткан? Замандашлары раслаганча, ул халык җырларыннан «Әй, дуслар, мал кайда?», «Ак бүрек», «Ашказар», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Мәдинәкәй», «Ончы Фәхри», «Сакмар суы», «Уел»ны, кыска көйләрдән «Аклы шәл», «Әминә гүзәлем», «Колаксыз Зариф», «Пороховой Фатыйх», «Порт-Артур», «Җомга»ны якын күргән. Аның әледән-әле көйләү гадәте гомере буена дәвам иткән. Поляк халкының бик популяр «Краковяк» биюе көен дә, «Турецкий марш»ны да күтәренке тавыш белән кабатларга күнеккән. Казан кунакханәләрендә яшәгән чакта, ятагында тезләрен кочаклап, иртә-кич үзалдына моңланып утырган. Шул арада үз рухына муафыйк шагыйрьләрнең кайсыбер назымнарын да төрлечә көйләп алган. Кем белә, Габдулла Тукай күңелендә «Туган тел» шигыренә канат биргән аһәңнәр дә яңгыраш тапкандыр, чөнки соңра әсирлек моң-зарларын үзенә сеңдерәчәк әлеге көй халыкка инде билгеле булган.

Истәлекләрдә басым ясап әйтелгәнчә, Габдулла Тукай халык җырларын йомшак-нәфис тавыш белән, үзенең вокаль мөмкинлекләреннән бик оста файдаланып башкарган. Шагыйрь җиренә җиткереп җырлауны башкалардан да таләп иткән. Мәсәлән, аның Казанда язучы һәм тәрҗемәче Солтан Рахманколый белән очрашкалап торуы, озын көйләрне сузып җибәрергә яраткан каләмдәшенә кайбер киңәшләр бирүе мәгълүм. «Җырлаган вакытта минем музыка хаталарымны табып төзәтә иде», – дип искә төшерә талымлы заттан сабак алган замандашы. Югыйсә Солтан Рахманколыйның тавышы шактый чиста булган, өстәвенә, ул мандолинада да үтә килештереп уйный белгән. Күр әле, шагыйрьнең эчке куәсенә тора-тора гаҗәпләнеп куясың.

Тагын бер хатирә. Композитор, дирижер, фольклорчы һәм педагог Антон Эйхенвальд 1907-1911 елларда Казан император университетында эшләп йөргән. Төгәлрәк әйткәндә, ул төрки телләр белгече, этнограф Николай Катанов белән бергә уку йортының эксперименталь фонетика кабинетында гыйльми эзләнүләр алып бара: музыкаль фольклор үрнәкләрен җыюда катнаша, халык җырларының метро-ритмик төзелешен өйрәнә, татар һәм башкорт көйләрен гармонияләштерә. Бервакыт язмыш юллары аны Габдулла Тукай белән очраштыра. Аннары алар арасында дустанә

мөнәсәбәт урнаша. Халык көйләрен күп тавышлы кимәлдә төзү тәҗрибәсе шагыйрь өчен бигрәк тә кызыклы булып тоела. Шундый ихласлык нигезендә хезмәттәшлек башланып китә.

«Ул профессиональ музыкант түгел иде. Ләкин халык җырларын көйләгәндә яки көйләрне үзе иҗат иткән чакта мин аңа гаҗәпләнә идем, – ди Антон Эйхенвальд, хәтер йомгагын сүтеп. – Озак вакытлар зур тырышлык белән эшләү һәм Тукайның барлык күрсәтмәләрен бик җентекләп анализлау соңында мин үземнең нинди хаталарым барлыгын аңладым... Музыка өлкәсендәге күпьеллык хезмәтләрем һәм Европа музыкаль техникасына нигезләнгән белемнәрем миңа Тукай биргәнне бирә алмаган иде». Һәм аннары истәлек авторы йомгак ясагандай әйтеп куя: «Әгәр Тукай музыканы ныклап өйрәнсә, аннан гүзәл бер композитор чыгар иде».

Әйе, кечкенәдән җыр-музыкага тартылган шагыйрь халык көйләрен җыю белән дә шөгыльләнгән, аларга аңлатмалар биреп, «Шәрык клубы»нда җәмәгатьчелек үтенече буенча әзерләнгән лекциясен укырга да өлгергән. Менә шундый каләм әһеле тарафыннан иҗат ителгән «Туган тел»нең халыклашып китүе, гомумән, аның дистәләрчә шигыренә ягымлы көйләр тәгаенләнү бик табигый рәвештә кабул кылына. Шулай шул, күңелгә салынган аһәң барыбер үзенекен эшли. Габдулланың Кырлайда кыюсыз гына скрипкага үрелүе дә, ә Җаекта кубыз уйнавы да очраклы түгелдер. Әле шагыйрь талантының тагын бер ягы, аның һич көтелмәгән вазыйфага алынуы мәгълүм.

Монысы Мәкәрҗәдә була. Биредә сәфәр юллары татар халкының өч күренекле затын – Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал һәм Габдулла Кариевны очраштыра. «Двухсветная» кунакханәсе идарәчесе Тимерша әфәнде Соловьев аларны кунаклар алдында чыгыш ясарга күндерә. Кечкенә сәхнәдән җырлар агыла. Икенче көнне хуҗа кызыл фәсләр алдыра. Бердәнбер зәңгәр фәс исә Габдулла Тукайга бирелә, чөнки аңа ансамбльнең капельмейстеры бурычын үтәү йөкләтелә. Халыкка арты белән басып, шагыйрь дирижерлык итә башлый. Ул репертуарны да үзгәрткәләп тора, концерт программасына яңа җырлар кертә... Дөрес, үз-үзенә таләпчәнлек күрсәтүчән Габдулла Тукай соңыннан әлеге «кәмит»не искә төшерергә яратмаган. «Калдыр әле шуларны!» – кебек сүзләр белән әңгәмәгә тизрәк нокта куярга тырышкан.

Ничек кенә булмасын, тормышта табигый рәвештә килеп чыккан мондый хәлләр шагыйрьнең җыр-музыка белән нык һәвәсләнеп китүен раслый. Шулай фаразлау өчен дә бик ышанычлы нигез бар: ул «Туган тел»не күмәкләп җырлаган миллионлы халыкка да алды белән борылган хәлдә дирижерлык итә алыр иде. Хәер, милли символыбызга әверелгән Габдулла Тукай безне инде болай да җырлата.

Сүз-фикер сөрешеннән кат-кат аңлашылганча, «Туган тел» шикелле илаһи гүзәл әсәр иҗат итеп калдыру өчен Габдулла Тукай бөтен яктан да әзерлекле, лаек һәм хаклы иде. Шуңа күрә аны барча төрки кавемнәр ятлап алды, шулай ук башка халыклар да яратып кабул кылды. Дөньяның 30лап теленә тәрҗемә ителгән шигырь милләтара илчелек чикләрен һаман саен киңәйтә. Чуашстанның халык шагыйре Педер Хузангай әйтмешли, «Габдулла Тукайның чакыру авазы бүген тулы көченә яңгырый: «Яшәсен туган тел!»

Халык үзе шаһит, хәзерге чорда «Туган тел»дән файдалану рухи-мәдәни тормышның төрледән-төрле өлкәсен колачлый. Әмма аның рухландыргыч һәм тәрбияви вазыйфалары күзалланган чаралар белән генә төгәлләнми әле. Яшәеш атрибутына әверелгән әсәрнең йогынтылы көчен арттыру өчен күрер күзгә гадәти тоелмаган заманча алымнар куллану кирәк. Гамәлгә ашырылуны көткән кызыклы идеяләр шактый. Әйтик, ничәмә-ничә халыкка бер гасырдан ары юлдашлык итеп килгән «Туган тел»гә төрки кардәшлек мәркәзе саналган Казанда үзенчәлекле һәйкәл куя

алабыз лабаса! Аны болайрак эшләргә була: озынча мәрмәр панно уртасында «Туган тел» – татарча, сулда – русча, уңда инглизчә язылган; артта әлеге шигырьне шундый ук тәртиптә гарәп графикасында, башкортча, төрекчә укырга мөмкин; алда милләт дәвамчысын гәүдәләндергән малай, чүгәләгән көенә, гимн-мәдхия сүзләрен иҗекләп күңеленә сеңдерә; аның иңбашына уң кулын куйган хәлдә, үзебезчә киенгән яшь ана басып тора.

Европа илләрен бизәгән сыннарны махсус карап йөргәнем хәтердә. Мәсәлән, Австрия, Германия, Польша, Чехиядә нинди генә һәйкәлләр салынмаган! Алар арасында гадәти скульптура үрнәкләре дә, кабатланмас булып тоелган ансамбльләр дә очрый. Алдында торып күзәтәсең, аннары арттан багасың. Күпчелеге төрле яктан да бик килешле рәвештә күренә. Хәер, безнең борынгы башкалабызда да күзгә эләрлек сыннар хәтсез: Идел-ана, Хөррият, Хәйрияче, Су ташучы, Элемтәче, Су анасы, Былтыр белән Шүрәле һ.б. Әнә, шәһәр үзәгендәге Бауман урамында Екатерина II каретасы туктап калган. Казан мәчесе дә таш постаментка күтәрелгән. Боларны күпсенергә кирәкми. Игенчеләр сарае каршында да зур һәйкәл торгызу көтелә. Анысы хезмәтчел крестьянны мәңгеләштерер. Менә шулар арасында «Туган тел» скульптур ансамбленә – бөек шагыйребезнең мөкатдәс әманәте гәүдәләнешенә урын табылмасмы?!

Мантыйк күрсәткәнчә, беркадәр күнегелмәгән әлеге һәйкәл башкалабыз үзәгендә, Габдулла Тукай мәйданы тирәсендә урнаштырылырга тиеш. Төгәлрәк әйткәндә, аны җәяүлеләр генә йөргән Бауман урамы башланып киткән төштә, яки Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры алдындагы мәйданчыкта яисә «Әкият» Татар дәүләт курчак театры янында күрәсе килә. Һәйкәл урыны Казаныбыз туристлары өчен дә, экскурсия оештыручылар өчен дә уңайлы булсын. Аның хозурында Туган тел көне тантаналарын да, «Мин татарча сөйләшәм» акциясенең кайбер чараларын да, мәктәп-гимназияләрнең ана теле буенча күчмә дәресләрен дә, танылган шагыйрьләр белән очрашуларны да үткәрергә мөмкин. «Туган тел» скульптур ансамбле шартлы очрашу ноктасына әйләнсен. Биредә фоторәсемгә төшү дә бик истәлекле килеп чыгачак. Аннары инде ошбу һәйкәлнең кечерәйтелгән үрнәген ясату да, аны шәһәрдә күпләп сату да көн тәртибенә куелыр. Мондый символик макет гомуми белем йортларындагы татар теле һәм әдәбияты кабинетларын да, төрле дәүләт учреждениеләрен һәм бала тәрбияләүче ишле гаиләләр яшәгән һәрбер өйне дә, чит төбәкләрдә һәм аерым илләрдә эшләүче үзебезнең милли җәмгыятьләрне дә бизәп торачак.

Инде исбат ителсә кирәк, күп кенә халыкка бәһаләп бетергесез хезмәт куйган «Туган тел», һичшиксез, күпне кичергән ана телебез пайтәхетендә мәһабәт һәйкәл торгызуга лаек. Гомуммилли идеябезнең бер күрсәтмә әсбабына әверелгән очракта, аның берләштерү һәм тәрбияви әһәмияте зураеп китәчәк. Мондый игелекле гамәлне бергәләп тормышка ашырсак, һаман саен катлаулана барган тел мәсьәләләренә игътибар көчәеп, дәүләт статусындагы телгә ихтирам тагын да артыр иде. Шундый кайгыртучанлык күрсәтсәк кенә без элгәрләрнең иң олуг мирасын киләчәккә илтеп, Габдулла Тукай сыман рухи әйдәманнар алдындагы мөкатдәс бурычны өлешчә кайтара алырбыз. ■

Безнең мирас №7 июль 2019

СИХЕРЧЕ КАРТ

Рафаил Шәйдуллин

Бу хикәя Бөек Ватан сугышында һәм японнарның Квантун армиясен тар-мар итүдә катнашкан гади татар солдатына – гвардия сержанты Нурулла Абдрахимовка багышлана. Ул хәзерге Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районындагы Лабит авылыннан 1941 елның 10 июлендә сугышка китә. Димәк, Нурулла Абдрахимов сугышның өченче атнасында ук Кызыл Армия сафларына баса. Бүләкләү документларында аның әнисе Мөршидә турында гына мәгълүмат бар. Сугышка киткәндә аңа 40 яшь була. Ул 1911 елда туа. Нурулла Абдрахимов (халык телендә Нурук, Нурук бабай) Кызыл Армия сафларында биш елдан артык хезмәт итә һәм төрле хәрби операцияләрдә, бәрелешләрдә катнаша. Күрсәткән батырлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

Мин аны бала чактан белә идем. 1960-1970 елларда Нурулла бабай миңа бик карт булып тоела иде. Бер уйлаганда, хәзер миңа 60 яшь диярлек, әмма үземне бик карт итеп хис итмим. Ә аңа ул вакытта 50-60 яшь кенә була. Шуны да әйтәсем килә: Нурулла бабай бик тыйнак, тырыш һәм ярдәмчел кеше иде. Ул һәр кешегә – баламы, өлкәнме – елмаеп мөрәҗәгать итә, авылдашларының сораулары, үтенечләренә дә шулай ук елмаеп җавап бирә иде. Ләкин аның елмаючан күз карашында бер сихерле борау бар. Уйлавымча, нәкъ менә шул бораулы карашлы кара күзләре Лабит авылы халкында төрле имеш-мимешләр барлыкка килүгә нигез булып торгандыр да. Авылдашларымның кайберләре аның «сихере», «авыр аягы» булуына ышанып яшәде. Зур эш башлаганда Лабит халкының күпчелеге ничек булса да аның белән очрашмау юлларын эзли, бу күренеш «Алга» колхозының Лабит авылы бригадасы механизаторлары арасында киң таралыш алган иде. Трактор, комбайн һәм башка төрле техника чаралары ватылгач, аларның кайберләре, уфтанып: «Бүген каршыма Нурук очрады», – дип әйтеп килделәр. Шул сүзләрне ишетеп, механизаторларның кайберләре: «Үзе белән капчыгы бар идеме?» – дип шаяртып сорыйлар иде. Шуннан соң һәммәсе дә шаркылдап көлеп җибәрәләр һәм бер-берсенә төрттереп, шаяруны дәвам итәләр. Әлбәттә, Нурулла бабай сихеренең механизаторның техникасы ватылуына бернинди дә катнашы булмагандыр. Аның капчыгы да, ризыктан һәм көндәлек кирәк-яраклардан тыш, бернинди дә сихер сакламагандыр. Үзе белән кул капчыгы йөртү гадәте аңа сугыш елларыннан кереп калган булса кирәк. Бүгенге көндә дә, ул вакыттагы кебек үк, техника чаралары ватылмый тормый, аның сәбәбе күбесенчә механизаторларның техник квалификациясенә, уңганлык һәм тырышлык дәрәҗәсенә бәйле. Авыл мәктәбендә укыган вакытта миңа да, башта эти (Бөек Ватан сугышы ветераны Вәли Әхмәт улы Шәйдуллин) белән дүрт ел комбайнчы ярдәмчесе, соңыннан үземә, 2 ел комбайнчы булып, җәй айларында «Алга» колхозында эшләргә туры килде. Безнең комбайннар да кайчак ватыла торды,

ләкин әти дә, мин дә моны Нурулла бабай һәм аның «сихерле капчыгы»ннан күрмәдек. Комбайн каршысына очраганда шул «сихерче бабай»ны әти һәрвакыт, киез эшләпәсен башыннан салып, елмаеп сәламли, ә Нурулла бабай үзенең серле елмаюы белән безгә үзенчә әйбәт теләкләр теләп кала иде.

1969 елның җәендә әтигә яңа комбайн бирделәр, аны Якушка тимер юл станциясеннән алып кайтырга кирәк иде. Әти үзе иске комбайны белән уракта булу сәбәпле, комбайнны алырга Лабит авылы механизаторы Ислам Әбляевне җибәрделәр. Авылдан чыкканда аның каршысына үзенең «сихерле капчыгы» белән Нурулла бабай очрый һәм ул, каушап, коелып төшә. Ислам ага үз-үзенә: «Юл уңмады», – дип әйтеп куя. Ләкин ул Якушкадан әтигә менә дигән комбайн (СК-4) алып кайта. Шул комбайнда әти үзе җиде сезон һәм аның уллары: мин – ике һәм энем Раил бер сезон эшләдек. Ул вакытта комбайннар уракта уртача 6-7 сезон гына эшләделәр, шуннан соң аларны ашлыкны егуда гына кулландылар яки тимер-томырга озаттылар. Минем фикеремчә, Нурулла бабай өчен уңган һәм сәләтле кешеләрнең каршына чыгып, аларны сәламләп, изге теләкләр белән озатып җибәрүе гадәти хәл булган. Аның бу гадәте сугыш елларыннан калган булса кирәк. Ул Бөек Ватан сугышы кырларында өлкән ат йөртүче булып хезмәт итә. Яшь солдатларны һөҗүмгә озату һәм аларны һөҗүмнән соң якты йөз белән каршы алу – аның көндәлек фронт тормышы. Нурулла бабай сугышчыларның ышанычлы кешесе дә була, чөнки сугыш барышында рәхимсез дошман уты астында ул аларга сугыш кирәк-яраклары илтә һәм яраланган солдат-офицерларны, ат арбасына яки ат өстенә салып сугыш кырыннан алып чыгып, үлемнән саклап кала. Нәкъ шулвакытта Нурулла бабайның сихерле капчыгы сугышчыларга ярдәмгә килә дә инде. Анда су һәм ризык, махорка гына түгел, яраланган сугышчыларга кирәкле мамык, бинт, хәтта дару һәм спирт та була. Ул үзенең сихерле карашы белән үлем тозагында яткан солдатларда яшәүгә – ышаныч, дошманга нәфрәт тудыра алган. Кайбер очракта аларны соңгы юлга да озаткан. Сугыш кырларында бик күп үлемнәр күрүгә карамастан, аның җан-күңеле кырысланмаган, кешегә мөнәсәбәте тупасланмаган. Нурулла бабай һәрвакыт кешелекле булып калды. Мин белгән балачакта да ул нәкъ шундый иде.

Бер уйлаганда, «сихерче карт» Нурулла Абдрахимов кем соң ул? Хәрби архив документларыннан күренгәнчә, Бөек Ватан сугышы елларында Нурулла бабай – гади совет солдаты, укчылар полкының ярдәмче (обоз) взводында өлкән ат йөртүче вазыйфасын башкара. Дүрт ел буе диярлек үзе хезмәт иткән һөҗүмдә катнашучы полк батальоннарын сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итү һәм яраланган солдат-офицерларны сугыш кырыннан алып чыгу аңа йөкләнә. Винтовка тотып дошман һөҗүмнәрен батырларча кире кагуда катнашуы турында да мәгълүматлар бар анда. Бу взводка аны билгеләүнең сәбәбе дә бар, дип уйлыйм. Ул бик кыска буйлы (165 см чамасы), гәүдәгә дә зур (70 кг тирәсе) булмый. Нурулла Абдрахимов сугышның беренче айларында ук диярлек коммунист булса да, аны укчылар сафына җибәрүгә командирлары бик нык каршы торалар. Чөнки ул бик ышанычлы, сәләтле, эшчән, тапкыр була, атларны бик ярата. Сугыш елларында совет командованиесенең бик күп ышанычлы йөкләмәләрен үти. Күрсәткән батырлыклары өчен бер орден һәм өч медаль белән бүләкләнә. Бу дәүләт бүләкләре обозда хезмәт иткән солдат өчен бик зур уңыш һәм сирәк күренеш булгандыр, дигән уйга киләм. Ярдәмче ат обозларында хезмәт иткән солдатларның күпчелегенең бернинди дә сугышчан орден-медальләре булмый, чөнки аларның сугышчан батырлыклары игътибарсыз кала. Әлеге сугышчыларның күбесе бары тик юбилей медальләре белән генә бүләкләнә.

Ә менә Нурулла Абдрахимов үз бүләкләре белән шаккаттыра. Минемчә, монда да аның сихере булгандыр, мөгаен. Ул – аның кешелеклелегендә, батырлыгында һәм тап-

кырлыгында. Шунысы да кызык, Нурулла Абдрахимов үзенең беренче «Сугышчан хезмәтләре өчен» («За боевые заслуги») медален өч ел диярлек көтә. Ул аңа 1943 елның 24 декабрендә Белоруссиядәге Пруды авылы янындагы сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен бирелә. Нурулла Абдрахимов көчле дошман уты астында укчы полкның батальон сугышчыларына сугыш кирәк-яракларын вакытында китереп, аларга хәрби бурычларын үтәүдә ярдәм итә.

Икенче дәүләт бүләге – «Батырлык өчен» («За Отвагу») медаленә Нурулла Абдрахимов 1944 елның 23 июнендә лаек була. Дошман уты астындагы һөҗүм барышында ул сугышчыларны даими рәвештә хәрби кирәк-яраклар һәм ризык белән тәэмин итеп тора һәм бик күп яралы солдат-офицерларны сугыш кырыннан алып чыга, аларның күбесен үлемнән саклап кала.

Өченче дәүләт бүләгенә – «Кызыл Йолдыз» («Красная Звезда») орденына Нурулла Абдрахимов 1945 елның гыйнвар-февралендә Көнчыгыш Пруссия өчен барган каты сугышларда аеруча зур батырлык күрсәткәне өчен лаек була. 1945 елның 22 гыйнварында Гросс Папеп авылы янында барган сугышларда ул сугышчыларны көчле дошман уты астында хәрби кирәк-яраклар белән тәэмин итеп кенә калмый, мылтык күтәреп дошман контратакасын кире кайтарырга да ярдәм итә. Шул елның 10 февралендә Лангер Вальд урманында барган сугышларда Нурулла Абдрахимов, укчылар взводы составында, дошманның 12 контр һөҗүмен кире кага, 5 немец солдатын юк итә һәм кыйммәтле документлары белән бер «тел»не кулга төшерә.

Әмма Берлинны алгач та, Нурулла Абдрахимов өчен сугыш тәмамланмый әле: аны 1945 елның язы-җәендә Көнчыгыш Пруссиядән полкы белән Ерак Көнчыгышка – Төньяк японнарның Кытайда урнашкан бер миллионлы Квантун армиясенә каршы сугышка озаталар. Ул бөтен ил буйлап, ике ай чамасы вакыт узгач, Кытай чикләренә килеп җитә. Бу сугышта Нурулла Абдрахимов инде ат йөртүче комендант взводы командиры, гвардия сержанты вазыйфаларын башкара. Аның карамагында полк штабының

яшерен документлары белән дивизия обозы була. Ул обоз белән Кытайдагы Хинган тауларын, ком-таш чүлләрен һәм Маньчжурия сазлыкларын сугыша-сугыша үтә. Аның комендант взводы, бер меңнән артык чакрым үтеп, билгеләнгән урынга вакытында һәм берниндi югалтусыз диярлек килеп җитә. Нурулла Абдрахимов җитәкләгән взвод тәүлегенә уртача 40-50 чакрым юл үтүенә карамастан, аның карамагындагы атлар исән-сау һәм көр булалар. 1945 елның 14 сентябрендәге бүләкләү документында Нурулла Абдрахимов турында шундый сүзләр язылган: «Лично дисциплинирован и исключительно вынослив, четко следил за упитанностью и сохранением тягловой силы». Бу язманы күргәч, Бөек Ватан сугышы солдатларының исемлеген барлау буенча озак еллар буе Россия күләмендә эш алып барган җирле «Ватан» оешмасы җитәкчеләренең берсе Рәфыйк Сәлахиев, гаҗәпләнеп: «Наградной документларда шундый җентекләп һәм батырлыкны тулыландырып характеристика биргән язмаларны бик сирәк очратып була», – диде. Мин, аның сүзләрен ишеткәч, шаяртып: «Ул бит сихерче бабай», – дип әйтеп куйдым. «Дөрестән дә, аның сихер капчыгы булгандыр», – дип әйтте ул да. Димәк, аның шундый сихри, кешелекле сыйфаты булгандыр һәм шуның белән башкаларны да үзенә җәлеп итә алгандыр. Хәтта батыр татар солдаты турында документларны тутыручы да шундый күркәм һәм матур сүзләр таба белгән. Япон милитаристларына каршы каты сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен, Нурулла Абдрахимовны икенче тапкыр «Батырлык өчен» медале белән бүләклиләр.

Совет-япон сугышы тәмамлангач, Нурулла бабай 1945 елның ахырында туган ягына кайтып, колхозда эшли башлый. Ул зур вазыйфаларга үрелми, баш тарта, гомере буе гади колхозчы булып хезмәт итә. Әлбәттә, аның җитәкче урыннарга утыру өчен мөмкинчелекләре дә булгандыр, дип уйлыйм. Сугышта взвод командиры, ордены һәм өч медале була. Шунысы да мәгълүм: аның хатыны Нурҗиһанның энесе Шәехислам Ибраһимов – сугыш ветераны, өченче дәрәҗә Дан ордены кавалеры, сугыштан яраланып кайткач, хисапчы, озак еллар «Алга» колхозы рәисе булып эшли. Ләкин ул бу форсаттан да нигәдер файдаланмый. Киресенчә, аңа гади колхозчы тормышы ошый төшә, дип уйларга урын бар. Нурулла бабай мал карауны, аеруча атларны, фермада һәм келәттә үзе генә каравыл торуны хуп күрә иде.

Сугыштан соңгы авыр, ач-ялангач елларны әйтеп тә тормыйм, хәтта мин белгән елларда да Нурулла бабайга хәтәр очраклар һәм зур хәсрәтләр кичерергә туры килде. 1969 елның көзендә, янгын чыгып, шифер түбәле, матур, зур, иркен итеп салынган өе һәм каралты-куралары тулысынча диярлек янды. 1970 нче еллар башында авылда яшәгән бердәнбер улы Адиулла вафат булды. Улының хатыны Наилә, бабайның ике оныгы Фәрит белән Айсылуны ияртеп, Куйбышев (хәзерге Самара) шәһәренә күчеп китте. Шулай итеп, алар авылда хатыны Нурҗиһан әби белән икәүдән-икәү калдылар. Нурулла бабай, пенсиядә булса да, озак еллар колхозда эшләп йөрде. Олы яшьтә булуына карамастан, аның өе һәм каралты-курасы төзек һәм каралган иде. Алар, хатыны белән бергәләп, хәлләреннән килгәнчә мал-туар һәм кош-корт асрадылар. Роза исемле кызлары да авылга Самарадан бик сирәк кайта, җәй көннәрендә Розаның ике баласын бабаларында күреп була иде. Бүгенге көндә аның өендә башка гаилә яшәвенә карамастан, ул салган йорт һаман да күзне шатландырып һәм күңелне җылытып тора.

Лабит, Әбдери һәм тирә-яктагы Тупли (Измаил), Зирекле Куак, Идәй авылларыннан да Нурулла бабай кебек гади, сугыш кырларында батырлык күрсәткән солдатлар күп чыккан. Әлеге сугышчыларның батырлыгы турындагы язмаларны хәзерге авыл халкына, яшь буынга һәм сугыш ветераннарының туган-тумачаларына җиткерү бүгенге көндә һәр кешенең бурычы, дип уйлыйм. Аларның һәммәсе дә мәңгелеккә китте һәм без аларны хөрмәт һәм дога белән искә алырга тиешбез. ■

ӨЧӘҮ

(хикәя)

Рашат Низами

Сугыш җиле нибары алтмыш морҗалы Янык авылына да килеп кагылды...

Ир-егетләр сугышта. Аларның да инде икесе мәңге әйләнеп кайтмаячак – гаиләләренә килгән «кара пичәтле» хат шулай сөйли. Орденнарын ялтыратып, Госман солдат кайтты кайтуын – тик аны күргәч, авыл халкы ни шатланырга, ни кайгырырга белмәде: егетнең аяклары тездән түбән икесе тиң юк иде. Гүя әллә кайдагы Гитлерның чалгыдай озын куллары бирегә кадәр сузылган да Госманның аякларын өзеп алып киткән. Хәл белә килгән кеше әнә шулайрак уйлый, фашистларга ләгънәт укый. Ана кеше улына дип әзерләгән пар оекбашны сандык төбеннән ун алып, ун тапкыр гына кире куймагандыр. Ахыр чиктә ул аларны үзгәртеп, Госманның аякларына ярашлы итеп кабат бәйләде.

Таһир атлы малай мәктәптән кайту белән абыйсы янында кайнаша, аның йомышларын үти, җай гына чыксын – шундук сугыш турында сораша башлый: янәсе, абыйсы шартлаткан танк ничек итеп янган да, дошман снаряды җиргә ничек, ни рәвешле килеп төшкән...

Тик менә соңгы вакытларда абыйсы сүзгә саранланды, караватта утырган җиреннән озак-озак итеп тәрәзәгә караганда энесенең кайбер сорауларын ишетмичәрәк тә кала. Җир җимертеп йөрер чагында чарасыз кадакланып ятудан йөрәгә сыза аның. Китаплар да укып карый, кышкы озын кичләрдә киез итек астына олтан да салгалый, ләкин егет кеше өчен болар гына җитми, күрәсең. Олтанны шулкадәр оста ябыштыра ул, агач җилеме белән катырганнан бер дә ким түгел! Иң элек сумала белән ышкый-ышкый

олтан җебе әзерли, иске итек кунычыннан өлге кисә. Бар да әзер, башларга мөмкин. Юк, ул ашыкмый, фокусчыныкыдай җиңел хәрәкәтләр белән башта учларын ышкый, бармакларын шартлатып ала. Аннары гына кулындагы очлы безне олтан буйлап йөгертә башлый. Элмәк салгач, җепне шундый итеп тарта ки, теге бичара скрипка кылыдай зеңләп куя.

Бу көннәрдә бабасы калага җыенып йөри. Абыйсына протез ясату өчен барачак ул анда. Тизрәк өлгертеп кенә куйсыннар, менә шуннан соң йөреп күрсәтер Госман абыйсы! «Протез киюем белән мин сугышка протест белдерәчәкмен», – дигән сүзләрнең мәгънәсенә кат-кат уйлангач кына төшенде Таһир: сугыш берәүгә дә кирәк түгел, ул кешеләрне үтерә, яралый, гарип калдыра...

Бүген, өйдә берәү дә юк чакта, абыйсы хикмәтле сүзләр әйтеп ташлады бит әле:

– Әзер бул, кызлар аулак өйгә чакыру җибәргән. Кичкә шунда барачакбыз.

Мондый бәхет абыйсы булган кешегә генә эләгәдер шул – Таһирның беренче тапкыр аулак өйгә баруы! Госман абыйсы инде салып куярга өлгергән хәрби гимнастеркасын, йолдызлы бүреген киде. Шома итеп кырган иякләренә уч тутырып ислемай сөртте. Таһирның шомырт агачыннан ясалган кул чанасы әзер: үрәчәләрне капларлык итеп кызыл юрган җәелгән, шуның уртасында – кабарып торган мамык мендәр. Беркайчан ватылмый, туктап калмый торган шушы «транспорт» белән барачак алар аулак өйгә.

...Гыйнварның чатнама салкын киче. Телеграф баганалары бозланып каткан, биектә йолдызлар калтырана. Оеп утырган агачларга барып кагылсаң, күктәге йолдызлар шыбырдашып җиргә коелыр кебек. Йорт тәрәзәләрендә ут җемелди. Урам буйлап шулай абыйлы-энеле югары очка менеп баралар. Чанада – абыйсы, аның алдында чуклы шәлъяулыкка төргән ике рәтле гармун. «Хромка» дип аталган бу нәрсәкәй заманында, ягъни сугышка кадәр, төнге урамнарның тынычлыгын алган гармун иде. Ә хәзер урамда уйнау ничектер килешми, фронттагылардан хәбәр көтеп ятканнарның бәгъренә кагылу шикеллерәк тоела.

– Энекәш, тукта!

Уйнамый гына йомылып барудан гармунның эче поша, ахрысы, салулаган чакта чанадан тәгәрәп төшкән икән! Посылка тартмасы чаклы гармунны абыйсының кулларына тоттыра Таһир һәм чана бавын яңадан җилкәсенә атландыра. Чана табаны астында бертуктаусыз кар шыгырдый... Йөк атлаган саен авырая, чана бавы муен тамырларын кисеп керә. Чәч төпләре тирләп чыкты Таһирның, тик сынатырга ярамый, көне шундый ич бүген. Аннары абыйсының гармун уйнавын да бик сагынды ул.

Сәбәп чыгуга куанып, Таһир туктап калды: сәер һәм хәтта шомлы адымнар белән, озын гәүдәле кемдер берәү каршыларына килә... Кара пәлтәдән, кара бүректән. Бәрәч, беркайчан үзгәрми, атнага бер кырына торган Тиле Шәяхмәт ич бу! Табигать тарафыннан кыерсытылган җан буларак, ни кыланса, ни сөйләнсә дә килешә аңа, авыл халкы моңа гадәтләнгән инде. Менә ул килә-килешкә кулының очын гына сузып Госман солдат белән күреште, аннары авыз эчендә әвәләгән җөмләләрен йотып, сабыйларча куана-куана, ниһаять, шаккаткыч ике сүз әйтте:

– Гитлер капут!

Шулай диде дә сузаеп кына тагын авыл караңгылыгына, карлы тынлыкка кереп югалды.

– Күр әле, немецларның Сталинград янында җиңелүен бу да белә микәнни соң? – дип гаҗәпләнде абыйсы, артына борылып карый-карый. Аның кышкы салкынга кушылган елмаюыннан урамнар киңәеп, күкләр биегәеп киткәндәй була Таһир өчен.

Кызлар инде аулак өйгә җыелып та өлгергәннәр. Ишек ачылу белән, кар йомарламыдай тәгәрәп, түргә бер кочак салкын узды. Мичтә пешкән ризык исе борыннарны рәхәт

итеп кытыклый. Кызлар, оялып кына, Госман абыйлары белән берәм-берәм күрешеп чыктылар. Күрешкәндә, Нәзифә исемлесе кызарып ук чыкты, ни өчендер Госман аның кулларын озак кына җибәрми тора... Алты кыз, Таһирның үзен исәпләмәгәндә, шулар янында нибары ике бөртек егет. Соңгысы – унҗидене тутырып килгән, тиздән солдатка каралачак түгәрәк битле Фәйзерахман. Аңа әле мыек та чыгып өлгермәгән.

Шәлъяулык эченнән, егерме дүрт төймәсен берьюлы ялтыратып, гармун килеп чыкты. Җылынсын, сулыш ала торсын, дип, аны караватт почмагына куеп тордылар. Хәл сорашкан, дөнья хәлләрен белешкән арада табын уртасына бәлеш куелды. Кай ара өлгергәндер, диген... Ярма бәлешен ашыкмый гына, агач кашыкны җай гына йөртә-йөртә тәмләп ашадылар.

– Үскәнем, менә монысы сиңа, – дип, бәлеш төбен Нәзифә апасы иң элек Таһирга сузды. Башы түшәмгә тиде малайның, зурлар арасында зурларча утырудан аяк табаннары кытыкланып килде.

Карлыган яфрагы кушып кайнаткан чәйне яшьләрчә тиз һәм житез эчтеләр. Гармун инде тәмам җылынган, рәхәтләнеп сулыш алган иде. Менә ул хуҗасының алдына сикереп менде, Госман солдатның бармаклары кагылуга, башта салмаграк, отыры дәртләнеп, очып-очып «Алмагачым»ны уйный башлады. Ничәмә-ничә буынны солдатка, ерак сәфәргә озаткан көй... Гармун күрегенең эчлеге салават күпередәй ачылып китә. Һәммәсе дә, тын калып, үзалдына нидер уйлый-уйлый, гармун моңын тыңлый. Ә уйлар ни дисәң дә бер генә: кайдадыр еракта сугыш бара, кешеләр кан коя, туган илен саклар өчен утка-суга керә...

Кызлар җырлый, көчәнмичә җырлыйлар. Яшь, таза, дәртле күкрәктән чыккан моң, өйне тарсынып, бозлы тәрәзәгә сарыла, дөньяга саркып чыга. Татар җырларына хас табигыйлек, якты сагыш шуны аңлата: туган ил, туган җир, бу күкләр, кырлар, урманнар – мәңгелек, алар мәңгегә безнең белән калачак...

Ал тәрәз төпләребез шул,
Үрмәле гөлләребез;
Дошманнарның йөрәгенә
Ут салган көннәребез.

Кайда утырганын да онытып, таң калып тыңлый Таһир, көндезләрен бишмәт киеп фермага, амбарга эшкә йөргән кызларның әнә шундый сихерле көчкә ия булуларын әлегәчә белми йөрүеннән уңайсызланып куя. Ә гармун шаша, кызлар белән егетләр күңелендәге яшерен хисләрне үзләре дә сизмәслек итеп бәйли, тоташтыра.

Сандугачым, син кечкенә,
Талларга үрел инде;
Яшь йөрәгем, сүрел инде,
Ул сиңа түгел инде...

Монысын, бөгелә-сыгыла гармун уйнаганда бер бушанып, төрләнеп алу өченме, Госман абыйсы әйттерә. Җырлавын матур җырлый, тик менә әллә ничек булып китә: кызлар бер-берсенең беләгенә кагылыр-кагылмас сагаешып калалар, Нәзифә апа керфекләрен аска төшерә, Фәйзерахман уч төбен тиктомалдан караватт тимеренә ышкый башлый. Госман абыйсы әнә шуларны сизеп алды булса кирәк, «хромка»ны биш төймәдә берьюлы үкертеп куйды да бию көйләренә күчте. Менә Нәзифә апа шунда,

җиң очыннан гынамы, чигүле кулъяулык тартып чыгарды. Ул аяк очларына вак-вак басып кына җиңел хәрәкәтләр ясый, аккош йөзгәндәй әле уңга, әле сулга борылып бии-талпына. Кулындагы дүртпочмаклы яулыгы дәфтәр битедәй ачылып-ачылып китә. Үзе генә түгел, иң өстендәге пар толымнары да гармун көенә бии ләбаса! Гармунчы каршында бер кат бөтерелеп алганнан соң, Фәйзерахманга китереп баса. Фәйзерахман, бәхетле генә елмая да, кулларын әле аска, әле өскә йөртә-йөртә, уртага чыга. Култыклашып әйләнәләр, кулъяулык аның кулына күчә. Күн итек үкчәсе белән идәнне көйдерер дәрәҗәдә очына егет, хикмәтле әйләнешләр ясый.

Их, аяклары исән булса, Госман абыйсы кимен куяр идеме соң! Ул биегәндә клуб тәрәзәләре зыңлап тора иде, дип, әле дә сагынып сөйлиләр бит. Шулчакларны күрергә теләгәндәй, ашкынып, артка каерылып уйный түгелме ул?

Биюне түгәрәкләүче кечкенәрәк буйлы кыз кулъяулыкны «ә», дигәнче гармун каешына бәйләп тә куйды. Хәзер инде кулъяулык – бөтенләйгә аныкы. Нинди бәхетле гармун!

Тәнәфес-мазар ясауларымы, кызларның берничәсе, пәлтә киеп, өйалдына чыгып китте. Фәйзерахман исә, кулларын селки-селки, кичә ферма буенда ничек итеп кыр куяны тотканын сөйли. Мич буе чаршавының теге ягында – Нәзифә белән Госман абыйсы... Нидер аңлашалар. Аларның ярым пышылдап сөйләшкән кайбер сүзләре Таһирның колагына керде:

– Нәзифә... син мине көттеңме?

– Көттем, Госман. Хатларыңны... саклыйм.

– Көткәнсең, рәхмәт... Тик син башканы сайларсың инде. Мин бит...

– Госман... ни сөйлисең, әллә шаяртуыңмы?..

Ул арада Фәйзерахманның куяны берәр мәзәк эшләде, ахрысы, тыңлаучылар гөрләтеп көлеп җибәрделәр. Ишектән, суык ияртә-ияртә, кызлар да кереп җитте. Инде хәйран вакыт узган икән, иртәгә эшкә барасылары бар, таралырга җыеналар.

...Урамда тагын чана шыгырдый, күктә йолдызлар биешә. Тәрәзәләрнең күбесендә ут бар әле, уты сүнгән йортлар гына бераз чүгә төшкән кебек. Кар яктысы белән кушылыр-кушылмас булып, урамга төн карасы җәелгән. Бу юлы инде чананы икәү тарталар. Шуңа күрәме, чана ун тапкыр җиңелрәк, атлаулары да мең тапкыр күңеллерәк. Бәлки, бүләккә бирелгән кулъяулык – тылсымлы канаттыр, бәлки, ул да ярдәм итәдер...

Госман солдатның исә үз уйлары: «Тормышны төптән җигелеп тартырмын, дигән идем, менә бит ничек килеп чыкты – үземне тартып баралар. Ничава, йөрәк сау булсын, калганы кечкенә мәсьәлә...»

– Үскәнем, кемдер килә түгелме?

Куркуыннан түгел, сөйләшергә сәбәп чыкканнан әндәшә бугай Нәзифә апасы. Чыннан да, озын-озын алдырып каршыларына тагын Тиле Шәяхмәт килә. Исәнләшеп тору юк, бары кулларын хәйран селкеп:

– Гитлер капут! – ди дә тагын, кара шәүлә булып, авылның теге башына уза. Әйтерсең, сугыш хәбәрләрен һәркемгә җиткерергә ашыккан төнге бер сөрәнче ул.

Авыл тынлыгын йомшак кына сискәндереп, урам буйлап өчәү баралар. Әнә ялтырап яткан чана эзләреннән ай нуры йөгерә. Килер көннәр яктысын чагылдырган бу күренешне абыйсына да күрсәтәсе килә Таһирның. Тик бер нәрсәне аңлап бетерми ул: Нәзифә апасы озата гына барамы аларны, әллә бөтенләйгә кайтышымы аның?!. ■

Безнең мирас №7 июль 2019

«ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН...»

Әхтәм Зарипов

«Кыю кызлар» спектакленнән бер күренеш: Бибкәйнур – Наилә Гәрәева, Миләүшә – Фирдәвес Әхтәмова, Гайшә – Наилә Ибраһимова. 1968 ел

Шушы исем белән (Фирдәвес Әхтәмовага 70 яшь тулганда) телевизион очерк эшләп күрсәткәч рәхмәт көтеп йөргәндә, телефоннан шалтыратты да ул, иң элек, җиңелчә генә, үпкәсен белдерде: «Тапшыруыңа исемне дөрес сайламагансың, исемем генә матур булганны мин үзем дә беләм», – диде. Күпме генә аклансам да, тынычландыра алмадым, Фирдәвес үз фикерендә калды. Аның өчен рәхмәтне тамашачылар һәм артистканың хезмәттәшләре әйтте. «Дөрес бәяләдең», – диделәр. Бәяләүгә килгәндә, Фирдәвес кемнеңдер бәяләвенә мохтаҗ түгел – ул үзенең кем булуын, нинди сәләтләргә ия икәнлеген, нәрсә җитмәвен дә бик яхшы белеп, булганына канәгать булып, ә булмаганына зарланып, елап яшәмәде. Аның күңеле һәрчак көр, киләчәге өметкә төрелгән була иде.

Елап, зарланып кына яшәрлек хәлдә булса да, Фирдәвестә холкы белән башкаларда яшәү рәхәтен тойдыру сәләте көчле иде.

...Әти-әнисе назыннан мәхрүм калгач, туганнары карамагында гына үскән ятимә кызда ихласлык та, вәгъдәдә тору да, туганлыкның һәм дуслыкның кадерен белү дә башкаларга үрнәк, гыйбрәт булырлык мул иде...

...Минем 1925 елгы абыем 18 яшендә Ватан сугышында һәлак булгач, әткәй белән әнкәй өчен мин бик тә кадерле бала булып үстем, укыдым, яшәдем. Артистлыкка укыганда «повышенная стипендия», өстәвенә, әткәй-әнкәйдән ай саен стипендия суммасы кадәр акча килә иде (әткәйнең киез итек басу кәсебе табышыннан). Ләкин барыбер акча җитми иде. Ара-тирә Фирдәвестән әҗәткә алып тора идем. Ә бит Фирдәвес бер стипендия акчасына гына яши иде! (Туганнарыннан акчалата ярдәм көтү мөмкинлеге юк...) Мине акча тота белмәүдә гаепләп тиргәгәне хәтердә: «Син үзеңне үзең дә карый алмыйсың, гаиләң булгач нишләрсең!?» – диде.

Фирдәвес хаклы булды: гомер буе акчага интегеп яшәдем. Бик кыен хәлләрдә калганда гел Фирдәвескә бара идем. (Фатиры бездән ерак түгел генә иде.)

– «Өч җирдән хак алып яшәгән Әхтәмнең пенсиядәге Әхтәмовага әҗәткә керүе көлке!» – дип булса да, үтенечемне канәгатьләндерә иде ул. Бу аның акчага туенып яшәвеннән түгел, ә кешелеклегеннән, ярдәмчеллегеннән иде.

70 нче еллар башында булса кирәк, кибеткә алтын чылбыр кайткач, Фирдәвес шул чылбырны алырга театрдагы хезмәттәшләреннән әҗәткә акча җыйды. Кем күпме булдыра ала – шулай бирүләре хәтердә. Китте Фирдәвес кибеткә һәм, күпмедер вакыт узуга, кайтты да: «Беткән...» – диде. Кемнән алса – шуларга акчаларын кире кайтарды.

– Миңа булса, гел шулай инде – йә җитми, йә кайтмый, – дип өстәде аннары.

Шулай дисә дә, Фирдәвес башкалардан ким яшәмәде. Зәвык белән киенә дә, булганына канәгатьләнеп, сөенә дә белде. Аның өчен иҗатташының уңышы, нәрсәгәдер ирешүе дә зур сөенеч иде. Ул көнчел түгел иде. Яшерен-батырын түгел: артистлар арасында роль уйнап дәрәҗәләр алу – зур вакыйга. Кайчакта дәрәҗәләрнең лаексызга бирелү очраклары да булгалый. Сүз китә, гайбәт тарала. Ә Фирдәвес сүзгә, гайбәтләргә игътибарсыз: ул кеше шатлыклары өчен сөенә генә белә... Без аның үзе өчен дә сөенгән, куанган-шатланган чакларын, сирәк булса да, күрдек.

...Фирдәвес өчен һәр премьера шәхси бәйрәм иде. Һәрбер уйнаган роле табышачыш иде. Ул бер ролендә дә алдан элек уйнаган ролен кабатламады. Тәвәккәл иде. Чагыштыру җиңеллеге өчен генә аның ике фильмдагы Биби ролен генә мисалга китерү. Г.Камалның «Беренче театр»ындагы Биби һәм «Бибинур»дагы Биби: икесе ике төрле холык, икесе ике дөнья. Аларны бер генә нәрсә берләштерә: артисткадагы

ихласлык. Үзе ышану белән башкаларны да ышандырып, үзенә әсир итә. Фирдәвес һәр тапшырылган эшкә чын күңелдән бирелеп, аны ихласлык белән башкарды. Кылану, ясалмалык дигән авыруларга иммунитет та табигатеннән килә иде.

Сценарийларын язып, үзем үк төшергән телефильмнардагы рольләрен санап тормыйм, Фирдәвес хәтерләрдә һәр ролен җиренә җиткереп, кирәкле сыйфатта башкаруы белән саклана.

«Щепкинчылар» дип йөртелгән артистлар төркеменең, укып кайтып театрда эшли башлауларына 50 ел тулуны бәйрәм итү кичәсендәге чыгышында Фирдәвес үзен: «Мин узган гасыр кешесе», – дип атады. Кичәдән соң мин аңа: «Юк, Фирдәвес, син узган гасыр кешесе түгел, син – киләчәк гасырлар артисты», – дидем. Ул бу вакытта инде каты авыру булганлыктан, күңелен күтәрмәкче булып әйткән идем. Кабул итмәде. «Мин узган гасыр кешесе булуым белән горурланып әйттем», – дип, узган гасырдагы кешеләрнең хәзерге кешеләр белән чагыштырмаслык яхшы якларын, иманлы, вөгъдәле булуларын санап китте. Кушылудан башка чарам калмады, әлбәттә.

Шулай да, «ятып калганчы атып кал», дигәннән чыгып, аның Бибинур образы Аяз Гыйләҗев иҗат иткән образга якын түгел дигән сүз ычкындырам, Аяз агай совет чорында иҗат иткән, «совет шулпасын» мул эчкән әдип бит. Сәясәтнең, идеологиянең кулы совет чорында әдәбиятта да, сәнгать төрләрендә дә бик ачык сизелә иде. Шул сәясәт күп язучыларның кулыннан каләмен алып, аларга көрәк-кәйлә тоттырды.

Аяз Гыйләҗевнең кулы, кәйләдән соң ныгып, каләмен ычкындырмас көчкә ия булды. Аның иҗатында «туган җир», «туган йорт», «әти-әни», «ир-ат», «яшәү һәм

НАИЛӘ ГӘРӘЕВА,
Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты:

«Фирдәвескәй, дип дәшә идем мин аңа. Үзен шулай яратуым, якын итүем булгандыр. Театрда без бер гаилә булып яшибез. Барыбыз да дуслар кебек, ләкин арада чын дус берәү генә була. Дуслыкны саклау, бигрәк тә театр дөньясында, җиңел түгел. Ул үзенә күрә бер сынау. Аллага шөкер, без Фирдәвес белән дуслыкны саклап кала алдык.

Фирдәвескәй ул – театрның иманы иде. Акыллы, кешелекле, үз эшенә тугрылыклы кеше. Моңлы дускаем минем. Моң аның табигатендә, үзәгендә иде – Ходайдан бирелгән бүләк ул. Безнең шактый гомеребез бергә узды. Шатлыкны да, кайгыны да бергә бүлештек...

Фирдәвес белән намазга да бергә бастык. Монда да аның йогынтысы зур булды...

Фирдәвеснең гомере кисәк кенә өзелде дә куйды. Бүгенге көнгә кадәр аның юклыгына ышанып бетә алмыйм. Сагындыра, юксындыра Фирдәвескәй, ахирәт дускаем...»



Ахирәтләр: Наилә Гәрәев (уңда) белән Фирдәвес Әхтәмова. 1970 ел

үлем», «зират» (символик мәгънәгә ия) бик тә мөһим төшенчәләр булдылар. Әдип күп әсәрләрендә игътибарын татар милләтенең яшәвенә, милләтнең киләчәге өчен «даруга рецептлар» тәкъдим итүгә юнәлтә. Аның әдип буларак рухи халәтен татар милләтенең язмышыннан аерым карап булмый. Иҗатының төп мотивы да шулдыр.

«Җомга көн кич белән» повестендагы Аксыргак авылының колхоз рәисе Җиһангир Сәфәргалин (44 яшендә генә булуына карамастан) авыл зиратын чистартуга, аны төзекләндерүгә ихлас күңелдән игътибарын юнәлтә. Символ бит бу! Аның бу гамәлләрен күреп яшәгән тол карчык Бибинур шул яшь рәискә чын күңелдән гашыйк була. (Символлар символы!)

...Кызганыч ки, Җиһангир Сәфәргалинның гомере кыска булып чыга. Аны туган авылы Тегәрҗеп зиратына бабалары янына кайтарып җирлиләр. Бибинур, Тегәрҗеп зиратына кадәр барып, «Әлхәм» һәм «Кулһуаллаһу»сын укып, Җиһангирны мәңгелеккә озата. (Символ!)

Аяз Гыйләҗевнең һәр әсәре татарның йөрәк җылысы белән сугарылган. Ә «Җомга көн кич белән»дәге Бибинурның йөрәк җылысы ул – мәхәббәт белән типкән татар йөрәге җылысы. Тереклек өчен җылылык – төп шарт. Аяз Гыйләҗевнең әсәрләрен укыган күп кеше аның дөньяга сибелеп яшәгән татар милләтенең рухын, җанын саклау юнәлешендә иң саллы өлеш керткән әдип булуына шикләнмичә, әсәрләре буенча куелган фильм-спектакльләргә дә иманнарын яңартырга баргандай барачаклар, караячаклар, ышаначаклар. Бу фикерләрне мин, әдипнең «Җомга көн кич белән» әсәре буенча үзем күп серияле фильм-спектакль төшереп күрсәткәч, килгән хатларга таянып яздым. Без төшергән фильмда Бибинурны Фирдәвес Хәйруллина уйнады. Ике Фирдәвес – ике Бибинур, ике фильм. (Кызганыч ки, икесе дә мәрхүмә.) «Бибинур» фильмында Аяз Гыйләҗев тә, татар рухы да калмаган иде. Төсле пыяла аша караганда, дөнья шул пыяла төсендә генә күренә. Ә «Бибинур» фильмы төрле

төстәге пыялаларны катлы-катлы итеп карар өчен төшерелгәндәй иде. (Образлар танылмый, вакыйга чит-ят милләтчә.) Уйлаганын яшерми турысын әйтә торган кеше булуын таныганлыктан, мин фильмны кабул итмәвемне, ошатмавымны белдердем. Ә Фирдәвес фильмның конкурсларда җиңүе, берничә приз яулавы турында сөйләп, минем фикерем белән килешмәүдән: «Син көнләшәсең», – диде. Бәлки, ул хаклыдыр. Бездә шулай бит: «Үзебезнекеләргә – умач, килгәннәргә – күмәч».

Тулы канлы образларны, үзенчәлекле типларны (коммерциягә ияреп) фильм өчен кирәкле муляжлар белән алыштыру сәнгать дип атала, хәтта мактала, бүләкләнә. (Замана чире генә булса ярый.) Киләчәктә Галиябану Исмәгыйльгә кияүгә чыкса, Анна Каренина исән калса, Неклюдов Катеринаны озатып Себергә бармаса – болар барысы да заман режиссерының әсәрне үзенчә чишәргә хокуклы булуы «теориясе» белән якланылачак.

Инде бик тирәнгә керми, киңлеккә җәелми генә Фирдәвес Әхтәмованың актерлык

ХӘЛИМӘ ИСКӘНДӘРОВА,
Татарстанның атказанган артисты:

«Театр ишегалдындагы тулай торакта без Фирдәвес белән икәү дүрт ел бергә яшәдек. Азиядә (Ташкентта) тууым, үсүем һәм татар телен бөтенләй белмәвем сәбәпле, ул миңа туган телне өйрәнүдә зур ярдәм итте. Фирдәвес миңа бирелгән роль текстын укый, ә мин исә аны ятлый идем. Үз чиратымда мин аңа рус телен үзләштерүдә булыштым, аны совет поэзиясенең иң яхшы үрнәкләре белән таныштырып бардым. Еллар узды. Гаиләле булдык, балаларыбыз туды, гаиләләребез белән йөрештек. Бәхет озын гомерле булмый, диләр. Аның Мараты яшь килеш якты дөньядан китте. Аннары минем Николаем белән мәңгегә хушлаштык. Күңелләребездә газиз ирләребезне югалтудан, бушлык хасил булды...

Фирдәвес белән без телефон аша еш сөйләшә идек. Соңгы вакытларда иртән дә, кичен дә озаклап сөйләштек. Ни турында сөйләштекме? Мәсәлән, атлар турында. Атларга сокланып караганын белгәнгә күрә, мин аны ипподромга – Россия Президенты призына узган ярышка алып бардым. Аны шул көнне күрсәгез иде сез! Йөзе кояштай балкый, үзе вакыт-вакыт урынынннан сикереп тора да кечкенә йодрыгын күккә чөя, үзе бар көченә кычкыра, үзенә ошаган чабышкыны күргәч, карале, карале, биле нинди нечкә, дип, минем янтыкка төртеп ала...

«Бибинур» фильмында без бергә төштек. Әлеге фильм аның тормышының бер бизәге булды. Фирдәвес бакый дөньяга бәхетле кеше булып китте».

Мәрфуга – Фирдәвес Әхтәмова (сулда), Сабира – Нәҗибә Ихсанова («Татар хатыны ниләр күрми?», Г.Ибраһимов). 1989 ел

карьерасына килгәндә – андый актриса бар иде, бердәнбер иде, кешелекле иде, ясалмалыктан мәхрүм ихлас иде, артыгы белән туры сүзле иде.

(Кайсыдыр бер мәҗлестә, сүз иярә сүз чыгып, кемдер минем хатыным Җәмиләне «чеметеп» алырга теләүдән: «Ничек бу артистка кияүгә чыгарга җөрьәт иттең? Аларның күзе гел читләрдә бит...» – дип белдергәч, Фирдәвес: «Әхтәмнең күзе читләрдә булса, аның үзенә караучы булдымы соң? Юк бит. Безнең кызлар аны яратмады, шуны яраткан Җәмиләсенә рәхмәт инде – ул аннан кеше ясады», – диде). Үз күргәнен, уйлаганын өздереп әйтсә дә, аңа рәнҗеп үпкә саклаучыны мин белмим. Фирдәвеснең кисәтүләре һәрчак үз вакытында, урынлы була иде.

Бүген – сәхнәдә ихласлык тансыкка әверелеп барган кабалану, ашыгу заманында, театрыбыз тезгенен кулларыннан ычкындырмас өчен тырышлыкларын кызганмаучыларга, сәхнәдә Фирдәвес рухы яшәсен өчен, ихласлык премиясе булдыруны тәкъдим итәр идем. (Уйнап түгел – уйлап!)

Әгәр шундый премия булдырылып, сәхнәдә ихласлык өстенлек итә башласа, тамашачылар Фирдәвес Әхтәмованы гына түгел, Гөлсем Камскаяны да, Галимә Ибраһимованы да хәтерләп, алар рухына дога кылырлар иде. Алар сәхнәдә уйнап кына яшәмәделәр, ә ихластан яшәп уйнадылар. Аерма бик тә зур. Әйе, татар театрында ихлас күңелле артистлар, күп булмаса да, бар иде. Алардагы ихласлык рухы яшәргә тиеш. Шунсыз татар милләте, үзенең төп милли сыйфатыннан мәхрүм булып, инкыйразга ризалашуы бәхәссездер.

Ихласлык – безнең милләтне башка милләтләрдән аерып танытучы төп сыйфатлардан берсе ул. Сүземне яшәсен «ихласлык премиясе», ә сәхнәдә Фирдәвес Әхтәмовалар ихласлыгы, дип, түгәрәклим. ■

Истә, һаман да истә!

Артистка Нәзифә Гайнетдинованың тууына 100 ел

ТАССРның атказанган артисты Нәзифә Гайнетдин кызы Гайнетдинова 1919 елның 16 июлендә (кайбер чыганакларда, мәсәлән, Минзәлә театры музеенда «декабрь» күрсәтелгән) Сарман районының Сарман авылында дөньяга килә. Ул, үсмер чагында ук, үзешчәннәргә кушылып, спектакльләрдә катнашып йөри. 1939 елда Нәзифәнең уйнавын Минзәлә театры режиссеры Сабир Өметбаев күреп ала һәм театрга эшкә чакыра.

Уйнаган рольләре: Людмила – «Васса Железнова» (М.Горький), Заһирә – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Зәкия – «Кайту» (Р.Ишморат), Окси – «Кара бүре» (Н.Арбан), Былбыл – «Язылмаган законнар» (Ю.Әминов), Нәгыймә – «Банкрот» (Г.Камал), Мәрфуга – «Әйтер идем йөрәк серемне» (Р.Ишморатова) һ.б.

Н.Гайнетдинова 2000 елның сентябрендә вафат булды.

Шагыйрь Чыңгыз Мусинның тууына 85 ел

Шагыйрь Чыңгыз Мулламөхәммәт улы Мусин 1934 елның 16 июлендә Татарстанның Әгерҗе районының Тирсә авылында туган.

Ч.Мусин – «Язмышым үзәннәрендә» (1989). «Тамырлар» (1997), «Кадер кичендә» (1999), «Баганалы юллар» (2003) һәм башка китаплар авторы.

1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

2017 елда вафат булды.

Артистка Фирдәвес Әхтәмованың тууына 80 ел

Татарстан Республикасының халык артисты (1996) Фирдәвес Каюм кызы Әхтәмова 1939 елның 21 июлендә Татарстанның Лаеш районындагы Яушыйк авылында туган.

1961 елда Мәскәүдә Щепкин исемендәге югары театр училищесын (татар студиясе) тәмамлагач, Татар академия театрында эшли башлый. Театрда башкарган рольләре: Рапиях – «Фаҗигале юлда» (А.Муис), Мәйсәрә – «Американ» (К.Тинчурин), Фатыйма – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин), Зөһрә – «Назлы

кияү» (К.Тинчурин), Шәмсия әби – «Казан сөлгесе» (К.Тинчурин), Розалия – «Соңгы хат» (Х.Вахит), Липочка – «Агай-эне ак мыек» (А.Островский), Софья – «Бер төн» (Б.Горбатов), Эльмира – «Дуслар җыелган җирдә» (Т.Миңнуллин), Эльмира – «Хушыгыз!» (Т.Миңнуллин), Алтынай – «Әниләр һәм бәбиләр» (Т.Миңнуллин), Хатын – «Бичура» (М.Гыйләҗев), Фатыйма – «Өчәү юлга чыктык» (Р.Батулла), Җәмилә – «Бәхетсез егет» (Г.Камал), Биби – «Беренче театр» (Г.Камал), Абруй – «Мәхәббәт турында сөйләшик» (И.Зәйниев).

2010 елда VI Халыкара «Алтын Мөнбәр» мөселман кинофестивалендә Фирдәвес Әхтәмова, «Бибинур» фильмында төп рольне башкарып, «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңү яулады.

Ф.Әхтәмова 2012 елның 22 февралендә Казанда вафат булды һәм Әтнә районы зиратында иренең кабере янәшәсендә җирләнде.

Әдәбият белгече Якуб Агишевнең тууына 120 ел

Татар әдәбияты галиме, филология фәннәре докторы (1946), доцент (1950), текстолог, педагог Якуб Хәлил улы Агишев 1899 елның 28 июлендә элекке Сарытау губернасының Кузнәй өязе (хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнәй районы) Пәлдәнге авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылындагы мәдрәсәдә ала, 1912 елда исә әти-әнисе аны авылның бер сәүдәгәр кешесенә малайлыкка бирә. Яшүсмер чагында төрле шәһәрләрдә була. 1917-1918 елларда Якуб Агишев Архангельск шәһәренең приказчиклар клубында һәвәскәр артист булып эшли.

1919-1925 елларда Якуб Агишев туган ягы авылларында балалар укыта. 1926 елда Казанга килеп, Татар телен гамәлгә кертү курсларын тәмамлый. Өч ел «Татстрах» оешмасында икътисадчы булып эшли.

1930-1933 елларда ул Казан педагогика институтында укый, шуннан соң анда татар әдәбияты буенча аспирантура тәмамлый. Аннары Татарстан халык мәгарифе кадрларының белемен күтәрү институтында татар теле һәм әдәбияты бүлеге мөдире (1934-1937), Казан педагогия училищесы мөдире урынбасары (1937-1939), Татар теле, әдәбияты һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында өлкән фәнни хезмәткәр, гыйльми сәркатип, мөдир урынбасары (1939-1945), ә 1945-1947 елларда Казан театр училищесында укыта. 1946 елда Габдулла Тукай иҗаты буенча Мәскәүдә кандидатлык диссертациясен яклый, 1947-1951 елларда Казан педагогика институтында, 1951-1960 елларда Казан дәүләт университетында укыта.

XX гасыр башы татар әдәбиятлары классиклары, аеруча Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүгә Якуб Агишев күп көч сала. Аның «Тукай – патриот» (1942), «Габдулла Тукай иҗаты» (1948, 1954), «Сайланма әсәрләр» (1954), «Пушкин һәм татар әдәбияты», «Некрасов һәм Тукай» һәм башка хезмәтләре бар.

Якуб Агишев 1972 елның 6 июнендә вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** әзерләде. ■

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

ДУМБЫРА

Дум-дум думбыра,
Әти башка кундыра.
Кундырса да кундыра,
Ипи белән туйдыра.

Гәрәй Рәхим.

Моннан 4000 еллар элек үк Урта Азиядә думбырага охшаган уен коралларының булуы турында таш кыяларга ясап калдырган рәсемнәр бар. Галимнәр бүген без белгән думбыра казакъларның шертер (чиертү), үзбәкләрнең дутар дигән уен коралларыннан соңрак килеп чыккан, диләр. Бу хакта үзләренең трактатларында Әбүнасыйр әль-Фараби да, әль-Хөсәйни дә язалар.

Марко Поло күчмә төркиләрдә, Сак кабиләләрендә думбыра дигән уен коралы моннан 2000 еллар элек үк булган һәм бөек күчеш чорында һуннар белән Европага килгән, ди.

Думбыраның борынгы болгарлар, соңрак Казан татарлары арасында киң кулланылышта булуы бәхәссез. Моны күп санлы тарихи истәлекләр, галимнәребезнең хезмәтләре һәм халык авыз иҗаты әсәрләре дә раслыйлар.

Нинди булган соң ул татар думбырасы? Аның формасы, кылларының көйләнелеше, уйнау алымнары һәм башка шундый сораулар бу уен коралын яңадан ясаучы оста өчен дә, аңарда уйнарга өйрәнүчеләр өчен дә бик кызыклы. Чөнки ул инде XVII гасыр башларында ук Казан татарлары арасында кулланудан акрынлап төшеп кала башлый, бераздан инде бөтенләй диярлек онытыла.

XX йөз башларында Русиядә беренче балалайкалар күренә башлый. Татарлар арасында балалайканы думбыра итеп көйләп уйнау очраклары күп. Бу бигрәк тә керәшеннәрдә, шулай ук үзәктән читтә яшәгән татар авылларында очрый. Шуңа да тулысынча онытыла барган мондый уен коралларын яңадан торгызу өчен күп эзләнүләр, күп белем таләп ителә.

1768-1839 елларда яшәгән күренекле татар шагыйре һәм галиме Таҗетдин Ялчыгол әль-Болгари кулъязмаларының берсендә шул чорда Казан татарлары арасында кулланылышта булган дүрт төрле музыка уен коралы – 24 кыллы гөслә, думбыра, эскрипкә (кыл кубыз), әрилә, ягъни тәгәрмәчле лира турында яза һәм сызымнарын да сызып калдыра. Сызымыннан күренгәнчә, думбыра өчпочмаклы, озын саплы, ике кыллы уен коралы булган.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

ӨЧПОЧМАКЛЫ ТАТАР ДУМБЫРАСЫ

19 нчы йөздә яшәгән Вафа Бәхтияров Сембер, хәзерге Ульяновск яклары этнографиясенә багышланган кульъязмасында думбыра сугып, төрле такмаклар әйтеп авылдан-авылга аю биетеп йөрүчеләр турында яза: «Аючылар авыл халкын җыяр өчен барабан сугып, быргы кычкыртып йөри торган булганнар. Халык җыелып беткәч, аючылар аюларын думбыра сугып, төрле такмаклар әйтеп биетәләр. Курайчылар курай уйнап, думбырачылар думбыра сугып яшь киленнәрдән көлеп, чәнчеп, такмаклар әйтә торган булганнар. Аю биетеп йөрүчеләр дүрт-биш кешедән торып, араларында курайчы, думбырачы, җырчы, такмакчы, көлдерүчеләр була».

1983 елда күренекле галим Марсель Әхмәтҗановка хәзерге Арча районының Олы Мәңгәр авылында 1879 елда туган Сабирҗан акынның думбыра чалып дастан әйткәнен күргән замандашлары: «Ул думбырасын чалып-чалып, ай чырагым, вай чырагым, дип дәртләнеп, әсәрләнеп җырлап күрсәтә иде», – дип сөйлиләр.

Күренекле галим-фольклорчы Нәкый Исәнбәт думбыра турында халык арасында сакланып калган күп кенә табышмак-әйтемнәрне җыйнап, аларны үзенең китабына кертә.

Мәсәлән: «Думбырачы думбырачыны күрсә, кылы өзелә»; «Думбыра туй төшкән өйгә килешер»; «Кызны үз иркенә куйсаң, думбырачыга барыр».

Урысларда: «Одна палка, две струны, я хозяин всей страны», – дигәннәре дә очрый.

Әлеге әйтемнәрдән күренгәнчә, думбыра уен коралы көндәлек тормышның нәкъ үзәгендә кайнаган һәм әйтеп бетергесез зур тәрбияви роль уйнаган.

XX гасырның 80 нче елларына кадәр думбыра инде онытылып беткән иде. Әмма

аның кирәклеге ул елларда үзен нык сиздерде, чөнки татар дөньясында уен коралларына битараф булмаган талантлы яшьләр күренә башлады. Борынгы уен коралларын торгызып, уйнап, беренче тапкыр сәхнәгә алып менгән үзенчәлекле үз йөзе булган «Сорнай» ансамбле оешты.

«СОРНАЙ» АНСАМБЛЕ

Думбыра уен коралының үткәнен өйрәнеп, аны яңадан халыкка кайтаруда зур хезмәт куйган шәхесләребезнең берсе ул елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми хезмәткәре Геннадий Макаров булды. Ул беренче тапкыр 1987 елда татар думбырасын ясый һәм уйнарга өйрәнә.

Ә инде 1989 елда «Сорнай» ансамбле Павлодар шәһәрендә яшәүче уен кораллары ясау остасы Шакен ага Рахешовтан ике думбыра, ике саз һәм бер ятаган ясатып ала.

ТАТАР ДУМБЫРАСЫ

1999 елда Казан дәүләт филармониясе каршында Фольклор музыкасы дәүләт ансамбле оеша. Ул елларда әлеге ансамбльнең сәнгать җитәкчесе буларак, ансамбль өчен думбыра уен коралын мин Мәскәү осталарыннан ясатып алып кайттым. Шул ук елларда Казан дәүләт консерваториясе каршында татар халык музыка уен коралары студентлар ансамбле булдырыла. Алар өчен думбыраны Петербург осталары ясый.

Алдарак язып үткәнчә, думбыра уен коралын ясау һәм аңарда уйнау традицияләре татарлар арасында инде онытылган. Фольклор экспедицияләрендә дә бабаларыбыз ясап уйнаган думбыраның бер генә үрнәге дә табылмады. Аны ясау күренешләре бары тик халык авыз иҗаты әсәрләрендә генә чагылыш таба.

Мәсәлән:

«Бер тактаны уерлар,
Эченә мәгънә куярлар.
Мәгънә ялган сөйләсә,
Колагыннан борырлар».
«Ике кылда бер таяк».
«Суксаң, елаган, тавышы халыкка өнәгән».
«Өстендә эчәге бар, астында түшәге бар».

Н.Исәнбәт.

Әлеге табышмаклардан думбыраның нинди материаллардан (агачтан, кыллары – эчәктән) ясалуы, ике кыллы булуы, аның яссы формада, агачның эчен уеп эшләнелеше, колагыннан борып көйләү, кылларына сугып уйнау алымнарын белеп була. Әлеге истәлекләр элеккеге татар думбырасының нинди булуы турында әйтеп бетергесез зур чыганак.

Думбырада уйнау алымнары да халык авыз иҗаты әсәрләрендә сакланып калган. Мәсәлән, «думбыра сугу», «думбыра чиертү», ягъни сугып уйнау, чиертеп уйнау. Ш.Мәрҗани думбырада уйнау күренешен «думбыра тарту», дип тә атый: «Нугай белән татарлар думбыраны тартарлар».

Әмма думбыраны кылларына бармаклар белән бәреп, сугып уйныйлар, чиертеп уйнау алымы бик сирәк кулланыла.

Безнең якларда думбыраны электән үк дүрт төрле формада ясаулары билгеле:

- урталай киселгән тоташ агачның эчен чокып, ярым груша формасында;
- көрәк сыман трапеция формасында яссы итеп;
- алдан әзерләнгән тактачыкларны махсус калыплар ярдәмендә ябыштырып ярым груша формасында;
- махсус әзерләнгән тактачыкларны ябыштырып, өчпочмаклы итеп.

Татар думбырасы

Безнең көннәргә килеп җиткәнче, думбыра уен коралы күп үзгәрешләр кичерә, камилләшә. Соңгы елларда думбыраны барлык төрки халыклар да диярлек ясыйлар. Ул шулкадәр камил уен коралы ки, аны инде тагын да камилләштереп булмый, бары тик сыйфатлы итеп ясап яисә бизәп кенә була.

«Ясалгансың син тут дигән агачтан,
Ә тут үскән нурлар алып кояштан.
Матур баулар тактым сиңа, думбырам,
Уйнаганда талмасын, дип кулларым.
Ак сөяктән төрле бизәк уйдырдым,
Йөзләреңә күп гүзәллек сыйдырдым».

Юлдаш Сәетназаров,
каракалпак шагыйре.

Алда санап кителгән чыганаклар нигезендә, халыкның өлгереп җиткән ихтыяҗын искә алып, 2000 елда музыка уен кораллары ясау остасы Таһир Вәлиуллин Казанда думбыра уен коралын ясый башлады.

Т.ВӘЛИУЛЛИН ҮЗЕ ЯСАГАН ДУМБЫРА

Озынлыгы – 96 см. Ике күтәртмә арасы – 73 см. Кәүсәсе (декасы) өрәңге агачыннан ясала һәм ул уен коралының тавышын көчәйтү өчен резонатор булып тора. Тавышны тагын да көчәйтү өчен дека эченә махсус пружина урнаштырылган. Өске тактасы ак чыршыдан ясалган. Кәүсәне ясау аеруча катлаулы. Монда агач эшен яхшы белү генә җитми, тавыш хасил итә торган физика законнарын да белергә кирәк. Сап өлеше кипкән өрәңге яисә каен агачыннан ясалган һәм аңа 0,8-0,9 мм калынлыктагы лескадан 16-17 лад күтәртмәсе бәйләнгән. Шундый ук лескадан ике кыл тарттырылган. Түбән тавышлы беренче кыл, кече октаваның – ре, икенче кыл кече октаваның – соль тавышларына (кварта аралыгына) көйләнә. Икенче кылны ля тавышына тарттырып квинта аралыгына да көйләргә мөмкин.

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

ТАТАР МУЗЫКАСЫНЫҢ НОТАЛЫ БАСМАЛАРЫ ТУПЛАНМАСЫ

Татарстанның музыка сәнгате ул – бөтен республиканың казанышы. Иң тәүге башлангычыннан алып бүгенге чорга кадәр нотага салынган әсәрләр татар музыка сәнгатенең елъязма-тарихын чагылдыра.

1987 елда оештырылган сәнгать бүлеге, ноталы музыка әсәрләрен җыю, тәртипкә салу эшен җайга салып, күпмилләтле республикабызда дөньяга чыккан күренекле иҗат үрнәкләреннән тулы бер коллекция булдырып килә. 1991 елда китапханә «милли» дигән дәрәҗә-статуска ирешкәч, бу эш тагын да мәгънәлерәк төс алды; элеккеге чорга караган яисә югалып калган басмаларны эзләп табып, яңалары янәшәсенә өстәү хисабына ноталы тупланмалар тагын да ишәя бара.



Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.


Рафаэль Белялов
Татарские сюиты
Рафаэль Белялов
Пьесы для скрипки и фортепиано
Рафаэль Белялов
Соната
для скрипки и фортепиано
Виолончель һәм фортепиано өчен пьесалар
Пьесы для виолончели и
Нт 1529386
Скрипка һәм
өчен поэма
Пятая
Сара Садыйкова
Ак калфак
Нт 1642027

Моңа ирешү өчен, иң әүвәл Татарстанның музыкаль елъязмасын чагылдырган ноталы әсәр-басмаларны эзләп табу кирәк булды. Моның исәбе алынмаган, библиографиясе юк, аз тиражлы басмалар төрле китапханәләргә сибелеп, онытылырга дучар ителгән иде. Күпьеллык хезмәт нәтиҗәсендә, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, шулай ук Казандагы башка китапханәләр: Республика яшүсмерләр, Казан университетының Фәнни китапханәсе, мәдәният оешмалары, музыка сәнгате

өлкәсендәге мәгариф оешмалары китапханәләре фондларында саклана торган ноталы милли музыка басмалары репертуары турында мәгълүмат җыелды.

Башкарылган эш нигезендә 1999 елда «Казан шәһәренең эре китапханәләрендә саклаучы ноталы татар музыкасы басмаларының җыелма каталогы» төзелде, анда һәрбер документның саклану урыны да күрсәтелде. Әлеге кулланма китапханәләр, мәгълүмат оешмалары хезмәткәрләренә, музыка сәнгате белгечләренә һәм укытучыларына, югары уку йортлары, музыка училищелары һәм мәктәпләре шәкертләренә, музыка мәдәнияте белән кызыксынучыларга тәгаенләнде. Боларны барлап ачыклаганнан соң, Милли китапханәнең сәнгать бүлегендәге тупланма татар музыкасы ноталы басмаларының Казандагы иң тулы коллекциясе буларак бәяләнде. 2010 елда «Татарстанның музыкаль мирасы» дигән исемдәге электрон библиографик күрсәткеч төзелеп, китапханә сайтына кертелде.

Хәзерге көнгә 1934-2015 еллар белән чикләнгән тупланманы 815 исемдәге 2119 данә басма тәшкил итә. Аңарда ноталы мондый басмалар бар:

- Татарстан Республикасында татар һәм рус телләрендә басылганнары;
- кайда чыгуына карамастан, татар телендәге басмалар;
- Татарстан композиторларының республикадан читтә дөнья күргән әсәрләре;
- Республикадан читтә яшәүче татар милли композиторларының әсәрләре.
- Тупланманың жанры – төре ягыннан җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә республиканың хәзерге көндәге күпкырлы музыкаль мәдәни торышы тулаем ачыла: биредә татар халык көйләре, Татарстан композиторларының вокаль һәм инструменталь әсәрләре, музыкаль сәхнә әсәрләре (опера, балет, музыкаль комедияләр), балалар өчен язылган әсәрләр урын алган.

Аерым композиторларның ноталы әсәрләре бер кулга җыелганга күрә, төрле елларда иҗат иткән Ф.Әхмәтов, Ә.Бакиров, Х.Вәлиуллин, Ю.Виноградов, Р.Еникеев, Н.Жиһанов, А.Ключарёв, М.Мозаффаров, А.Монасыйпов, С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, Р.Яхин кебек мәшһүр талант ияләренең иҗат җимешләре тупланмада тулысы белән диярлек саклана.

Ноталы басмаларның чыккан елларын ачыклап карасаң, гыйбрәтле мәгълүмат аласың:

- 4 исемдә – 1934-1939 еллардагы басмалар;
- 15 исемдә – 1940-1949 еллардагы басмалар;
- 58 исемдә – 1950-1959 еллардагы басмалар;
- 155 исемдә – 1960-1969 еллардагы басмалар;
- 134 исемдә – 1970-1979 еллардагы басмалар;
- 126 исемдә – 1980-1989 еллардагы басмалар;
- 145 исемдә – 1990-1999 еллардагы басмалар;
- 178 исемдә – 2000-2015 еллардагы басмалар.

Авторлар тарафыннан култамга куеп бирелгән бердәнбер, кыйммәтле һәм сирәк нөсхәләр «Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең сәнгать бүлегендәге кыйммәтле һәм сирәк документлар реестры»на («Реестр ценных и редких документов отдела искусств Национальной библиотеки Республики Татарстан») кертелгән. Ноталы басма китаплар тупланмасы Татарстанда музыка сәнгатенең үсешен тулысынча күзалларга мөмкинлек бирә, аерым жанрларның гына түгел, ә композиторларның да иҗади үсеш баскычларын ачыкларга ярдәм итә. ■

ИЮНЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 июньдә Казан Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күп балалы аналарны хөрмәтләде. Аларга «Ана даны – Материнская слава» медален тапшырды.

● 2 июньдә Казакъстаннан «Нәүрүз» халыкара театр фестивалендә килгән артистлар Кабан күле өстендә «Җибәк кыз» спектаклен күрсәтте.

● 5 июньдә Казан Кремле музей-тыюлыгында «Татарларда шәмаил сәнгате һәм гарәп каллиграфиясе» дип исемләнгән күргәзмә ачылды.



● 12 июньдә Сабаның үзәк мәйданында беренче тапкыр зур гаилә чарасы – «Колясқалар парады» узды.

● 12 июньдә Кукмараның Лубян урман-техник көллияте студентлары һәм хезмәткәрләре арасында ел саен үткәрелә торган туристлык җыены үтте.

● 13 июньдә Россия Президенты Владимир Путин Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең солист-вокалисты Георгий Ибушевка «Россия Федерациясенең атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турындагы Указга кул куйды.

● 13 июньдә Ташкент шәһәрендәге Үзбәкстан Дәүләт консерваториясендә Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, композитор Рәшит Кәлимуллинның авторлык концерты булды.

● 14 июньдә Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин «Милли тормыш һәм дин» X Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының пленар утырышында катнашты һәм чыгыш ясады.

● 16 июньдә Актанышта Ык буе авыллары Сабан туе булып узды. Бәйрәм кунакларын Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Башкортстан Дәүләт Корылтае Җыены Рәисе Константин Толкачев һәм Актаныш муниципаль район хакимияте башлыгы Энгель Фәттахов котлады.

● 16 июньдә Таллинның Иске шәһәр өлешендәге Манаралы мәйданда IV Европа Сабан туе үтте. Анда Финляндия, Польша, Бельгия, Литва, Латвия, Англия, Чехия, Швейцария һәм Россиянең күп кенә шәһәрләреннән милләттәшләребез (барлыгы 11000 кеше) бәйрәм итте.

● 17 июньдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Кытайның Хэйлунцзян провинциясе башкаласы Харбин шәһәрендә «VI Россия-Кытай ЭКСПО-2019» чараларында катнашты.



● Июнь аенда Румыниядә милләттәшебез – язучы, тәрҗемәче, культуролог Танер Муратның «Мин Татарстан урамында яшим» дигән китабы нәшер ителде. Әлеге күркәм җыентыкта Т.Муратның шәхси хатлары һәм сәяхәтнамәләре урын алган. ■

Мирасворд

1912-1918 елларда Казанда татарча чыккан газета

Җәләй, Хәмиди

Гарәп артикле

XX йөз азәрбайҗан шагыйре һәм драматургы

«... юлның тузаны» (татар халык җыры)

... мулла

Кайбер хайваннарның муенындагы озын куе йон

Шагыйрь Мостафа ...

... Насыйри (репрессияләнгән язучы, журналист)

Яраклы, кулай

Тәрҗемәче ... Миңлебаев

Соклану, хуплауны белдерә торган сүз

Җәядән атыла

Тире астына шприц белән дару җибәрү

... Вәлиәхмәтов

Нәҗми, Латыйп

Кирмән коменданты (иск.)

Габдулла Тукайның 1911 елда язган шигыре

Дагыстанда яшәүче төрки халык

Аңлатма, ачыклама (иск.)

Шигырьдә махсус рифмалы сигез юллы строфа

Фитильне яктырткыч

Карловы ...

Америка әдибе, «Том Сойер маҗаралары» романы авторы

Данил Салихов романы

Гарәп хәрефе

Бәрәңге төбенә өю (диал.)

Усманов, Рәкыйпов, Маннапов

... Бәдигый

Вак кисәкләргә таркалу

Коръәнне дөрес уку турындагы өйрәтмә

Борынгы Мисырда кояш Алласы

... Роллан

Бик тиз, кыска вакыт эчендә

... Геллий (борынгы Рим әдибе)

... Ахеджакова

Робин ...

Урылган игеннең бер бәйләм итеп җыеп бәйләнгән сабаклары

Кәрим Тинчурин драмасы

Ялган гаеп, гайбәт

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Самат», аса, Мар, Рәсүл, Хуҗа, Рим, Әрә, «Мират», Кубрат, мән, Хо, Наг, «Кайту», олыс, сары, лар, тимеркүк, «ЗИС», Пастер, әвен, неон, даим, келә, Ивик.

Өстән аска: «Сәрләүхәсез», ип, мисвәк, ураса, унты, Садри, Толымбай, Ыргали, Еники, Ра, кам, Ремек, ата, ре, Әнвәр, «Амур», Мөлеков, Саҗидә, Арам, сәкен.

Рәис Габдулла төзеде.



«Красная звезда» пароходы

«Безнең мирас» елъязмасы /июль

100 ел элек (1919)

10 июльдә Казанга агитацион-инструктив пароход («Красная звезда») килә. «Эш» газетасы бу хакта болай яза: «Пароходның килүдән максаты – халык арасына аңфикер тарату һәм урыннардагы совет мөәссәләренең, мәгариф шөгъбәләренең эшләрен тәфтиш кылу».

Бу пароходта Н.К.Крупская да була.

100 ел элек (1919)

22 июльдә Татарстан китап нәшрияты оештырыла.

95 ел элек (1924)

Галимҗан Ибраһимовның «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» исемле китабы Мәскәү нәширият кооперативында басылып чыга.

90 ел элек (1929)

«Яңалиф» газетасы «Шәрык-кино» тарафыннан татар руханилары тормышын чагылдырган «Койрыклы йолдыз» исемле кинокомедия төшерелә башлавы турында хәбәр итә.

90 ел элек (1929)

«Кызыл Татарстан»да композитор Салих Сәйдәшевнең «Бездә музыка мәсьәләләре» исемле мәкаләсе басыла.

90 ел элек (1929)

22 июльдә Яшел Үзән шәһәрендә Идел буе фанера-мебель комбинаты ачыла.

85 ел элек (1934)

15 июльдә Урал өлкә татар театры оештырыла.

80 ел элек (1939)

«Совет әдәбияты» журналында Таҗи Гыйззәтнең «Атаклы кызлар» пьесасы (ахыры журналның 1940 елгы 1 нче санында), А.Шамовның «Кыз урлау», М.Әмирнең «Тун ачуы» дигән хикәяләре басыла.

75 ел элек (1944)

Татар матбугаты А.П.Чеховның үлүенә 40 ел тулуны билгеләп үтә: «Кызыл Татарстан»да шул уңайдан Фатих Хөсни (2 июль) һәм Гадел Кутуй (15 июль) мәкаләләре дөнья күрә.

75 ел элек (1944)

15 июльдә Төркиядә яшәп иҗат итүче татар галиме, тарихчы, тарих фәннәре докторы, профессор Надир Дәүләт (Надир Ибраһим улы Дәүләткилде) туа.

30 ел элек (1989)

«Идел» журналының беренче саны чыга.

Журналга ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. ИЮЛЬ 2019

И останется в мире слово моё...: Зиннур Мансуров.

Историческое наследие: «Сююмбике». О.Иванова; «Этруски – наставники римлян». С.Шамси.

Татарский мир: Минтимир Шаймиев: «Невозможно закрыть глаза на проблемы родного языка»; «Книгу, которую читали со слезами на глазах». Г.Рахим; «Столица крящёных татар». Р.Сагди.

Педагогическое наследие: «Казанская центральная крящёно-татарская школа». Р.Исхаков.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Надо установить памятник «Родному языку». З.Мансуров.

Эхо войны: «Старик-колдун». Р.Шайдуллин; «Трое» *(рассказ)*. Р.Низами.

В глубинах памяти: «Кто дал тебе такое имя?» А.Зарипов; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Древние татарские музыкальные инструменты». Р.Гилязов.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JULY 2019

There will be left my word in the world...: Zinnur Mansurov.

Historic heritage: «Suyumbike» by O.Ivanova; «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi.

Tatar world: Mintimir Shaymiev: «The problem of mother tongue cannot be held back»; «The book read with tears» by G.Rakhim; «The capital of the Baptized Tatars» by R.Sagdi.

Pedagogical heritage: «Kazan central Baptized Tatar school» by R.Iskhakov.

Literary heritage: «Mother tongue needs in establishing of monument» by Z.Mansur.

The echo of war: «The old wizard» by R.Shaydullin; «The three (story)» by R.Nizami.

From the deepest store of memory: «Your name is amazing, who named you in a such way...» by A.Zaripov; «Still keeping in the memory, still keeping!».

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

«Кырымның йөзем бакчасы». 1960. Киндер, майлы буяу

«Катык. Натюрморт». 1976. Картон, майлы буяу

Евгений Зуев



1923 елның 23 декабрендә Калининград өлкәсендәге Хвошня авылында туган.

1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша.

1953 елда Эстония ССР дәүләт сынлы сәнгать институтын тәмамлый.

Е.В.Зуев – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1964), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1974).

Казан шәһәрендә яшәде һәм вафат булды.

«Икмәк – тиңсез хикмәт!». 1989. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

«Гайнан Кормаш төркеме» әгъзасы Фәрит Солтанбәков. Казан. 25 август, 1994 ел. Мидхәт Шакирҗанов фотосы.
(**Ш.Мостафин.** «Изге антка тугрылык»)

Агымсуларны эшкә җигәсе бар. Фәрит Хатипов
Хатирәт. Сәгыйт Сүнчәләй
Изге антка тугрылык. Шаһинур Мостафин
Мөхтәрәм Мөдәмил ядкяре. Рөстәм Зарипов
Вәгъдә. Рәмзи Вәлиев

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- ***uslugi.tatarstan.ru*** *сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- ***podpiska.pochta.ru*** *сайты ярдәмендә*

электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*